МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№2-3 / июнь 2012

1812 елгы Ватан сугышында җиңүгә 200 ел

Сабантуй

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

Журнал «Татмедиа» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.

ИНДЕКС 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов

Иҗат төркеме:
Илфак Ибраһимов
Рамил Ханнанов
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Ренат Минигалиев
Ландыш Әбүдәрова
Лилия Гәрәева

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм
массакүләм коммуникацияләр
агентлыгы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексын-
да басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ №6943.
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 $^{1}/_{16}$
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 15.06.2012

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№2-3 / июнь 2012

Эчтәлек

ТАРИХ

10 **Татарлыгыбыз сагында.** *Индус Таһиров*
14 **Үткәнебез сәхифәләрен барлап...** *Рафаил Хәкимов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе*
23 **Ак сөлге.** *Ренат Харис*
24 **1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813-1815 еллардагы рус армиясенең Чит ил походларында татарлар.** *Илшат Фәйзрахманов*
31 **Бөтендөнья Сабан туйларының башкаласы — Казан!** *Равил Рахмани*
32 **«Кадимчеләр дийарыннан» бер әсәр.** *Әлфинә Сибгатуллина*
41 **Җыен сүзе.** *Лена Шагыйрьҗан*

ӘДӘБИЯТ

44 **Нәзыйрәчелектән — интертекстуальлеккә-әңгәмәдәшлеккә таба.** *Резеда Ганиева*
54 **Шагыйрь Һәмдәми яки Мелла Мамай.** *Марсель Әхмәтҗанов*
62 **Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә»сеннән үрнәкләр**
66 **Йөрәк җырлый.** *Флера Гыйззәтуллина*
68 **«Унҗиденче елның алдында уяндык без көлеп...»** *Фәридә Хәсәнова*
76 **Шигырьләр.** *Әбрар Сәгыйди*
80 **Якташларыма бәйрәм.** *Фәнис Яруллин*
81 **Уйгану вә яңалык тарихы.** *Ризаэтдин Фәхретдин*
95 **Батыр тәкә.** *Шамил Маннапов*

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторларның, Р.Якупов, Р.Әхмәтов, М.Шакирҗанов, Г.Хафизов, В.Туник, И.Латыйфуллин, В.Зотов, Л.Кузнецова, Рус этнография музее, ТРның Үзәк дәүләт архивы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Халыклар дуслыгы йорты архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә — Каенлыкта узган Казан Сабан туе. 1985 ел. М.Шакирҗанов фотосы; **2 нче битендә** — Болгар Җыены. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты архивыннан; **3-4 нче битләрендә** Р.Якупов фотолары.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132
ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә языла аласыз.

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

98 **Тамырлар кая тоташа?** *Гамирҗан Дәүләтшин*
107 **Чабыш атлары.** *Салисә Гәрәева*
108 **«Сабан туе — безнең туй, сөлгеяулык сайлап куй».** *Рамил Ханнанов*
121 **Ул заманда.** *Ирек Сабиров*
122 **Федераль Сабантуй: тәҗрибә һәм үсеш перспективасы.** *Фәрит Уразаев*
133 **Сабан туенда.** *Рәшит Әхмәтҗанов*
134 **Катыктан акча эзләү.** *Зиннур Мансуров*
135 **Җыеннар.** *Закир*
140 **Казанда үтә торган Сабантуй бәйрәме — XIX гасыр рус газеталары битләрендә**
144 **Сабан.** *Карл Фукс*
149 **«Каенлыкта бүген Сабан туе...»** *Әхмәт Рәшит*
150 **Сабан туенда.** *Фатих Әмирхан*
154 **Алып батыр уллары.** *Газинур Морат*
155 **Ярыш.** *Рабит Батулла*
165 **Сабантуй булып узган мәйданда.** *Харрас Әюп*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

168 **Сүз ул — гәүһәр.** *Тәлгат Галиуллин*
173 **Иле иркеннең көне иркен.** *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*
179 **Яшә, Сабан туе!** *Лена Шагыйрьҗан*

ХУШЛАШУ

184 Шәүкәт Биктимеровны озату мәрасимендә *Роберт Миңнуллинның* ясаган чыгышы

186 **Сабантуй.** *Мөхәммәт Мирза*
188 **Яңа китаплар**
191 **Тарих сәхифәләреннән**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВНЫҢ САБАН ТУЕ УҢАЕННАН ТАТАРСТАН ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

ХӨРМӘТЛЕ ТАТАРСТАНЛЫЛАР!

Дәүләт Советы, республика Хөкүмәте исеменнән һәм шәхсән үзем сезне татар халык бәйрәме – Сабан туе белән чын йөрәктән тәбрик итәм!

Күп гасырлар дәвамында ул татарлар өчен иң яраткан, шатлыклы һәм көтеп алына торган бәйрәм булды һәм шулай булачак та. Халкыбыз вәкилләре кайда гына яшәсә дә, Сабан туе аларга үз тамырларын барлау, иң күркәм сыйфатларын күрсәтү мөмкинлеге бирә. Бу бәйрәм – милли мәдәниятебезне сугарып торучы, буыннар арасында рухи бәйләнеш булдыручы мәңге тере чыганак.

Ямьле Сабан туе бөтенхалык мәхәббәтен казанды. Хәзер аны Татарстанда гына түгел, Россия Федерациясенең күп кенә төбәкләрендә, шулай ук чит илләрдә дә уздыралар. Бәйрәм мәйданына барлык милләт һәм дин вәкилләре җыела. Бу безне берләштерә, татар мәдәниятен популярлаштыруга, тынычлыкны һәм иминлекне ныгытуга ярдәм итә.

Сабан туенда авыл уңганнарын тантаналы шартларда тәбрикләү, хөрмәтләү матур традициягә әйләнде. Республика халкын азык-төлек белән тәэмин итү өчен алар зур тырышлык куялар. Сабан туеның данлыклы батырлары, мәшһүр мәдәният һәм сәнгать әһелләре белән беррәттән, хезмәт алдынгыларының урыны мәйдан түрендә.

Россия тарихы елында һәм Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елында Сабан туен бәйрәм итү аеруча актуаль яңгыраш тапты. Татар халкының әлеге нурлы бәйрәме уртак рухи хәзинәгә әверелде, һәм Россиянең күпмилләтле мәдәнияте елъязмасында ныклы урын алды. Без моның белән хаклы рәвештә горурланабыз.

Кадерле дуслар! Сезнең барыгызга да ихлас күңелдән нык сәламәтлек, бәхет, тынычлык һәм иминлек телим! Сабан туе күңелләребезне шатлык нурына күмсен, җиңүләргә рухландырсын, яшәү дәрте бирсен!

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н. МИҢНЕХАНОВ,

САБАНТУЙ
МИЗГЕЛЛӘРЕ

ТАРИХ

Әйләнгәндә дөнья тәгәрмәче,
Бик күп серләр чәчелеп-коелып
Кала икән...

Лена Шагыйрьҗан

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНА 20 ЕЛ

ТАТАРЛЫГЫБЫЗ САГЫНДА

ИНДУС ТАҺИРОВ,
тарих фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Фәннәр академиясе академигы

Татар конгрессының барлыкка килүенә 20 ел. Бай эчтәлекле еллар бу. Күз алдыбызда диярлек ничәмә-ничә дәүләт таркалды, аллы-гөлле революцияләр булып үтте. Шул ук вакытта татарның тарихи хәтере уянды, үткәнен барлап, киләчәгенә юл билгеләгән, гасырлар буе югалып торган татар факторы өр-яңадан хасил булды. Шуларның нәтиҗәсендә татар дөньясы барлыкка килде. Милләтебез горур рәвештә халыкара мәйданга чыкты, аның шундый ук горур республикасы пәйда булды. Республикабызда шушы кыска гына 20 ел вакыт эчендә гасырлар буе халкыбызның күңелендә йөргән уйтеләкләре, ниһаять, тормышка ашты. Болар хакында күптомлыклар язып булыр иде. Шөкер, ирешкәннәребез турында яздык та, язарбыз да... Әйе, Конгрессның беренче рәисе буларак, аның эшчәнлеге турында тәфсилләп сөйли алыр идем.

Ләкин мин, тарихчы булсам да, бу язмамны аның тарихына түгел, ә милләтебез алдында торган кайбер проблемаларга кабат-кабат юнәлтмәкче булам. Ә алар шактый.

Аларның иң беренчесе — милләтебезнең мәңгелегенә юл ачу, аның санын һәм сыйфатын саклап калу. Икенчесе — шушы максатка ирешүнең төп шарты булган Татарстаныбызны чын рәвештә алга киткән, чәчәк аткан үрнәк республикага әверелдерү. Бу ике бурыч бердәм булса гына, аларны тормышка ашыру мөмкин. Иманым камил, сөт калса, Ватан кайтачак яки татар үзе сакланса, аның Ватаны да кайтачак.

Сөт — ул милләтебезнең сыйфаты, аның ныклыгы. Татар дөньясы — ул Татарстан һәм җир шарының төрле якларына сибелеп яшәүче милләттәшләребез. Әйткәнемчә, татарлар, акрынлап булса да, бер җан һәм бер тән булып, бер-берсенең сулышын,

йөрәк тибешен сизеп, тоеп яши башладылар. Аларның башкаласы — Казан, тарихи Ватаннары — Татарстан.

Без — татарлар!
Шушы исем белән
Җирдә яшәү үзе бер бәхет.

Шагыйрь Гәрәй Рәхимнең шушы шигъри юллары халкыбызның рухи халәтенә туры килә, чөнки халкыбызга милли горурлык хисләре кайта, аның үз-үзенә ышанычы ныгый.

Ләкин барысы да ал да гөл, дип уйлау һич кенә дә дөрес булмас иде. Үткән гасырлар, бигрәк тә совет чоры милләтебезгә үзенең кара һәм зәхмәтле тамгаларын сугып калдырган. Алар бүген дә үзләрен сиздереп тора.

Соңгы халык санын алу нәтиҗәләре үз телләрен белми торган татарларның арта барганлыгы турында сөйли. Шуңа таянып кайбер рус милләтчеләре тиздән Россия тулысы белән рус телле илгә әвереләчәк, нәтиҗәдә татарлар һәм башка рус булмаган милләтләр үзләренең руслашканнарын сизми дә калачаклар, дип фаразлый. Бу — аңлы рәвештә рәсми сәясәткә килеп тоташа торган фараз. Әмма анда дөреслек тә юк түгел, чөнки телсезлек — милләт бетүгә туры юл. Россия Дәүләт Думасының 309 нчы закон кабул итүе, русларны бердәнбер дәүләт төзүче халык итеп тануны тәкъдим итүләр юкка гына түгел. Болар барысы да — бер җепкә тезелгән, беркайда да, берничек тә билгеләнмәгән милли сәясәт ул. Без Россиянең милли сәясәте юк, дибез. Аның закон нигезендә кабул ителгәне булмаса да, гамәлдәгесе бар. Ул да булса милләтләрне бетерү, аларның республикаларын юкка чыгару. Эш бит шуңа таба бара. Татар корабын да җил сөрә, кайберәүләрнең мәкерле гамәлләре татар җанын сорый, аны упкынга өстери.

Татарстан хакимияте боларга кулыннан килгән кадәр каршылык чараларын күрә, ләкин аның мөмкинлекләре чикле. Аңарга үткән гасырның 90 нчы елларындагы кебек көч-куәтне халык биреп торырга тиеш. Ә бит ул елларда мәйданнар тулы халык иде. Декларация кабул иткән 1990 елның август көннәрендә Ирек мәйданы шау-гөр килде. Әллә нинди ерак араларны якын итеп килгән меңләгән милләтпәрвәр җанатарлар Югары совет бинасына җыелган депутатларга тиешле көч-куәт биреп торды. Ерак чит илләрдә яшәгән милләтәшләребез, төннәрен йокламый, түземсезлек белән шушы документны тикшерү өчен җыелган сессия нәтиҗәләрен көтте, бәйсезлек Декларациясен кабул итүне таләп итеп, Казанга телеграммалар яудырып тордылар. Шунлыктан 30 август көнне кабул ителгән Декларация хакимият һәм халыкның бердәмлек нәтиҗәсе булды. Бу вакыйга гасырлар буе көтеп алынган бәйрәмгә әверелде.

1991 елның 21 мартында республикабызның бәйсезлегенә багышланган референдумдагы уңай җавап — шулай ук хакимият һәм халкыбызның бердәм эш итү нәтиҗәсе иде.

Безгә бүген дә әнә шундый бердәмлек һәм тәвәккәллек кирәк. Бердәмлеккә, тәвәккәллеккә мәйданда гына түгел, ә милли үзаң белән ирешелә. Моның өчен безгә милли горурлыгыбызны гомумиләштерү, үткән бай тарихыбызны барлап, аны халык күңеленә, бигрәк тә яшь буынның күңеленә сеңдерү кирәк... Галимнәребез үткән тарихыбызны гәүдәләндерүдә шактый уңышларга иреште. Зур-зур күләмле хезмәтләр барлыкка килде. Әмма аларны пропагандалау эше түбәннәнтүбән, сүлпәннән-сүлпән. Телевидение бу өлкәдә тиешле эш алып бармый, дисәм, дөреслектән әллә ни ерак булмамдыр. Ышанасы килми, ләкин миңа кайбер вакыт кемнәрдер тарихи хәтеребезне махсус рәвештә сүндерүне

максат итеп куйган кебек тоела. Ичмасам, күршеләребез башкортлардан үрнәк алсак иде. БСТ каналы моңа махсус игътибар бирә, даими рәвештә төрле тарихи тапшырулар оештыра.

Онытмыйк: тарихсыз халыкның киләчәге юк!

Бурычларыбызның иң зурларыннан берсе — яшь буынны тәрбияләү, татар гаиләсенә махсус игътибар бирү. Аңлашыладыр: татарны милләтсезлеккә өстерәүче, туган телебезне юкка чыгаручы — катнаш никахлар. Ни кызганыч, шушы ныклыгыбызны кимерүче гамәл әле дә булса үзен сиздереп тора. Тизрәк арынасы иде аңардан! Оясында ни күрсә, очканында шул була, ди халык. Балага бишектән башлап ук җыр-моңнарыбызны, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне сеңдерү зарур. Әйтик, Чувашстанның Тукай авылындагы кебек. Анда җәмәгатьчелек балаларны бөтен тулылыгы белән милли рухта тәрбияли. Мәдрәсә, мәктәп, ата-аналар бу эшне бердәм рәвештә алып бара, шунлыктан авылда эчүчелек, наркомания кебек күп урыннарга хас заман чирләре дә юк. Аллага шөкер, мондый авылларыбыз юк түгел. Шул ук Чувашстанның Шыгырдан, Пенза өлкәсенең Урта Әләзән, Мордовиянең Белоозерье кебек авыллары шулай ук күпләргә мисал булып тора.

Сер түгел: соңгы елларда шәһәрләрдә балаларын татар мәктәпләренә бирергә теләмәүчеләр саны артты. Имештер, бу мәктәпләрдәге балалар рус телен начар үзләштерә, шунлыктан аларның югары уку йортларына керү мөмкинлекләре чикле. Монда дөреслек юк дип әйтеп булмый. Моңа ниндидер рәвештә югары уку йортларына керү БДИ (бердәм дәүләт имтиханы) рус телендә генә бирелергә тиешлеге дә дәлил булып тора сыман. Алай булгач, нигә соң Саратовның шәһәр уртасында урнашкан татар гимназиясендә беренче сыйныфка керү өчен бер урынга алты кешелек конкурс? Монда башка милләт балалары да керергә омтыла. Шул ук хәл Ижау татар гимназиясендә яки Самараның «Яктылык» мәктәбендә. Монда әллә ни сер юк, бу мәктәпләрдә укыту, белем һәм тәрбия бирү дәрәҗәсе тиешле югарылыкка куелган. Әлеге мәктәпләрне тәмамлаучылар өчен теләсә кайсы уку йортының ишеге ачык. Аларга заман чирләре дә йокмый, чөнки алар киң җәмәгатьчелек игътибарында. Мондый мәктәпләрнең уңышларында ата-аналар гына түгел, галимнәрнең һәм татар байларының өлешләре дә зур. Быел Саратов өлкәсенең 6 татар авылы мәктәбе тиешле шартлар булмау сылтавы белән оптимизация корбанына әйләнергә тиеш була, тик меценат Камил Аблязовның матди ярдәме һәм киң җәмәгатьчелекнең бу чарага каршылык күрсәтүе аркасында, мәктәпләр ябылмый кала. Самара, Оренбург өлкәләрендә дә җәмәгатьчелек шундый активлык күрсәтә.

Мондый мәктәпләрне тәмамлаган балалар туган телләрен, рус һәм инглиз телләрен камил рәвештә үзләштерәләр. Чит телләрне белүнең төп нигезе — туган тел. Ул һәрбер татар өчен мөкатдәс һәм газиз булырга тиеш. АКШ, Финляндия татарлары өч-дүрт тел белә, ләкин алар өчен туган татар телебез беренче урында тора. Нигә безгә шул милләттәшләребездән үрнәк алмаска?

Революциягә кадәр Россиядә дә татарлар үз телләрен саклый белгәннәр. «Сын Отечества» газетасының 1904 елгы 1 июнь санында юкка гына «мөселманнарның рус йогынтысыннан ерак торуларына аларның мәктәп системасы сәбәп булып тора», дип язылмаган. Безгә бүген дә милли мәгариф проблемасын беренче урынга чыгару зарур. Моны тормышка ашыруда дин әһелләребезнең ныклы һәм даими катнашы булырга тиеш.

Татар конгрессының дин әһелләре

белән якынлашуы, уртак чаралар үткәрүе — иң кирәкле чараларның берсе. Болгар Җыенын дәүләт органнары белән бергә үткәрүнең традициягә әверелә баруы моңа ачык мисал. Дин дәүләттән аерылган булса да, җәмгыяттән аерылмаган.

Халкыбызны 1552 елдан башланган иң авыр чорларда Ислам дине саклап калган. Аның аркылы Аллаһы Тәгалә милләтебезгә яшәү көче иңдергән. Ят камалышта калса да, чукындыру, руслаштыру сәясәте янаса да, ул бирешмәгән, чөнки дини тәрбия милли яшәешнең төп сыйфатына әверелгән. Заманында күренекле тарихчы Н.А.Фирсов болай дип язган: «Ни убеждения миссионеров, ни льготы, даруемые правительством за переход к христианству, ни обстоятельства, что им приходилось разоряться от платежа за новокрещеных податей, ни уничтожение их мечетей не действовали на них; огромнейшее их большинство оставалось твердым в вере отцов и дедов, между тем, как живущие рядом с ними язычники почти поголовно крещены». 1870 елны Сембер шәһәрендә чыккан бер китапта татарлар, русларга рухи яктан түгел, бары сәяси рәвештә генә буйсындылар, алар Россиянең иң ныклы, башкаларга да йогынты ясаучы халкы, дип язылган.

Бүген дә дини тәрбия актуаль проблемаларыбызның берсе булып тора. Шәһәр һәм авылларыбызда мәчетләр торгызылды, аларның яңалары да үсеп чыкты. Болгардагы яңа ачылган мәчет үзе генә дә ни тора!

Әйе, мәчетләр күп, ә менә анда йөрүчеләр әллә ни күп түгел. Татарлар төзегән Мәскәү мәчетләрен башка милләт вәкилләре басып алды. Гасырдан гасырга яшәп килгән җамигъ мәчетебез сүтелде. Яңасын кавказлылар сала. Башка шәһәрләрдә дә охшаш проблемалар җитәрлек. Шунысы куандыра: мәчеткә, динебезгә тартылучы яшьләрнең саны арта. Шуның белән наркомания, эчүчелек кебек заман чирләренә дә киртә барлыкка килә.

Тик менә дин әһелләребез арасында таркаулык кына күңелне борчый. Ни кызганыч, алар арасында үзара аңлашу юк дәрәҗәсендә. Күрәсең, монда да җәмәгатьчелегебезнең, милли оешмаларыбызның, Татар конгрессының, президентыбызның катгый сүзе кирәктер. Дини бердәмлек — милли бердәмлекнең асылы. Халкыбыз бу мәсьәләдә дә, Декларация кабул иткән, референдум үткәргән көннәрдәге кебек үз сүзен өздереп әйтсен, милләтпәрвәр шәхесләребезне алыштырырлык яшьләр күбрәк булсын иде.

Татар — үзенең ике мең елдан артык тарихында ничәмә-ничә дәүләт төзеп, утны-суны кичеп, Габделбари Баттал язганча, тарих тарафыннан чарланган эшсөяр халык. Безгә шушы сыйфатыбызны яңартып, татар эшчәнлегенә юл ачу кирәк. Хәзергә исә күпвакыт халкыбызның эшкә омтылышын буу фактларын күрергә туры килә. Бигрәк тә авыл эшчәннәре аптырый. Милиция-полиция органнары, бернигә дә карамастан, аларга бер киртә артыннан икенчесен тудыра тора. Күп авылларда медицина пунктлары, клуб һәм китапханәләр, балалар бакчалары юк, шунлыктан авылдан яшьләр китә. Ә бит авылларыбызга, андагы халыкка махсус игътибар тудырмасак, милләтебезне саклап калу кыен булачак.

Проблемалар бихисап. Ләкин аларның күбесе хәл итәрдәй. Моңа тик сәяси ихтыяр һәм бердәмлек кенә кирәк. Бердәмлек, бердәмлек һәм тагын бер кат бердәмлек!

Бу — минем Татар конгрессының егерме еллыгы якынлашу уңаеннан барлыкка килгән кайбер уй-фикерләрем.

2012 ЕЛ — ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ

ҮТКӘНЕБЕЗ СӘХИФӘЛӘРЕН БАРЛАП...

Татарстан Фәннәр академиясе академигы,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры,
тарих фәннәре докторы РАФАИЛ ХӘКИМОВ *белән әңгәмә*

– Рафаил Сибгатович! СССР таркалганнан соңгы дәвер хөр фикер үсеше өчен уңай шартлар тудырды. Галимнәр дөрес дип тапкан фикерләрен ачыктан-ачык яза башлады, өйрәнү өчен яңа фәнни темалар барлыкка килде. Шушы үзгәрешләрнең бер нәтиҗәсе булып 1996 елда Тарих институты оешты. Шактый вакыт үткән, шактый сулар аккан. Инде беренче нәтиҗәләрне ясарга мөмкин.

— Беренчедән, без тарихны дөрес яза башладык. Әлбәттә, безне беркем дә ничек язарга, ничек язмаска дип өйрәтеп тормый. Яисә кайсы чорны бирергә, кайсын бирмәскә, дип. Элек, үзегез беләсез, өстә шундый карар тора иде — Үзәк карары. Хәзер без бу яктан ирекле, үзебез язабыз, үзебез галимнәр әзерлибез, үзебез фәнни юнәлешне билгелибез. Институтта татар тарихы буенча диссертацияләр яклана. Алтын Урда тарихы яки башка тема буенча әле ул диссертацияне кайда яклап булыр иде. Мәскәүдәме яки кайсыдыр бүтән шәһәрдәме?! Әйтергә мөмкин: хәзер безнең бу яктан нигез бар. Бу нигез тарихны язар өчен һәм фәнни эшләрне дәвам итү өчен кирәк.

Икенчедән, безнең тикшеренүләр киң колачлы. Элек автономия булган. Безнең аң да шул автономиядә чикләнгән булган икән. Бүген без киңрәк карыйбыз. Татар тарихы искиткеч киң бит, бөтен Евразияне алсаң да, татар тарихы килеп чыга. Шуңар бөтен тарихны күрсәтергә безнең мөмкинлек бар. Татар тарихы искиткеч бай, искиткеч кызык. Бөек тә дип әйтер идем.

Өченчедән, без кайсы галим, кайсы институт яисә университет белән аралашырга телибез, шуның белән эшлибез. Безнең Рәсәйдә генә түгел, чит илләрдә дә бергә эшли торган галимнәр, партнерлар бар. Мондый хезмәттәшлек безгә көч, тарихны бүтәнчә күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Без җиде томлык «Татар тарихы»н яза башладык. Өч томы чыкты. Бу бик яхшы нигез, бик төпле эш. Ул безнең Тарих институтында гына түгел, Татарстанда һәм, киңрәк, Рәсәйдә, бүген татар тарихын өйрәнү дәрәҗәсен күрсәтә. Шушы нигезгә таянып, бүтән юнәлешләрне үстерә ала-

быз, кая барырга кирәк, ничек, кемне тагын монда тартып, университетларда студентларны, аспирантларны әзерләп, яңа адымнар ясый алабыз? Киләчәк турында уйлаганда, бу яктан без ирекле.

Халык күбрәк Казанның мең еллыгын уздыруны белә. Ул, чыннан да, зур проект булып чыкты. Фәнни яктан да, тормышка ашыру ягыннан да нindидер нәтиҗәләр бирде. Безгә абруй да бирде. Ләкин ул безнең эш юнәлешләренең берсе генә булды. Бүген Болгарда, Тәтештә, Яр Чаллыда, Зөядә, Алабугада, Әстерханда археологик казу эшләре алып барабыз. Быел Алтайда һәм Болгариядә фәнни конференцияләр, форумнар үткәрергә җыенабыз. Безнең эшебездәге ачышларны Рәсәй галимнәре дә таный.

– 2012 ел Россия Федерациясе күләмендә Тарих елы, Татарстанда Тарихи-мәдәни мирас елы дип игълан ителде. Шушы уңайдан төзелгән Россия һәм Татарстан дәүләт программалары, Сезнеңчә, кайсы яклары белән охшаш һәм кайсы яклары белән аерыла.

— Рәсәй тарихы дигәндә, алар әле кайсы юл белән барырга кирәклеген белеп бетерми. Без инде ул юлны аз-маз булса да чамалыйбыз. Кайда безнең кимчелек, кайда безнең мөмкинлек — барын да беләбез. Рәсәйнең тарихын яңадан карарга кирәк. Элек ул тарих Киевтан башлана иде. Киев бүген Украинада. Аңардан башлап булмый. Новгородтан башласаң, Швециягә тарта. Мәскәүдән башласаң, Алтын Урдага тарта.

Икенче яктан, Рәсәйдә яши торган күп милләтләр үз тарихларын язалар һәм язып чыктылар да. Мәсәлән, башкортлар, чувашлар язды. Ул тарихларны ничек Рәсәй тарихына кертергә? Алар капма-каршы булса, кешенең аңы буталып бетә. Кертмәсәң, исәпкә алмасаң, рус тарихы гына булып чыга. Мондый мөһим мәсьәлә дә бар.

Идеологик яктан караганда, Рәсәйдә бүген коммунистик идеология юк. Демократия бар дип әйтәләр, анысы да аңлашылып бетми. Идеология юк, шуңа тарихка биреләләр, ләкин тарихны еш гына дөрес аңлатмыйлар. Шуңа Рәсәйдә тарихи юл зәгыйфь булып чыкты. Россия күләмендә берничә конференция кысаларында нindидер төпле темаларны уртага куеп сөйләшсәләр иде. Минемчә, бөтенебезгә дә файдалы булыр. Андый эш күренми. Аерым-аерым китаплар чыга, алар болай да чыгып тора.

Татарстанга килгәндә, монда әллә нинди яңа нәрсә күренми. Шушы башлаган эшне яхшы гына дәвам итәбез.

Әлбәттә, безнең программа бар. Берсе турында мин әйттем инде, без җиде томлык «Татар тарихы» язабыз. Бу юнәлештә Евразия тарихына чыктык дисәк тә була. «Татар педагогика антологиясе»н әзерлибез. Күптомлы татар дини фәлсәфәсе антологиясен бастырабыз. «Тартарика» исеме астында «Tartarika», «Этнография» атласлары эшләдек. Яңаларын әзерлибез. Безнең күп хезмәтләр үрнәккә әйләнде. Аларны хәзер казахлар, төрекмәннәр кабатларга тырыша.

Дөресен әйткәндә, хәзер һәрбер юнәлеш турында киң итеп сөйли башласам, сөйләшү бер лекциягә әйләнәчәк. Безнең һәр бүлек үзе бер институт сыман. Темаларына,

хезмәтләренә, башкарган эшләрнең фәнни әһәмиятенә карасаң, институт сыман эшли.

– Сез җитәкләгән Тарих институтының археологлары башкалабызның борынгы тарихын өйрәнү һәм аның мең еллыгын раслауда зур хезмәт куйды. Бүген Казанның «Тарихи шәһәр» исемен ныгыту өчен, әле тагын нинди эшләр башкарасы бар?

— Иске йортларны, тарихи-мәдәни һәйкәлләрне саклау буенча ВООПИиКның (Всероссийское общество охраны памятников истории и культуры) Татарстан бүлекчәсе бар. Кайсы йортны сакларга, кайсын сакламаска дигәндә, мин кайсы йорт безнең өчен кадерлерәк, кайсы йорт кадерсез булуын әйтә алмыйм. Бөтенесе дә ниндидер тарихи вакыйга яки зур шәхес белән бәйле.

Мәсәлән, мин яшәгән урамны алып карагыз. Безнең ишек алдында Горький торган, күрше ишек алдында Киров яшәгән. Әз генә астарак, хәзер Пушкин урамы инде ул, Шаляпин торган, Бауман туган. Безнең йорт каршысында Такташ яшәгән, хәзер ул йорт сакланмаган. Әз генә өскәрәк менсәң, Ирек мәйданы янындагы йортта Ленин шахмат уйнаган. Һәр йорт ниндидер шәхес белән, вакыйга белән бәйле. Бүтән урамнар да шулай ук. Татар бистәсен карагыз. Анда һәр йортта ниндидер шәхес яшәгән.

Бүтән шәһәр булса, халкы һәрбер йорт, ишегалды белән мактанып йөрер, туристларга сөйләр иде.

Күрәсең, без зур шәхесләр яшәгәнгә артык күнеккән — кадерен белмибез.

– Совет чорында Казан тарихчыларының фәнни эзләнүләре, гадәттә, ТАССР, Казан губернасы чикләрендә алып барылды. СССР таркалгач, элекке союздаш республикалар чит илгә әверелде. Димәк, фәнни бәйләнешләр өчен шартлар начарайды дигән сүз. Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең тарихи мирасын өйрәнү һәм Казанга кайтару юнәлешендә ниләр эшләнә?

— Аның белән күбрәк шунда яшәгән татарлар шөгыльләнә. Безнең Институт бөтенесен үз өстенә ала алмый. Бездә аның кадәр күп кеше дә юк. Фәнни юнәлешләр Татарстан Фәннәр академиясе аша уза, аларны Министрлар Кабинеты раслый, алар госзаказ белән бәйле. Шуңа Кытайга, Финляндиягә барып җитү чикләнгән.

Ләкин соңгы елларда татарлар арасында үз тарихы белән кызыксыну көчәйде. Күп нәрсә языла. Безгә, төбәк тарихын язучыларга, методик яктан ярдәм итүне оештыру мөһим. Ничек өйрәнүне өйрәтергә кирәк. Һәрбер төбәктә энтузиастлар булса, һәвәскәр тарихчылар, укытучылар, журналистлар төбәк тарихларын язып барса, без аларны туплый алабыз. Сайт эшләргә мөмкин. Бу турыда әле ныклап уйлыйсы бар. Себердә, Саратовта, Оренбургта, Кытайда төбәк тарихлары язалар. Без Татарстан буенча әле күп эшне эшләмәгәнбез.

– Татарстанда «Мирас» программасы эшләп килде. Шушы программа кысаларында Тарих институты галимнәре нинди проектларны тормышка ашырдылар? Бу программаның киләчәк язмышы нинди?

— «Мирас» программасының тәэсире яхшы булды. Безнең бюджетны карасаң, бер елга китап бастырырга 200 мең сум бирәләр. Аңа

«урта куллы» бер китап бастырып була. Ярдәм булмаса, том-том калын китапларны үзебез генә чыгара алмас идек. Аларны чыгару бик кыйммәт. Узган ел Тарих институты 55 китап бастырды. Аның кайберләре бик калын, кайберләре андый калын булмаса да, чыгымнар зур. «Мирас» программасы ул яктан яхшы ярдәм иде. Һәм проектлар өчен ярдәм булды. Аның әле тормыш өчен дә ярдәме тиде. Мәсәлән, туризм, музейлар, шәһәрләр тарихы буенча күп кенә нәрсәләр эшли алдык. Хәзер җиде томлык «Татар тарихы»ның VI, VII томнарын бастырырга, өметләнеп, акча көтәбез.

Киләчәк турында әйтүе авыррак. Универсиада якынлаша, акча кими. Шуңа «Мирас» программасына әле кул куелмаган. Ул кирәк микән, юк микән, дигән фикерләр бар. Минемчә, программаның кимчелеге булса, аны тикшерергә кирәк. Ләкин «Мирас» программасын, һичшиксез, саклап калу бик мөһим.

«Мирас» программасы тарихчылар өчен генә түгел бит. Әйтик, Мәдәният министрлыгы күбрәк фестиваль, төрле бәйрәм чаралары уздыру, кайда клуб ачу турында кайгырта. Ә, гомумән, мәдәният турында уйлаганда, аны бу кысаларда гына алып барып булмый. «Мирас» программасы безнең мәдәниятне киңрәк күрсәтә. Шуңа күрә бу программаны камилләштереп, киметмичә саклап калу шарт.

– Татарстан Фәннәр академиясенең Сез баш мөхәррир урынбасары булган «Фәнни Татарстан» журналы тарихи чыганаклар темасына еш мөрәҗәгать итәме? Гомумән, тарихи чыганакларны пропагандалауда нинди яңа чаралар, алымнар куллану мөһим?

— «Фәнни Татарстан» журналында күбрәк фәнни мәкаләләр бастырыла. Чыганаклар — алар махсус юнәлеш. Чыганаклар бастыру белән «Гасырлар авазы» журналы шөгыльләнә. «Фәнни Татарстан» журналының төп максаты — чыганаклар бастыру гына түгел, ә бөтен гуманитар фәннәрне берләштерү, академиядәге эшләгән институтларга бер төп юнәлешне алып барырга ярдәм итү. Мин шулай күзаллыйм.

– Ә чыганакларны пропагандалау буенча?

— Бу юнәлештә дә эш яхшы бара. Безне журналистлар ярата. Үзебезнең матбугат үзәге юк, аның кирәге дә юк. Газета-журнал битләрендә татар халкының тарихы һәм мәдәниятенә бәйле күпсанлы материаллар дөнья күрә, телевидениедә дә алар чагылыш таба. Без актив эшлибез. Зарланып булмый. Ниндидер махсус программа кирәк тә түгел. Конференция, семинар турында хәбәр чыкса, журналистлар шундук килеп җитәләр. Аларга бик зур рәхмәт.

Безнең Институтта, әлбәттә, бер килеп җитмәгән як бар. Төртеп күрсәтмәсәләр дә, без аны яхшы беләбез. Фәнни хезмәтләрне уку авыррак. Алар күбрәк галимнәргә атап язылган. Кайвакыт темасы бик тар. Берничә галим генә аңлый торган. Ансыз эшләп булмый, башкача фән була алмый. Ләкин шул ук вакытта популяр китаплар бик кирәк. Андый китапларны яза белә торган кешеләр — язучылар булырга тиеш. Алар күп түгел. Галимнәр гадирәк яза башласа, ул барыбер

КАЙСЫ ЙОРТНЫ САКЛАРГА, КАЙСЫН САКЛАМАСКА ДИГӘНДӘ, МИН КАЙСЫ ЙОРТ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН КАДЕРЛЕРӘК, КАЙСЫ ЙОРТ КАДЕРСЕЗ БУЛУЫН ӘЙТӘ АЛМЫЙМ. БӨТЕНЕСЕ ДӘ НИНДИДЕР ТАРИХИ ВАКЫЙГА ЯКИ ЗУР ШӘХЕС БЕЛӘН БӘЙЛЕ.

фәнни булып чыга. Шуңа күрә бу ике арада берничә кеше булсын иде.

Шул ук вакытта фәнни-популяр китап сериясе, әлбәттә, кирәк. Бу хакта күп уйлап йөрим. Кайбер китапларны чыгара да башладык. Ләкин әле бу эш юнәлешен колачлы дип әйтеп булмый.

Интернет тормышыбызга нык үтеп керде. Китаплар популяр булсын, халыкка барып җитсен өчен, шушы күзлектән дә карап уйларга, эшне оештырырга кирәк.

– Рафаил Сибгатович, урта гасырлар татар тарихына бәйле тарихи чыганакларны барлау, Татарстанга җыю, кабат бастырып чыгару юнәлешендә нинди уңышлар, проблемалар бар?

— Төп эш Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыныкы. Без дә урта гасыр чыганаклары белән эшлибез. Биредә махсус бер бүлек, төркем булса яхшы. Тарих язучы галим генә моны булдыра алмый. Вакыт күп кирәк. Борынгы гарәп теле хәзерге гарәп теленнән аерыла, борынгы фарсы телендә дә язылган, латин чыганаклары да күп, Төркия архивларындагы документлар борынгы төрки яки гарәп телендә. Белгеч әле телне генә түгел, тарихны да белергә тиеш. Чыганакны язганда, аңлатма бирү сорала. Бу бик зур һәм авыр эш дияр идем. Чыганакны кайтару бер хәл. Башта Истанбулда, Иранда яки Генуяда, Венециядә, Ватиканда утырырга кирәк. Әле ул чыганакны аңларга кирәк. Эш, әлбәттә, бара, бармый дип әйтмәс идем. Ләкин безнең көч кенә җитми. Кайтару бер хәл, ул тарихи мәгълүматларны хезмәтләргә кертү тагын да авыррак. Иң мөһиме шул.

Әле ИЯЛИ Мирасханәсендә күпме чыганак кайтарылган һәм күпмесе тикшерелгән — монысы да бик мөһим. Без бу якны да күздә тотарга тиеш. Чыганакны кайтарабыз, ул еш кына шүрлектә ятарга мәҗбүр.

– Сезнеңчә, кайсы тарихи шәхесләребезнең эшчәнлеге, мирасы әле игътибардан читтә калып килә?

— Шәхесләр турында әз язылган дип әйтмәс идем. Алар турында бүген яңача язарга кирәктер, заманча итеп. Шәхесләр турында күп кенә китаплар чыкты. Алар, кызганычка каршы, еш кына зәгыйфь. Яки материал җитеп бетми, яки без аларны аңлап бетермибез. Сәясәткә өлеш керткән кешеләр турында язабыз, язучылар турында. Ә менә эшмәкәрләр читтә кала бирә. Алар да бит шәхес. Татар мәгариф системасын кем финанслаган? Ул бит капчыктан алып акча бирү генә түгел, менә — теләсә нәрсә эшлә, дип. Юк, ул үзе инициатива күрсәткән: аңа мәдрәсә кирәк булган, гәзит кирәк булган. Ул байлар акча эшли торган бай гына түгел, алар бит татар халкының киләчәген уйлый торган шәхесләр булган. Безгә бу яктан да киңрәк карарга кирәк. Шәхес дигәндә, бәяләү төрлечә булырга мөмкин. Бөтен татар халкы өчен танылган зур шәхесләр бар. Ә бит һәр төбәктә шәхесләр булган. Аларның кылган гамәлләре шул төбәк халкы өчен бик кадерле. Андый шәхесләрнең тормыш юлы яшь буын өчен бик яхшы тәрбия үрнәге дә булып тора. Минемчә, шәхесләргә төрле яктан карарга һәм бәяләргә кирәк.

– ТАССР оешуга 90 ел тулу, Татарстан Республикасының юбилее, совет һәм хәзерге чор чыганакларын барлау һәм саклауны көн кадагына

куйды. Бүген «суверенитет чоры» дип аталган елларда Сез Татарстан Президентының сәяси мәсьәләләр буенча Дәүләт киңәшчесе булып эшләдегез. Сез – ул еллардагы Татарстан – Россия арасындагы мөһим тарихи документларны төзүче, киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган тарихи чыганакларны белүче шәхес. Бу өлкәдә, беренче чиратта, кайсы тарихи материалларны бастырып чыгару мөһим дип санныйсыз?

— Аларның кайберләрен бастырдым да инде. Хәзер тарихчылар бу документларны фәнни күзлектән карап өйрәнергә тиеш. Әлбәттә, Тарих институтының директоры булу файдалы булды. Чыганакларның кадерен белеп, аларны Дамир Рәүф улы Шәрәфетдинов белән (ул Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең директоры иде) җыя башладык. Документлар аерым фонд булып хәзер архивта саклана. М.Ш.Шәймиевнныкы гына түгел, минекеләр дә. Дөрес, ул документлар әлегә ачык түгел. Ләкин аларны ачарга да була.

Бер тапкыр Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинның кирәкмәгән эш кәгазьләрен ташлаганын күрдем. Әйттем: Фәрит Хәйруллович, болар Сезнең өчен артык кәгазь булса, тарих өчен алар мөһим документ булырга мөмкин, дим. Архив өчен алар бик кадерле.

Документлар җыелып бара. Кайберләрен җыюга үз өлешемне дә керттем. Әйтик, Тышкы эшләр буенча департаментның эш кәгазьләрен барлап, китап чыгардык. Чит илләр белән төзелгән шартнамәләрне бастырдык. Әлбәттә, бөтенесен бастырып та бетереп булмый. Күбесе охшаш. «Белая книга» исемле документлар җыентыгы чыгарган идем. Аны, тагын да баетып, кабат бастырырга мөмкин.

Өйдә караламалар белән бер папка саклана иде, диссертация язганда, кемгәдер бирдем һәм кайтармадылар. Анда Декларациянең иң беренче вариантлары бар иде.

1990 елгы документларга бәяне тарихчылар бирергә тиеш. Безгә, «эчтән караганга», бәяләү кыен. Читтән карап бәяләү сорала.

– Рафаил Сибгатович, өр-яңа «Мирас» журналы чыга башлады. Редколлегия әгъзасы буларак, журнал хезмәткәрләренә Сезнең нинди теләкләрегез бар? Безгә кайсы темаларга күбрәк мөрәҗәгать итәргә кирәк дип санныйсыз?

— Иң әүвәл без Татарстанны, татарлар яшәгән төбәкләрне өйрәнергә тиеш. Бөтендөнья күзлегеннән караганда, ул бик мөһим дә булмаска мөмкин. Ләкин кеше өчен, гади халык өчен ул — шундый ук тарих, шундый ук кадерле, мөһим эш. «Мирас» журналы шуның белән шөгыльләнсә, искиткеч яхшы булыр иде. Әле аның әһәмиятен үзебез дә ахыргача аңлап бетермибез. Зур тарихны күрмәгәч, аңлап бетермәгәч, һәрбер авыл тарихы да яхшылап өйрәнелмәгән, аның методикасы да эшләнеп бетмәгән.

Институтка эшмәкәрләр, укытучылар, төбәк тарихын өйрәнүчеләр китапларны кайдан гына җибәрмиләр. Киләчәк турында уйласак, һәр төбәкнең тарихы язылырга тиеш. «Мирас» журналы шуны башласа иде. Монда Тарих институтының гына көче җитмәячәк, журналистлар да,

укытучылар да кирәк. Бәлки, интернет аша да хезмәттәшлек юлларын уйларга кирәктер. Без Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергә инде күп еллар татар тарихын өйрәнү буенча республика конкурсы уздырабыз. Җиңүчеләргә диплом да бирәбез. Ләкин бу бер юнәлеш кенә. Иң яхшы үрнәкләрне «Мирас» журналы бастырса, яхшы булыр иде.

Кайбер авыл тарихлары татар тарихының бөтен нечкәлеген, аерым вакыйгаларны гына түгел, татар тормышын төрле яктан чагылдыра. Шуңа күрә бу методика, методология күзлегеннән караганда да зур эш.

Бу эшкә туристларны җәлеп итү эше дип карап та була. Читтән килгән туристлар өчен түгел. Татарлар Тукай белән кызыксыналар, Мәрҗани, Курсави белән. Күп нәрсәне шәхесләр аша күрсәтеп була. Татарстанда яшәүче халык республикабызны яхшылап белми, аны күрмәгән дияргә була. Телевизордан гына күрә. Барып, күреп, эчтән белеп аңлау әле җитеп бетми. Шуңа күрә безгә этәргеч ясарга кирәк.

Шәхесләр турында әйттем инде. Әле аңлашылмаган, халыкка барып җитмәгән темаларны күтәрә алабыз. Эшмәкәрләр, ак байлар турында. Кеше байый, халык турында, республика турында да — берни турында да уйламый. Әле чит илгә качарга омтыла. Революциягә кадәр татар байлары халкы турында уйлаган, шул ук вакытта баеган да, ярдәм дә иткән. Бу бик кызык феномен. Кызганычка каршы, бу феномен яхшылап өйрәнелмәгән һәм яктыртылмаган. Аларны үрнәк итеп күрсәтү мөһим.

Күп эшмәкәрләр Тарих институтына килеп кызыксына, безнең тарих нинди булган, дип сорый. Күренеп тора, ул баерга гына уйламый, үткәнгә, бүгенгегә үз карашын булдырырга тырыша.

Авыллар, төбәкләр тарихы турында әйттем инде. Без бит татар тарихы дигәндә, Казан күзлегеннән карыйбыз яисә бер ике-өч шәһәр күзлегеннән. Ярый әле галимнәр белән берлектә кайбер район тарихлары язылган. Алар җитеп бетми.

Дөресен әйткәндә, без Татарстан тарихын да әле тиешенчә белеп, аңлап бетермибез. Казан ханлыгы административ яктан ничек бүленгән, аны да анык белмибез. Ничә даруга булган? Алар белән кем идарә иткән? Бәкләр утырганмы? Даругалар соңрак нинди үзгәрешләр кичергән? Күп нәрсә әле ачылмаган.

Татар тарихына да, Татарстан тарихына да без һаман да Казан күзлегеннән карыйбыз. Минемчә, моны үзгәртергә кирәк.

– Бик зур рәхмәт, Рафаил Сибгатович, Сез күтәргән мәсьәләләр һәм Тарих институтының эшчәнлеге «Мирас» мәйданында киң яктыртылыр. Халкыбызга үз тарихын кайтарып бирүдә без бергә булырбыз дигән ышанычта калабыз.

Әңгәмәдәш —
Илдус Заһидуллин

АК СӨЛГЕ

РЕНАТ ХАРИС

Ихтирамымны белгертим
Хак сүз белән:
Кунак килсә каршыладың
Ак йөз белән;
Дошман килсә чыкмадың
Кулын юарга,
Һәм булмадың ак төстәге
Сатлык байрак!
И ак сөлге, беркайчан да
Пычранмадың —
Күпме сөрттең гаделләрнең
Хәләл канын!
Син көрәштең Сабантуйда,
Билгә яттың.
Көрәшченең гаделлеге,
Көче артты.
Көрәшләргә озатып калдың
Син ирләрне,
Сау бул, диеп, кулга кушылып
Җилфердәдең.
Җилфердәдең кызыл туйлар
Пар атында,
Әверелеп туйның бәхет
Канатына...
Җеназада син, ак сөлге,
Безнең кулда.
Озатасың гүр иясен
Соңгы юлга...
Кичерешләрнең таныш сиңа
Һәркайсысы,
Илемнең һәрбер шатлыгы,
Һәр кайгысы.
Син бит үзең дә халкымның
Күңеле төсле —
Сөттән сеңгән зур пакьлекнең
Бер көзгесе.
Һәрбер эшнең, һәр ниятнең
Өмете — уңыш.
Кешеләрнең нияте зур,
Сөлге,
Булыш!

1812 ЕЛНЫҢ ИЮНЕНДӘ НАПОЛЕОН АРМИЯСЕНЕҢ РОССИЯГӘ БАСЫП КЕРҮЕ ИЛ ӨЧЕН ГАЯТЬ ЗУР КУРКЫНЫЧ ТУДЫРА. СУГЫШНЫҢ БЕРЕНЧЕ КӨННӘРЕННӘН ҮК РОССИЯ ХАЛКЫНДА ПАТРИОТИК ХИСЛӘР КӨЧӘЕП КИТӘ. ШУЛ ИСӘПТӘН ТАТАРЛАР ДА БӨТЕН ИЛ ХАЛКЫ БЕЛӘН БЕРГӘ КӨРӘШКӘ КҮТӘРЕЛӘ.

1812 ЕЛ ВАТАНГЫ СУГЫШЫНДА ҖИҢҮГӘ 200 ЕЛ

1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫНДА ҺӘМ 1813-1815 ЕЛЛАРДАГЫ РУС АРМИЯСЕНЕҢ ЧИТ ИЛ ПОХОДЛАРЫНДА ТАТАРЛАР

ИЛШАТ ФӘЙЗРАХМАНОВ,
тарих фәннәре кандидаты



Петр I чорыннан алып 1874 елга кадәр төп өлеше дәүләт крестьяннары саналган татарларның армиягә дәүләт алдында рекрутлар бирү йөкләмәсе булган. 1793-1834 елларда армиядә хезмәт итү вакыты 25 ел тәшкил иткән. Гадәти елларда мең кешедән 5-7 кеше армиягә алынса, сугыш алдыннан һәм сугыш вакытында көчәйтелгән (1 мең ревизия җанынннан 7-10 кеше) һәм өстәмә (1 мең ревизия җанынннан 70 кешегә кадәр) рекрут наборлары үткәрелгән. 1812 елда исә 3 тапкыр армиягә алу була: 82 нче (1 мең кешедән дүртешәр рекрут), 83 нче (1 мең кешедән 20 рекрут), 84 нче (1 мең кешедән 16 рекрут)[1]. Даими армиядә хезмәт итүче татар солдатлары Наполеон гаскәрен җиңүгә зур өлеш кертә.

1812 елның сентябрендә Казан ополчениесен җыю башлана. Ополчениегә крепостной крестьяннар (100 кешедән 4се) алына. Дәүләт крестьяннары, шул исәптән татарлар, ополчениегә чакырылмый, шулай да шәһәрдә яшәүче мещаннардан, һөнәрчеләрдән баручылар була. Мәсәлән, Нигабидуллина фамилияле мещан сословиесеннән татар хатыны ополчениегә олы улын бирә. Алай гына түгел, Татар шәһәр ратушасына барып, кече улын да ополчениегә алуларын сорап йөри[2].

1812 елның көзенә Казанга Мәскәүдән һәм Смоленскидан 30 меңләп качак китерелә. Казанда качакларга зур ярдәм күрсәтәләр: монастырьларга һәм казанлылар йортларына урнаштыралар.

Сугыш башыннан алып армия, ополчение һәм зыян күрүчеләргә ярдәм итү өчен иганә кампанияләре үткәрелә. Казан губернасы буенча барлык иганә җыемнары 346 мең сум тәшкил итә. Җыйналган алтын-көмеш арасында татар хатын-кызлары тапшырган бизәнү әйберләре дә була. Армия өчен кирәк-ярак җыю ирекле-мәҗбүри характерда алып барыла. Казанның татар общинасыннан 1812 елның 3 июленә 2 нче Кострома пехота полкын оештыруга 4100 сум җыела. 1812 елның 21 августында Татар шәһәр ратушасына караган сәүдәгәрләрдән мәҗбүри 8360 сум җыю карала. Шәһәрнең рус мещан сословиесе общинасы 10 мең сум тирәсе ярдәм акчасы җыеп бирә[3].

Франция белән сугыш чыгар алдыннан, бай Казан сәүдәгәрләренең күбесе Мәкәрҗә ярминкәсенә киткән була. Ярминкәдә Түбән Новгород губернасы ополчениесенә иганә акчасы җыела. Ярдәм итүчеләр арасында ярминкәгә Түбән Новгородтан, Мәскәүдән, Казаннан, Тобольскидан, Иркутскидан һ.б. төбәкләрдән килгән сәүдәгәрләр була. Иганәчеләр исемлегендә Казанның I гильдия сәүдәгәре Муса Исмәгыйль улы Апанаев (520 сум), Малмыж шәһәренең I гильдия сәүдәгәре Муса Үтәмышев (500 сум), Арча шәһәренең I гильдия сәүдәгәрләре Мөхәммәтрәхим Мәмәшев, Мортаза Борнаев, Габделкәрим Бакаров (йөзәр сум) һ.б. исемнәре язылган.

[1] Полное собрание законов Российской империи. Собрание 1-е. Т.32. — №25198.

[2] Городчанинов Г. Казанское ополчение // Газета «Республика Татарстан». — 2002. — 12 сент.

[3] Валиуллин И. «На пожертвование в пользу Отечества» (Татарская община г. Казани в 1812 г.) // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 2009. — № 1. — С.10-12.

1812 елның 8 августында Мәкәрҗә ярминкәсенең Татар сабын рәтеннән генә дә Казаннан килгән татар һәм рус сәүдәгәрләре 5690 сум тапшыра. Мәкәрҗә ярминкәсе барышында җәмгысе 72746 сум иганә акчасы җыела. Чагыштыру өчен: Түбән Новгород губернасы буенча җыемнарның гомуми күләме 875 мең сумнан артып киткән[4].

Татарларның бер өлеше сугыш хәрәкәтләрендә даими булмаган хәрби формированиеләр составында катнаша.

Башкортлар, мещерякләр, типтәрләр, татарлардан торган казак полклары французларга каршы генераллар П.И.Багратион, А.И.Тормасов, М.Б.Барклай де Толли армияләре составында сугышкан. Монда берничә төркем хәрби көч була: башкорт һәм мещеряк полклары, Оренбург казак гаскәре, типтәр казак полклары.

Мөселман хәрби формированиеләрдән, беренче чиратта, башкорт һәм мещерякләрдән торган полкларны атап үтәргә кирәк. Алар Пермь, Оренбург һәм Вятка губерналарында 1798 елда кантон системасы төзелгәч оештырыла[5]. Гаскәрләрне Оренбург саклану линиясе буенча казахлар белән ике арадагы чикне саклауда файдаланалар.

[4] Сенюткина О.Н., Загидуллин И.К. Нижегородская ярмарочная мечеть — центр общения российских и зарубежных мусульман (XIX — начало XX вв.). — Нижний Новгород, 2006. — С.30.

[5] Полное собрание законов Российской империи. Собрание 1-е. Т.27. — №18477.



Хәрби министрлыкның 1812 елның 25 июль боерыгы нигезендә 3, 4, 5 нче башкорт полклары оештырыла. Шул ук елның июлендә өстәмә атлы полклар оештыру тәкъдиме белән Оренбург казак гаскәре атаманы В.А.Углецкий чыга. Аның тәкъдимен Александр I хуплый. Инде 1812 елның август-сентябрендә 1 нче, 2 нче мишәр һәм тагын 15 (6-20 нче) башкорт полклары оештырыла. Һәр полкта 530 кеше исәпләнелә (500 рядовой, полк начальнигы, старшина, 5 есаул, 5 сотник, 5 хорунжий, 10 пятидесятник, квартирмейстер, писарь һәм мулла)[6].

Башкорт һәм мещеряк полкларының махсус мундиры булмый, алар үзләренең милли киемнәрен киеп сугышка китә, сөңге, кылыч, ук-җәя белән коралланган була. Мылтык һәм пистолетлар бик сирәк сугышчыда гына була. Чөнки хөкүмәт аларга кораллану өчен акча бирми.

Башкорт полклары французлар белән күпсанлы бәрелешләрдә катнаша: французларны Россиядән куганда, Березина янында бәрелештә, рус армиясенең Чит ил походында, шул исәптән 1813 елның 4-7 октябрь көннәрендә «Халыклар сугышы» исеме белән тарихка кереп калган Лейпциг сугышында һ.б. Алар шулай ук әсирләрне саклыйлар, каравыл һәм тәртип саклау вазифаларын башкаралар[7].

Оренбург казак гаскәре күп милләт вәкилләреннән торган. 1799 елда гаскәргә Оренбург губернасының ясаклы крестьяннары һәм татарлары кертелә. Французларга каршы Оренбург казак полклары составында татар-мөселманнардан тыш ногайбәкләр — чукындырылган татарлар да катнаша. Ногайбәкләр походтан соң туган якларына кайткач һәм күпмедер вакыттан соң яңа урынга күченгәч, поселокларын үзләре җиңүчеләр буларак үткән Европа шәһәрләре исемнәре белән (Париж, Берлин, Фершампенуаз, Арси, Кассель һ.б.) атыйлар.

XVIII гасыр ахырында оешкан типтәр полклары статуслары буенча регуляр һәм иррегуляр кавалерия гаскәрләре «арасында» булалар. Бер яктан, аларга хәрби мундир, корал бирелгән, билгеле бер хезмәт итү срогы (15 ел) билгеләнгән, икенче яктан, полкның тәэмин ителеше, аның типтәрләр һәм бобыльләр сословиесе вәкилләреннән генә оешканлыгы, чиннар һәм оештыру тәртибе иррегуляр гаскәрләрдәге сыман булган[8].

Сугыш башланганда 1 нче типтәр полкы инде генерал М.Б.Барклай де Толлиның 1 нче Көнбатыш армиясе составында була. Бородино сугышында әлеге полк М.И.Платов һәм Ф.П.Уваров җитәкчелегендәге рус атлы гаскәренең француз тылына рейдында катнаша. 1812 елның сентябрь-октябрь айларында хәзерге Калуга өлкәсендә һәм янәшәдәге Смоленск, Мәскәү өлкәләрендә 1 нче типтәр полкы башка частьлар белән бергә актив хәрәкәт итә. Аларга дошман тылына һөҗүмнәр оештыру, француз армиясен азык-төлек, корал белән тәэмин итүне тоткарлау, мародерлар белән көрәш вазифалары йөкләнә[9].

[6] Усманов А.Н. Башкирский народ в Отечественной войне 1812 г. —Уфа, 1964. — С.56.

[7] Бекмаханова Н., Кобландин К. Французской кавалерии лучше бы не сходиться со степняками // Татарский мир. — 2002. — №3. — С.5.

[8] Рахимов Р.Н. История тептярских конных полков. 1790—1845. — Уфа, 2008. — С.188.

[9] Ахметшин Ш.К., Насеров Ш.А. Татары на службе Отечеству. Долг. Отвага. Честь. Страницы истории татарских воинских частей в Российской армии и Императорской гвардии. — СПб., 2006. — С.165-166.

2 нче типтәр полкы 1812 елның сентябрендә Денис Давыдовның партизан отряды составында Вязьма шәһәре янында һәм Яңа Смоленск юлында французларга каршы хәрәкәт итә. Аннары полк ополченецлардан һәм иррегуляр гаскәрләрдән торган махсус корпус составында Смоленск губернасында дошманга каршы сугыша.

Күп татар сугышчыларының батырлыкларын командирлары югары бәяли. Мәсәлән, Вязьма өчен сугышта 1 нче типтәр полкы есаулы Сәгыйть Халитов үзен таныта — III дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнә[10]. Рославль шәһәре янында күрсәткән батырлыклары өчен полк командиры майор Тимиров — IV дәрәҗә Изге Владимир ордены белән, прапорщик Мөнасыйпов III дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнә, зауряд-хорунжий Ибраһимовка — хорунжий чины бирелә[11].

[10] Бекмаханова Н., Кобландин К. Күрсәтелгән хезмәт. — Б.5.

[11] Народное ополчение... — Б.161-162.

1814 елның 18 мартында 4 нче һәм 5 нче башкорт, 1 нче һәм 2 нче типтәр полклары Россия гаскәре составында Парижга керәләр. Бу полк сугышчылары «1814 елның 19 мартында Парижны алган өчен» дип язылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

Шулай итеп, чик буен саклауда зур тәҗрибә туплаган атлы типтәр полклары, кавалерия һөҗүмнәре вакытында үзләренең югары дәрәҗәдә хәрби әзерлекле булуларын күрсәтәләр.

Наполеон Франциясен җиңүгә кырым татарларының дүрт атлы полкы да зур өлеш кертә. Бородино сугышында татар җайдаклары, французларның тылларына рейд ясауда катнашып, сугышка француз императоры гвардиясенең катышып китүен тоткарлауга зур өлеш кертә.

1812 елда Россия регуляр кавалериясе составында литва-польша татарларыннан торган Татар улан полкы була. Татар улан полкы сугыш башында генерал А.П.Тормасовның 3 нче Резерв армиясе авангардына керә, 1812 елның җәендә полк Кобрин янындагы, Литвадагы Городечке авылы янәшәсендәге сугышларда катнаша, Наполеонның төп көчләре белән бәрелешү французларның Березина елгасын кичкән вакытта була. Татар полкы уланнары дошман гаскәренең флангларына «кинжал» ударлар ясый һәм шунда ук кире үз позицияләренә кайта.

Литва-польша татарларының Наполеон ягында сугышучылары турында да әйтеп китәргә кирәк. 1812 елда Наполеон армиясе составына кергән аерым татар эскадроны (штаты: майор, 4 капитан, 7 лейтенант һәм су-лейтенант, 110 түбән чин) полковник Мостафа Әхмәт улы җитәкчелегендә сугыша. Вильноны саклаганда, эскадрон зур югалтуларга дучар була (10 офицер һәм 50 рядовой). Француз полкы составында эскадрон Германия, Франция территорияләрендәге сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, 1815 елда туган якларына кайтарып таратыла.

Сугышка Урал-Идел төбәгеннән киткән татарларның Наполеон армиясенә каршы сугышулары «Любизар», «Голубец,

молодец» кебек халык җырларында чагылыш тапкан. Патриотизм хисе белән сугарылган «Рус-француз сугышы бәете» татарларның рус армиясе җиңүенә керткән өлешен ачып бирә:

[...] Французлар килеп кергән Мәскәү дигән калага;
Безнең гаскәр килгәчтен, алар качты далага. [...]

Урамнарын тутырса да французлар Мәскәүнең,
Унике типтәр бетерде французның гаскәрен.

Дүрт-биш кердек сугышка, каннар билдин актылар,
Сугышларны бетергәч, безгә медаль тактылар.

Французның атлары бар да ефәк тышаулы;
Французның солдатлары офицерга охшаулы. [...]

Французлар монда килгән, таныдылар үзләрен,
Уңда — башкорт, сулда — типтәр, табалмыйдыр эзләрен.

Французның илләре, түгәрәк икән күлләре,
Французларны куганда үттек без күп илләрне. [...]

Французның атлары кырын җирдә дулыйдыр,
Башкорт белән типтәрләр французны турыйдыр. [...]

Наполеонның эшләпәсе канга тапланган иде;
Без сугыштан кайтканда, илләр шатланган иде. [...]

Шулай итеп, 20 башкорт (аларның 13 е хәрби хәрәкәтләрдә катнаша), 2 типтәр һәм 2 нче мещеряк полклары, 4 кырымтатар полкы, литва-польша татарларыннан торган Татар улан полкы 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813-1814 еллардагы Чит ил походларында катнаша (1 нче мещеряк полкы Мәскәүдә калдырыла). Мөселман руханилары бу полкларда дини бурычларын үтәгәннәр, дин кардәшләрен Ватан һәм патша өчен көрәшкә рухландырып торганнар.

Ил-Ватан өчен көрәш, 200 ел элек безнең бабаларыбыз кылган батырлыклар, Россия дәүләтчелеген тагын да ныгыткан, бүген дә халык хәтерендә якты истәлек булып саклана. Тарихның аннан соңгы вакыйгалары, XX гасырның I, II Бөтендөнья сугышларында милләтебезнең сугышчан батырлыгы традицияләре тагын да ачыла. Г.Тукайча әйтсәк: «Уртак Ватанда, аның тарихында — без эзлебез». Уртак Ватанда безнең хокукларыбыз да тиң һәм гадел булырга тиеш.

БӨТЕНДӨНЬЯ САБАН ТУЙЛАРЫНЫҢ БАШКАЛАСЫ – КАЗАН!

РАВИЛ РАХМАНИ

Миллионнарның күңел тынычлыгы,
Килер бәх(е)те, Казан,
синнән башлана;
Дуслык уты ягып йөрәкләргә,
Яктыртасың җанны, Башкала!

Җир шарының гүзәл гөлбакчасы,
Дусларыңны, Казан,
тартып китердең;
Хезмәт сыен Сабан туең аша
Һәр күңелгә илтеп җиткердең!

Ярасы син канлы көрәшләрнең,
Байрагы син, Казан,
безнең дәвернең!
Бөтендөнья Сабан туйларының
Башкаласы булып әв(е)релдең!

Р.Якупов фотосы

«КАДИМЧЕЛӘР ДИЙАРЫННАН» БЕР ӘСӘР

ӘЛФИНӘ СИБГАТУЛЛИНА,
тарих фәннәре докторы

XIX гасыр ахыры — XX йөз башында татар җәмгыятендә ике фикри юнәлешнең кадимчеләр һәм җәдитчеләр лагеры буларак мәйданга чыгуы, иң беренче чиратта, шул чорда күтәрелгән тәгълим-тәрбия һәм дин мәсьәләләрендәге бәхәсләргә барып тоташа. Җәдитчеләргә гел югары бәя биреп, кадимчеләрне даими хурлау заманнары инде хәзер узып бара: кадимчелек булмаса, җәдитчелек тә барлыкка килә алмас иде дигән фикер дөреслеккә ныграк якын тора кебек тоела. Ләкин, кызганычка каршы, кадимчеләр станыннан булган шәхесләрнең хезмәтләре һаман әле читкә кагыла, өйрәнелми кала бирә. Аларга мөрәҗәгать итүнең шул чор фикер хәятын тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итәчәге шөбһәсез. Шундый әсәрләрнең берсе — «Китабел хәдид ли әбталел җәдид, яки Мисыр карга-

1. Кадимчеләр бу «хәдид-җәдид» рифмасын ятраткаңнар шикелле: 1899 елда Казанда зур тираж белән кадимче идеологлардан Гыйләҗетдин Мөхетдиновның «Ән-нөсүл хәдидә фи хилаф әл-ысул әл-җәдидә» («Яңа методкага каршы тимер сөңгеләр») исемендә бер китап бастыруы билгеле. Кара:

сы» («Җәдитчеләргә каршы тимердәй нык китап, яки Мисыр каргасы») [1] дип аталган, Х.И. наширлегендә Казанда бертуган Кәримевләр матбагасында 1909 елда чыккан 36 битлек бер шигъри әсәр игътибарымны җәлеп итте. Тукай тарафыннан «Авыл җырлары»ның дүртенче көлтәсендә «Карга» дип «чеметелгән» бу китапның «Яшен», «Ялт-йолт», «Әл-ислах» битләрендә дә телгә алынуы билгеле [2]. XX гасыр башы татар җәмгыятенең көн кадагына суккан теманы күтәргән, ләкин бүген инде онытылган әлеге әсәрнең эчтәлеге белән якыннанрак танышу белән бергә, аның әдәбилеге мәсьәләсен дә күзәтергә мөмкин, ягъни текстка «кадим-җәдид» бәхәсе күзлегеннән генә чыгып бәя бирмичә, аны татар әдәби теленең формалашу этабына караган бер үрнәк буларак та тикшерергә мөмкин, дип уйладым.

Беренче карашка ук, ул миңа рифма-кафиясе шактый гына шома (аааб, вввб), үткен һәм җор тел белән язылган бер әсәр булып күренде:

Бер Ходага тапшырып яздым китаб,
Хәвасләргә [аксөяк], гавәмнәргә [кара халык] булсын хитаб [эндәшү, мөрәҗәгать итү],
Кыйлсалар да без фәкыйрьне анлар гыйтаб [шелтә, әрләү],
Калебемдә [йөрәк] милләтемнең гайрәте бар.

Авторы күрсәтелмәгән һәм шуның аркасында күп кенә гөманнарга урын калдырган [3] бу китапчыкта «Мисыр каргасы» дип Муса әфәнде — Муса Ярулла улы Бигиев (1875-1949) атала. Татарларда Мисырда укып кайтучыны «Мисыр каргасы» дип, Гарәбстанда укыганны «Гарәбстан песие» дип атау таралганлыгын искә алсак, кушаматның Муса Бигигә нигә тагылуы аңлашыла: ул — Каһирәдә атаклы Әл-Әзһәрдә белем алган кеше. Нәкъ менә Мисырда вакытта Муса Биги, Милли китапханәдә Коръән тарихы белән бәйләнешле китапларны өйрәнеп, соңыннан «Тарих әл-Коръән вә әл-мәсахиф» («Коръән һәм күчермәләренең тарихы») китабын яза.

1908-1909 елларда Муса Биги Казан, Чистай һәм Оренбург арасында күп йөри, «Шәрык китапханәсе»ндә китаплар бастыра, төрле очрашулар уздыра, соңрак «Хөсәения»дә укыта ук башлый. Бу вакытта актив рәвештә Коръән басмаларында киткән график хаталарны төзәтү юнәлешендә һәм «Әл-Лөзүмийәт» китабының авторы атаклы философ имам Әбелгалә әл-Мәгарринең тәрҗемәи хәлен язу өстендә эшләп, китаплар хәзерли. Кадимчеләрнең «Мисыр каргасы» китабы нәкъ менә шул уңайдан, ягъни Муса Бигинең 1909 елда Казанда басылып чыккан «Тәсхих рәсм хатт әл-Коръән» исемле әсәренә каршы язылган дип әйтергә мөмкин. Бигиевнең бу хезмәте турында

Мухаметшин Р.Г. Проблемы татарского традиционализма на страницах журнала «Дин ва магишат» (1906-1918). — Дисс. канд.ист.наук. — Казань, 2004. — С.82.

2. Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда: 2 том: Шигырьләр. Поэмалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. — 400 б.

3. Тукай әсәрләренең яңа алты томлыгында бу китапның «Аксак Низами (Яшел Низами) дип йөртелгән бер кадимче сәүдәгәргә нисбәт ителүе» әйтелә. Кара: Габдулла Тукай. Әсәрләр. Академик басма. 6 томда: 2 том. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2011. — 331 б.

Тукай да «Авыл җырлары»ның өченче көлтәсендә телгә ала:

Арыслан белән юлбарыс яратылган бер каннан;
Безнең Муса һич тик тормас: яңлыш тапкан Коръәннән.

Безнең кулыбыздагы китапта исә болай диелә:

Мәмләкәткә шөһрәтен тәмам чәчде,
Ничә кәррә [тапкыр] мәҗлесләрдә булып кәчде,
Йөзләп хата табам дип Коръән ачды,
Андин артык батил ялган сүзләре бар.

Бигиев әсәре татар руханилары арасында зур шау-шу куптара: Коръән басылган текстларда йөзләп хата таптым дип әйтергә җөрьәт иткән кешене тыңларга һәм «тәртибен тикшерергә» теләүчеләр күп табыла: 1909 елның 7 һәм 21 февральләрендә сәүдәгәр М.Юнысовлар өендә ике зур җыелыш булып, һәрберендә өчәр йөзләп кеше катнаша [4].

Китап авторы үзенең бу вакыйгага ничек килеп эләгүен гап-гади тел белән аңлатып бирә:

Кантурга төшкән идем, гәзит алдым,
«Тәсхих» [төзәтү] дигән мәкаләгә күзем салдым,
Бер көндән соң дәхи дәгъвәтнамә алдым,
Фәлән көнгә Муса Биги дәгъвәте [чакыру] бар.

Җыелышка килүчеләр Муса Биги хезмәтенә мөнәсәбәтле рәвештә икегә бүленә. Муса тарафдарларының аны яклап чыгуы китап авторына, әлбәттә, ошамый:

Мусаны югарыга утырттылар,
Синдән галим кеше юк дип күперттеләр,
Хатаны күбрәк тап, дип котырттылар,
Югарыдан түбән төшәр көннәре бар.

Кадимче авторның Муса Бигине Шиһабетдин Мәрҗанигә каршы куюы күренә һәм бу башта гаҗәп кебек тоела:

Мәҗлестә Мәрҗанине таптадылар,
Муса таба барыр кадәм [адым] атладылар...

Чөнки Мәрҗанинең заманында үзенең дә кадимче доносларыннан иза чиккән шәхес булуын бүген һәркем белә, монда исә китап авторы галимнең дөньякүләм мәшһүрлегенә таныклык итә:

4. Шул чор татар вакытлы матбугатында да тәфсилле рәвештә чагылыш тапкан бу «тарихи» җыелышлар хакында Муса Бигиев эшчәнлеген анализлаган галим А.Хәйретдинов язды. Кара: Серия «Антология татарской богословской мысли». Муса Джаруллах Бигиев. Избранные труды. В 2-х томах: Т.1 / Пер. с осман. — Казань: Татар. кн.изд-во, 2005. — Кереш мәкалә.

Мәрҗанинең тәгълимләре [өйрәтү] мәгъләм [маяк] улды,
Хәрамәин һәм Хиҗазда мәгълүм улды,
Тәснифләре [әсәр, китап] Йаурупага тәмам тулды,
Исламбулда андин артык шөһрәте бар.

Мәрҗани белән Муса Бигинең болай кискен каршы куелуы Мәрҗанинең дә Коръәнне бастырганда киткән хаталарны төзәтүгә багышланган шундый ук китабы — «Тәсхих Мусхаф» («Изге китапны төзәтү») булуы белән бәйле булып чыкты. Бигиевнең Казанда, хәтта Истанбул һәм Каһирәдә басылган Коръән китапларында киткән хаталарны тикшерүгә багышланган бу хезмәте Ш.Мәрҗанинең шундый ук әсәренә якын торган.

Муса Биги хезмәтен тикшерү җыелышының, кемнең, кайсы мулланың ни дию хакындагы «стенограммасы» кадимче китабында шактый җентекле рәвештә бирелгән:

Әйа Муса, син чакырдың, без җыелдык,
Хата дигән фикремездән без тыелдык,
Хата-савап аермага без куелдык,
Хата юкка һәр хәзрәтнең дәлиле бар.

Суфи хәзрәт бер сүзенә йитмеш дәлил,
Ахырында дошманлары булды хәлил,
Һәркаюсы мөслимдер әля камил,
Дин гыйльменең шул вакытда файдасы бар.

Кәшшаф хәзрәт «Мөһиммә»сен кулга алды,
Дәлилләрен берәм-берәм җарып салды,
Бәднишинләр [эш башында торучы начарлар]
җавабына гаҗиз калды,
Мөэминләргә фәрештәнең илһамы бар.

Гариф хәзрәт хата югын тәгъфир итде [таныды],
Дәлил берлән Муса нәкълен [традиция] тәкърик итде
[сөйләп бирде],
Эчендәге җәүһәрләрне тәфригъ итде [аерып бирде],
Аны каккан «Бәянел-хак» [5] гәзите бар.

Садыйк хәзрәт дәлилләре садыйк иде,
Хатасы юк дигән сүзгә сабит иде,
Дәлилләре әксәренә [күпчелек] саикъ [юнәлтүче] иде,
Хак тарафка хакның кыйлган вәгъдәсе бар.

Ибраһим хәзрәт барды, китап ачды,
Гайрәтендән шайтанлар ерак качды,
Җәүһәрен мәйданга барып сачды,
Хәзрәтләрнең риваҗ [популярлык] табар көннәре бар.

5. «Бәянел-хак» — 1906-1914 елларда Казанда чыккан иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета.

Китап авторы җыелышка килми калган шәхесләрнең дә исемнәрен атый һәм аларның мөфти (Мөхәммәдьяр Солтанов) сүзеннән чыкмауларына ишарәтли:

Таип хәзрәт сүзләре дә савап алды...
Сабир хәзрәт бармады, колак салды...
Борнаев Шакир хәзрәт бармый калган,
Мөфтидән әмер җугын белеп алган...
Касыйм хәзрәт катышмады, авышмады...
Завод арты Вәли хәзрәт Габдулласы,
Хисаметдин хәзрәт Казан хак мулласы,
Белсәләр дә бүген мәҗлес һәм буласы,
Аларда һәм сәләфләрнең мәсләке бар...

Шакирҗан Хәмиди — бертуган Кәримевләр матбагасында корректор булып эшләгән, матбугатта күтәрелгән мәсьәләләр буенча еш чыгыш ясаган кеше дә Муса әфәндене тәнкыйть итеп, «савап җыя»:

...Мусаның бер сүзенә биш-ун җавап,
Бәрәкалла, Хәмидигә йөз мең савап...

Бигигә каршы чыгучылар арасында «Йолдыз» газетасы мөхәррире Әхмәдһади Максуди да бар:

Мусаның сүзләрен җакды утка,
Иярмәде Мәгарри кебек сукыр чуртка,
Һади мәхдүм, «Йолдыз»ың [6] китсен хутка,
Мәгарринең кәференә дал сүзләре бар.

Күренә ки, кадимче автор рус сүзләрен текстка шактый оста кертеп җибәрә, бу төр «әче» теллелек аеруча Муса Биги яклыларны сүккәндә ачык күренә:

Аларның кампанйасы шайтанский,
Өстәлдә бер дюжинә шампанский,
Һәр сүзләре малаигъны шалканский,
Кадимләрдә «Дин-мәгыйшәт» [7] журналы бар.

Кадимчеләрнең төп органы «Дин-мәгыйшәт» журналының иң явыз дошманы булган Оренбург газетасы «Вакыт» һәм мөхәррире Фатих Кәрими, фикердәшләре Риза Фәхретдин, Зыя Кәмали аяусыз чыбыркылана:

6. «Йолдыз» — 1906-1918 елларда Казанда чыккан иҗтимагый-сәяси газета.

7. «Дин-мәгыйшәт» — 1906-1918 елларда Оренбургта атнага бер тапкыр чыга торган журнал, нашире һәм мөхәррире Мөхәммәдвәли мулла Хөсәенов (1871-1933).

Вакыт-мокыт, Риза, Зыя шогъбәләре,
Диянәтдә күренми шөгъләләре [ялкын].
Сукыр, зиндыйк Әбелгалә — кагъбәләре,
Мисырда гыйбадәт нам шайтаны бар.

...«Дин-мәгыйшәт» журналын ачыб кара,
Мәгарриләр кабәхатен [гаеп, кимчелек] язып бара.
Бер елга дүрт сум көмеш салыб кара,
Мәгыйшәтдә зыялылар бәяны бар.

X-XI гасырларда яшәгән гарәп философы, пантеист рухлы сукыр шагыйрь Әбелгалә Мәгарринең фикергә ирек таләп итүче тәгълиматының Идел буе мөселманнары хәясенә туры килмәвенә иманы камил автор, аңа иярүчеләрне дә зиндыйклыкта гаепли һәм аларның бу «чир»не Мисырда «йоктырып» кайтуларын әйтә:

Искеләрдән бер хәзрәтнең углы Гасыйм,
Мусага ияреп булды асим [гөнаһ кылучы],
Атаңның җулындан чыкдың зачем,
Берадаре Мисри булып кайтмакы бар.

Муса Биги, шулай итеп, Рәсәй голамәсен «себереп түгеп», Мисырдан безнең тарафларга бу җирлеккә хас булмаган башка бер мәзһәб гыйлемен алып кайтып таратырга җыенуда гаепләнә:

Мисрилардан ширукы [күп аллага ышану, мәҗүсилек]
мәзһәб чыкды,
Хәлал-хәрам хәдисләрен бәреп җыкды,
Дин гыйлемен Парижга барып тыкды,
Русиядә Мисриларның кантуры бар.

Бу юлларда шул чор фикер ияләренең күбесен борчыган мөһим мәсьәлә күтәрелә: бер яктан, татар-мөселман җәмгыятенә яшьләрнең Аурупага ияреп, үз кыйблаларыннан тайпылуы куркынычы янаса, икенче яктан, игътикад үзгәрү куркынычы, Имам Матуриди гакыйдәсеннән, Әбү Хәнифә мәзһәбеннән читкә китү мәсьәләсе исә ислам дөньясыннан килергә мөмкин фетнә булып күренә. Татар мәдрәсәләрендә укымаган, каядыр читтә белем алган, яше яңа гына утыздан узып киткән нindидер берәүнең, Казанга килеп, беркемнең дә башына килмәгән, кулытеле тимәгән әллә нинди катлаулы мәсьәләләрне берүзе чишәргә алынуы, дөресен әйткәндә, бик күпләрдә Бигиевкә ышанмау, аны җитди кабул итмәү хисен тудырган булса кирәк. Җитмәсә,

бәхәсләрдә Муса Биги үзе дә кызып китә торган була. Безнең китап авторы да Муса әфәнденең үз-үзенә кирәгеннән артык ышануын һәм Казан дин әһелләрен надан дип уйлап, алар белән хисаплашмавын тәнкыйть итә:

Килгән икән Казанда кеше юк дип,
Коръәнда аларның эше юк дип,
Меллаларны наданлар, теше юк дип,
Меңәрләрне чәйнәб өзәр тешләре бар.

Бигиевне җитдирәк булырга чакырып, язучы:

...Муса әфәнде, өстән генә ни уйлыйсың,
Кәлам шәриф, хәдис белән ник уйныйсың? — дип сорый һәм:

...Мәгарри сүзен китабыңдан бетер утаб,
Мөэминләрнең игътикадын язма бутаб, — дип киңәш тә бирә.

Җыелыш кадимчеләр тантанасы белән тәмамлана:

Йөз хатадан бер хатага калдырдылар,
Әхбаблары, мәхбүбләре кайгырдылар,
Әйтә торгач, сачене дә алдырдылар,
Ахыр бер көн мыек кисәр көнләре бар.

Коръәннең хатасы юк, мәҗлес бетде,
Хәзрәтләр исбат кыйлып кайтып китде,
Һади мәхдүм «Йолдыз»да игълан итде,
Мөэминләргә шадлык туар көнләре бар.

Әсәрдә Муса әфәнденең озын чәче һәм мыегы гына түгел, җәдидчеләр аурупача киенүдә дә утка тотыла:

Муса Коръән бастыра дип шадланмышлар,
Катышмакчы аңа бәгъзе мактанмышлар,
Пәлтә, шәблит киеп алга атламышлар,
Мөселманның үзенә хас либасы [кием] бар.

Кадимчеләрнең театрга каршы көчле нәфрәте, яңа укыту ысулын кабул итмәүләре дә әсәрдә тәфсилле чагылыш тапкан:

Инанмаңыз бу заманның шәятына,
Театр хәрам ир һәм хатынына...

...Мәсҗед карты, эскрипкә тыңлап тор да
Ни җавап бирерсең үлгәч гүрдә?..

Укытырлар аю-бүре, каргалары,
Уен-көлке, театр арбалары...

Ука, сука, арба, чана өйрәтерләр,
Бер бүлмәдә дәханны һәм көйрәтерләр,
Бер шәкертне сикез йиргә сөйрәтерләр,
Остаз хакы юк дигәнгә дәлиле бар.

Автор шулай ук «җәдидләрне» ураза тотмауда гаепләп, бу темага да шактый күп үгет-нәсихәт биреп ташлый. Шул ук вакытта кадимчеләрне дә буш сафсата сату белән шөгыльләнмәскә чакыра:

Ни файда аять-хәдис күререңдә,
Җәдидләр-пәдидләр дип өререңдә,
Мин кадим дип лаф орыб йөререңдә,
Коръән-хәдис йөкләткән хәмаре [каләм] бар.

Китапта милләтпәрвәр бертуган Хөсәеновләр хакында шактый үзенчәлекле фикерләр әйтелә:

Бәрәкалла Мәхмүд байның мәкаменә,
Зат шәрифнең мөбарәк ак сакалына,
Васил булсын әүлияләр мәкамына [урын],
Вакыфларым шәргый булсын димәке бар.
Дин гыйлеме укылсын, нурга батсын,
Әхмәд бай, Гани бай рәхәт ятсын,
Зат шәрифе Мәхмүднең гомре артсын
Миллионлар дин чырагы улмакы бар.
...Мәхмүд бай зирәк икән, зиһне йитде,
Мәдрәсәсен ислахка һиммәт итде,
Әхмәд бай уйганмады, үлеб китде
Мәхәлләсен мәхрүм итеб үлмәке бар.
Батырҗанга ышанды, кәрам [юмарт] итде,
Ничә мең сум сәмәнне [акча] әрәм итде,
Сөмәрсез агачка су сибеб китде,
Тамырсыз агачның кормакы бар.

Күргәнебезчә, Муса Бигинең бер хезмәтен кире кагуны максат итеп куйган китап авторы, язмасының ахырында шул заман татар җәмәгатьчелеге арасында күтәрелгән башка мәсьәләләргә юнәлеп, «төп курс»тан бераз читкә дә китә. Кадимчеләр арасында Муса Бигинең бу чыгышларына шигъри әсәр белән җавап бирү бер бу китап белән генә чикләнми, әлбәттә. Күпсанлы мәкаләләр, язмалар белән Бигиевне туктаусыз тәнкыйтьләп, тынычсызлап торган «Дин вә мәгыйшәт» журналында шигырь белән язылган башка текстлар да юк түгел. Мәсәлән, 1909 елның 24 июлендә чыккан 29 нчы сандагы авторы «Шагыйрь» дип куелган бер шигырь без тикшергән китап белән бик тә аваздаш тоела:

Җәмгыять ясаганнар төзәтергә,
Коръәндәге хатаны күзәтергә,
Ияргән малайлар Муса артыннан,
Әйтәләр, әйдә, Коръән төзәтергә.
Җәмгыятьдә булган яхшы, галим затлар,
Рәд кыйлганнар [кире какканнар] Мусаны куш канатлар,
Гыйлемлек бер Мусада мәхсүр [чикләнгән] түгел,
Чыга шул Казанда да галим затлар...

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: XX гасыр башында кадим-җәдид бәхәсләре буш һәм кирәксез тартышулар булмаган, киң җәмәгатьчелекне кызыксындырган сорауларга шулай бергәләп җавап эзләнгән һәм дөрес юлны табарга ярдәм иткән. Муса Бигиев тә бу җыелышларда үз фикерләрен яклап чыгып чарланган, көрәштә чыныккан, яңа идеяләр белән баеган дип уйларга кирәк. Без тикшергән әсәр исә кадимчеләр станындагы атмосфераны шактый җанлы итеп бирә алуы белән кызыклы. Теле җиңел һәм гади, шигырь төзелеше ягыннан традицион әдәби калыпка туры китереп язылган бу әсәр, шул чор татар җәмгыятенә хас үзенчәлекләрне типик гыйбарәләр белән билгеләп, укучыларның бер өлешендә теләктәшлек хисе уята алган икән, димәк, аның татар иҗтимагый фикере һәм әдәбияты тарихында яшәргә хокукы бар дигән сүз.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ
ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ,
ШАГЫЙРӘ

ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАН

(04.06.1945)

ҖЫЕН СҮЗЕ

Табадан гына төшкән, тәмам пешкән
Кайнар җырың кирәк Җыенга!
Яңа сүзең кирәк, үзең кирәк, —
Халык бүген шуңа җыелган...

Шагыйрьгә дә кирәк Җыен сүзе —
Шифалы дым — үзәк тамырга:
«Авызымнан алып әйттең», — дисә,
Риза шагыйрь сүзсез калырга...

Шагыйрь булгач, сүз дә уйнатасың,
Керсен өчен бераз киртәгә.
Тамыр сүзләр аша мәгънә эзлим,
Ирек эзлим: «Иртә... Иртәгә...»

А, юк! Ирек безгә бүген кирәк!
Казан җирен итмик казамат.
Азапланып инде азмы яттык, —
Атлан атка, азат азамат!

Азатлыкка дәшеп, азан әйтик,
Азатлык, дип укыйк намазны...
Азат халык кына аера белә
Таш тәтидән затлы алмазны...

Тыелып килгән, җыелып килгән сүзгә
Ашыга халык колак салырга:
«Йөрәгемнән алып әйттең», — дисә,
Риза шагыйрь сүзсез калырга...

* Шагыйрә Лена Шагыйрьҗанның кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

ӘДӘБИЯТ

Бәгырьләрдән сөзелеп чыккан моңны
Шигырь, диләр — түл ук җыру ул...
Агалмыйча, җыелып, буылып торган
Хәсрәт буаларын ерү ул...

Лена Шагыйрьҗан

НӘЗЫЙРӘЧЕЛЕКТӘН – ИНТЕРТЕКСТУАЛЬЛЕККӘ-ӘҢГӘМӘДӘШЛЕККӘ ТАБА

РЕЗЕДА ГАНИЕВА,
филология фәннәре докторы, профессор

Һәр яңа нәрсә иске нигезендә туа. Бу сәнгать һәм әдәбият әсәрләренә дә карый. Һәр әдәби әсәр алдагы буын әдипләренең әсәрләреннән иҗади файдаланып мәйданга чыга һәм яңа заман таләпләренә ярашлы итеп эшкәртелә. Шул рәвешчә, шагыйрьләрнең бер буыны икенчесенә әдәби традицияләр дәвамлылыгын гасырдан гасырга тапшырып килә. Бүгенге бөтендөнья чагыштырма әдәбият белемендә (компаративистикада) традицияләр мәсьәләсе интертекстуальлек төшенчәсе белән тыгыз мөнәсәбәттә өйрәнелә. Урта гасырларда да, яңа заманда да традицияләр дәвамлылыгы сакланган. Мәсәлән, «кешелек мәдәниятенең бишеге» дип саналган Борынгы Греция ауропалылар өчен антик нигез вазифасын үтәгән, аларның сәнгать һәм әдәбиятларын гасырлар

дәвамында төрледән-төрле сюжетлар, жанрлар, рухи кыйммәтләр, образ-сурәтләр белән туендырып торган. Урта гасырлардагы Шәрекъ мөселман әдәбиятлары, шул исәптән, татар әдәбияты да тулысы белән интертекстуальлеккә нигезләнгән. Әмма ул заманда «интертекстуальлек» дигән термин булмаган, аның урынына канунчылык, традиционлылык дигән төшенчәләр кулланылган. Әдәби традицияләр күчемлелеге, дәвамчылык Шәрекътә төрледән-төрле иярүләр язуда, тәкълидчелектә, нәзыйрәләр иҗат итүдә күзәтелгән. Элгәреге шагыйрьләргә, я булмаса, замандашлар әсәрләренә ияреп нәзыйрәләр язуның да унга якын төре булган. Гарәп, фарсы, төрки халыклар әдәбиятларындагы нәзыйрәчелекне дә шартлы рәвештә интертекстуальлекнең тарихи бер баскычы һәм төре итеп карарга мөмкин. Интертекстуальлекне хәтерләткән тәкълидчелек, нәзыйрәчелеккә таянып, Шәрекъ мөселман әдәбиятларында «Йосыф вә Зөләйха», «Хөсрәү вә Ширин», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Таһир вә Зөһрә»ләр сюжетына йөзләгән иярүләр язылган. Мондый закончалыкны Урта гасыр һәм Яңа заман Аурупа әдәбиятлары да читләтеп үтмәгән. Аларда да, классика дип исәпләнгән Борынгы Юнан, ә соңрак Рим әдәбиятыннан үрнәк алып, заманга ярашлы бихисап әсәрләр иҗат ителгән.

Көнбатыш Аурупа һәм рус әдәбият белемендә «нәзыйрә» дигән термин юк. Алар үз әдәбиятларын өйрәнү өчен башка төшенчәләрдән файдаланганнар.

XX гасырның икенче яртысыннан башлап, америка, аурупа һәм рус әдәбиятларына «интертекстуальлек» дигән термин килеп керә. Бу терминны гамәлгә кертүче — чыгышы белән кытайлардан булган француз галимәсе, постструктурализм теоретигы Юлия Кристева. Ул үзенең интертекстуальлек турындагы карашларын атаклы рус галиме М.М.Бахтинның әле 1924 елда ук «Сүз сәнгатендә эчтәлек, материал, форма мәсьәләләре» дигән хезмәтенә, андагы «чужое слово» (теге яки бу текст эчендә чит текст кулланылышы) һәм «диалогичность» («әңгәмәдәшлек») дигән төшенчәләренә таянып үстереп җибәрә. Шул рәвешчә, 1967 елдан башлап, Ю.Кристеваның җиңел кулы белән, интертекстуальлек термины дөнья әдәбиятындагы постмодернизм әсәрләрен анализлауда (башлыча формаль яктан) киң кулланылышка кереп китә. Интертекстуальлек — әңгәмәдәшлек төшенчәсенә иң төгәл аңлатма бирүче булып Р.Барт дигән галим исәпләнә. Аның фикеренчә, «һәр текст интертекст вазифасын башкара; башка текстлар — узган заман культурасымы, әллә бүгенге көндәге тирә-юнь культурасымы — танып белү мөмкинлеге төрле дәрәҗәдә булган текст катламнарында яшиләр. Һәр текст иске цитаталардан тукылган яңа тукыманы тәшкил итә» [1: 260].

Канунчылык традицияләре өстенлек иткән урта гасыр мөселман әдәбиятларында сюжет-мотивларны иҗади эшкәртү, аларга иярү, ярышка чыгу, җавап бирү рәвешендә язылган нәзыйрәләр өстенлек иткән. Соңрак, халыкара аралашу киңәю нәтиҗәсендә рухи байлыклар белән аралашу максатыннан, төрле төсмерләрдәге тәрҗемәләр дә эшләнә башлаган. Әмма интертекстуальлекнең бик борынгыдан бирле киң кулланылыштагысы, һәр язучы өчен аерылгысыз

юлдаш булып килгәне цитаталар дисәк тә, һич ялгышмабыз. Текстара бәйләнешләрне өйрәнү буенча байтак хезмәтләр язган И.В.Фоменко цитата төшенчәсенә киң мәгънә сала: «әдәби атама буларак цитата авторның «үз» тексты эченә керткән барлык чит элементларны берләштерә» дип саный [2:497]. Димәк, цитата — фикерне раслау өчен бик әһәмиятле фактик материал буларак, нинди дә булса бер әсәрдән яисә башка бер кеше сөйләменнән сүзгә-сүз китерелгән өзек (куштырнакларга урнаштырылган цитата) булырга да, укучы өчен яхшы таныш әдәби, тарихи яки көнкүрештәге вакыйгага ишарә (аллюзия) һәм автор ихтыяры белән яки бөтенләй аның ихтыярыннан тыш кулланылган, башка текстны хәтерләтә торган сүз, образ, гыйбарә (реминисценция) булырга да мөмкин.

XX гасыр азагы — XXI йөз башы татар әдәбият белемендә дә интертекстуальлек күренешләрен өйрәнүгә игътибар артты. Көнбатыш белән Көнчыгыш арасындагы әдәби бәйләнешларны текстара мөнәсәбәтләр яктылыгында тикшергән игътибарга лаек хезмәтләр язылды.

Бүгенге америка, аурупа, рус галимнәре тарафыннан теоретик һәм гамәли яктан киң колач белән өйрәнелә торган интертекстуальлек (французча), диалогичность (русча), әңгәмәдәшлек (татарча) XX гасырда гына пәйда булган әдәби алым яки ысул түгел. Алда искәрткәнебезчә, текстара мөнәсәбәтләр борынгы чорларда да, урта гасырларда да, яңа заманда да кулланылышта булган; асыл сыйфатларын саклаган хәлдә, төсмернюансларда яңартылып, исемнәрен алыштырып, ул XXI йөз башында да яшәвен дәвам итә.

Татар әдәбиятындагы әңгәмәдәшлек, әле М.Бахтин белән Ю.Кристева хезмәтләре мәйданга чыкканчы ук, сәнгатьчә фикерләвебез Көнбатыш Аурупа әдәбиятлары казанышларын иҗади үзләштерүгә, Шәрекъ һәм Гареб синтезына омтылган бер чорда — XX гасырның беренче-икенче унъеллыкларында башланып китә. Бу синтезның көнбатыш әдәбиятлары белән бәйле канатындагы интертекстуальлекне тудыру һәм аны әдәби-эстетик алым буларак укучыга җиткерүдә инглиз драматургы һәм шагыйре Шекспир иҗаты зур роль уйный.

Вильям Шекспир (1564-1616) — Көнбатыш Аурупадагы томанлы Альбион җирләрендәге Яңарыш әдәбиятының «ишекләрен ябучы» соңгы даһи язучыларның берсе. Тулырак һәм фикерне җәеп әйткәндә, VII гасырда Ерак һәм Якын Көнчыгышта кытайларның Тан империясе дәверендә (618-907), мөселманнарның Согуд Гарәбстанындагы Хиҗаз өлкәсендә Мөхәммәд пәйгамбәр (570-632) эшчәнлеге һәм Коръән тәгълиматы белән ачылып киткән Ренессанс хәрәкәте, урта гасырлардагы Аурупаның төрле илләре, мәдәниятләре аша үтеп, XVII гасырдагы Англиядә үзенең меңьеллыгын тутырып, Шекспир иҗаты белән тәмамлана.

Егерме елдан артык дәвам иткән иҗатының (1590-1612) күпсанлы драма һәм трагедияләрендә Шекспир таркалып килүче феодаль җәмгыятьнең җанны тетрәтерлек канлы вакыйгаларын, авыр фаҗигаләргә юлыккан образларын гәүдәләндерде, яңа заман тарихының сәхифәләрен ачарга җыенган, шәхескә азатлык таләп иткән, әле бөреләнеп кенә килгән буржуаз мөнәсәбәтләрне чагылдырды.

Өч гасыр узгач та, Шекспир драматургиясендә күтәрелгән мәсьәләләр, феодаль башбаштаклыкны үзәккә куйган конфликтлар, шәхес азатлыгын яклаган мотивлар, иң әһәмиятлесе — шушы вакыт аралыгындаауропалыларның иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни алгарыш кичерүе XX йөз башында җәдитләшү, милли яңарыш юлына баскан татарлар өчен дә гыйбрәтле үрнәк, актуаль зарурият буларак көн тәртибенә килеп басты. Инглиз, француз, немец әдәбиятлары белән дә кызыксыну артты; Шекспир әсәрләре дә русчадан татарчага күчерелеп, театрларда уйнала башлады, Мохтар Мутин кебек трагик рольләрне башкаручы бөек артистларыбыз туды, Шекспир иҗаты буенча Габдрахман Кәрам кебек белгечләребез барлыкка килде; аның драмаларының сәхнәдә ничек куелышы, артистларның рольләрне ничек башкарулары турында күпсанлы рецензияләр, күзәтү мәкаләләре басылды; дөнья әдәбиятының даһи сонет жанры остасы тәэсирендә Гали Рәхимнең милли яңгырашлы гүзәл ике сонеты язылды, Габдулла Тукай да «Ромео и Джульетта» фаҗигасеннән кыска-кыска ике тәрҗемә-нәзыйрә бирде, Шекспирның «Гамлет», «Тимон Афинский» трагедияләреннән дә язар өчен рухи ризык алды; Сәгыйть Рәмиев, Фатих Әмирхан, Фазыл Туйкин әсәрләренә дә бөтендөнья әдәбиятының мәңгелек әсәре дип саналган «Гамлет» трагедиясеннән интертекстлар үтеп керде.

***

Вильям Шекспир — Көнбатыш Ауропа әдәбиятларындагы сонет, драма, трагедия жанрлары һәм театр сәнгате үсешенә зур этәргеч ясаган бөек әдипләрнең берсе. Шул сәбәпле инглиз, америка, француз, немец, рус әдәбиятларында аның иҗаты белән текстара бәйләнешләр да киң һәм зур. XX гасыр башында «Гамлет» трагедиясеннән аллюзия, реминисценция, цитата рәвешендә алынган интертекстуаль алымнар татар әдәбиятына да үтеп керә. Әдипләребез «курайда уйнау», «җүләрләнү» мотивларына, «быть или не быть!» («яшәргәме, әллә үләргәме?») антиномиясенә яратып мөрәҗәгать иткәннәр, үзләренең шигырьләре, проза һәм драма әсәрләре тукымасында кулланганнар. Фикеребезне раслау өчен, иң элек Шәрекъ һәм Гареб халыклары, шулай ук төркиләрнең музыкаль сәнгатендә яратып кулланылган уен коралы флейта — курай — сыбызгы образы һәм мотивының Шекспир иҗатыннан алынган аллюзия, реминисценция, цитата рәвешендә Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Фатих Әмирхан, Фазыл Туйкин әсәрләрендә нинди әдәби-эстетик вазифаны башкаруына тукталып үтик.

Шекспирның «Гамлет» трагедиясендә сарай музыкантларының флейтада — курайда уйнау күренеше король Клавдий шымчыларының принц Гамлетка күз-колак булу, аны эзәрлекләү уңае белән тасвирланган. Аның эчтәлеге түбәндәгечә: һәр адымы күзәтү астына алынудан ярсыган принц Гамлет флейтачылар ансамбленнән торган музыкантларны чакыра. Алар сәхнәгә килеп кергәч тә, Гамлет, үзенең элгәреге дусты, сарай хезмәтчесе Гильденштернның флейтада уйнавын таләп итеп, аның кәефен кыра:

Гамлет (Гильденштернга). Ә, менә флейтада уйнаучы да килде.

Миңа флейтаңны биреп тор әле. Минем арттан Сез кирәгеннән артык күзәтчелек итәсез кебек тоела.

Гильденштерн. Ышаныгыз, принц, моңа төп сәбәп — минем Сезне яратуым һәм король хакына тырышлык күрсәтүем.

Гамлет. Мин нигәдер бик үк аңлап бетермим. Миңа нинди булса да бер көй уйна әле! (Аңа флейтаны суза).

Гильденштерн. Уйный алмыйм, принц.

Гамлет. Тыңла инде, уйна!

Гильденштерн. Дөресен әйтәм, принц, булдыра алмыйм.

Гамлет. Ходай хакы өчен, уйна инде!

Гильденштерн. Мин флейтада бөтенләй уйный белмим бит.

Принц Гамлет Гильденштернны икейөзлелектә, алдакчы булуда гаепли. Аныңча, *«флейтада уйнау, алдалау кебек, бик җиңел эш бит: флейтаны менә болай тотасың, иреннәреңне монда куясың, бармакларыңны бирегә — ул үзеннән-үзе уйный башлар»* [3:77].

Принц Гамлет король шымчысы Гильденштернга үзенең гади уен коралы — флейта гына булмыйча, җаны булган Кеше икәнлеген аңлатырга тырыша. Үзен һәрдаим күзәтеп, әзәрлекләүләргә ризасызлык белдереп, ул болай ди: *«Үзең уйлап кара: син мине кем дип исәплисең соң? Син минем җанымда уйнарга телисең, ә үзең гап-гади сыбызгыдан да көй чыгара алмыйсың. Мин шул гап-гади флейтадан да начаррак, гадирәкме? Мине теләсә нәрсә дип сана: син мине газаплый аласың, әмма минем белән уйнарга ярамый»* [3:78].

Гамлетның Гильденштернга җавабыннан ачыктан-ачык түбәндәге фикер аңлашыла: кеше җаны матур тавышлар чыгаручы, гади бер агачтан ясалган флейта гына түгел, ул гаять тә катлаулы. Аның белән флейтада уйнаган кебек теләсә ничек уйнарга ярамый. Шул рәвешчә, Шекспир герое принц Гамлет кеше рухына азатлык даулый, аны хөрмәт итүне таләп итә.

Әле XVII гасыр башында ук «Гамлет» трагедиясендә (1601) инглиз Ренессанс әдәбиятының даһи драматургы Шекспир көн тәртибенә куйган шәхес азатлыгы мәсьәләсе XX гасыр башында Яңарыш дәвере кичергән татар әдәбияты өчен дә актуаль проблема булып калды. Сүз дә юк, татар җирлегендә ул заманга ярашлы милли мәнфәгатьләр күзлегеннән яктыртылды. «Курайда уйнау» интертексты озак гасырлар дәвамында физик һәм рухи изүгә дучар булган хатын-кызларыбызга ирләр белән тигез хокуклар таләп итүдә, милли тәрәккыятькә, халыкны хезмәткә чакыруда, татар тормышындагы кадимчелек, торгынлык күренешләрен тәнкыйть итүдә уңышлы файдаланылды.

Мәгълүм булганча, флейта — Шәрекъ һәм Гареб халыклары музыкаль сәнгатендәге төрле исемнәр белән атап йөртелгән бик популяр борынгы уен коралы. Курай дип аталып йөргән бу музыка коралын төрки кавемнәр, шул исәптән татар-башкортлар да үз иткәннәр. Сәгыйть Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» пьесасында (1907) курайның «флейта» синонимы белән аталуы бу образның Шекспир трагедиясенә аллюзия булуына да ишарәли. Ике драматург арасындагы охшашлык сюжет элементларында да күренә. «Гамлет» трагедиясендә дә, «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» пьеса-

Д.Нәүрузова коллажы

сында да музыкантлар махсус чакыртып алыналар.

Дини-патриархаль гореф-гадәтләр басымыннан азат булырга омтылган Сөләйман белән Зөбәйдә мәхәббәтенә бәйле рәвештә, Сәгыйть Рәмиев пьесасына Шекспирдан кабул ителгән «флейтада уйнау» интертексты һәм дә башкорт курайчыларының ачыктан-ачык хәзрәтләр алдында күңел кылларын тибрәтерлек көйләр уйнавы дин әһелләре тарафыннан «шайтани сәнгать» дип саналган музыканы реабилитацияләү дә иде. Драмада хәзрәтләр үзләре үк музыканы шәригать тыюларыннан аклап, «хәйләишәргый» (шәригать хәйләсе) дип, курайда уйнарга рөхсәт бирәләр. Кыскасы, Сәгыйть Рәмиев Шекспирдан алынган «флейтада уйнау» мотивын тулысынча милли җирлеккә яраштырып эшкәртә.

«Курайда уйнау» реминисценциясе Фатих Әмирханның «Яшьләр» пьесасында да яңгыраш тапкан. Шекспир белән аваздашлык Ф.Әмирхан геройларының диалогларында ук үзен сиздертә:

Йосыф. Сызгыра беләмсең син?
Зыя. Ни дисең?
Йосыф. Юк, хуррай уйный беләмсең, дим [4:298].

Гамлет король Клавдий шымчысы Гильденштернны флейтада уйна әле дип башын катырса, Йосыф исә Зыяның «сызгыра беләмсең», «хуррай уйный беләмсең?» дигән тинтәк сораулар белән кәефен җибәрә.

Әдип сурәтләгән зыялы яшьләрнең күпчелеге татар тормышын тамырыннан үзгәртү, яңарту уе белән яна. Әмма бу олы максатны тормышка ашыруда алар арасында фикри бердәмлек юк. Берәүләр моңа ирешүдә радикаль чараларны, инкыйлаби халыкчылык идеяләрен алга сөрә, икенче берәүләр социаль демократларча эшче-крестьяннарның сыйнфый аңын тәрбияләү фикерен куәтли, өченчеләре — Аристотель фәлсәфәсендәгечә — «алтын урта» тарафдарлары.

Драма геройлары үзләрен, Тургеневның Рудиннары, Базаровлары кебек, «халыкка бертуктамый искене җимерү идеясен сөйләүчеләр», «переходный типлар» дип атыйлар, безнең бөтен уй-фикеребез «искене разрушениегә» юнәлтелгән булырга тиеш дип, кызып-кызып бәхәсләшәләр: Гаяз Исхакыйның таңчы яшьләрен хәтерләткән Гали белән Йосыф «разрушение старого, негодного» идеясен кайнар яклыйлар, урталыкта чайкалучы Зыя исә бу фикергә каршы чыга. Искене вату, җимерү уе белән янган Йосыфны Зыя акылдан шашканнар рәтенә кертә. Йосыф үзе дә бу фикерне кире какмый. *«Впрочем,* — ди ул, — *каждый дурак по своему с ума сходит» [4:297].* Йосыфның русча әйткән бу сүзләреннән ирония белән көлеп, аларны хуплагандай, Зыя болай ди: *«Бик дөрест, һәр мәҗнүн үзенчә акылдан шаша. В том числе, сез дә» [4:298].* Шуны да ассызыклап үтәргә кирәк: Ф.Әмирхан «мәҗнүнлек», «гакылдан шашу», «сходить с ума» кебек интертекстларны Шекспир иҗатыннан кабул иткән. Дошманнарының уйларын белер өчен, Гамлет та акылдан шашкан кеше булып кылана, аларның икейөзлелеген, астыртын эшләрен, җинаятьчел адымнарын ачы сүзләр белән фаш итә.

Озак гасырлар дәвамында шәригать кануннары белән бере-

геп яшәгән гореф-гадәтләр никах, мәхәббәт мәсьәләләрен патриархаль традицияләргә буйсындырды; хатын-кыз хокукларын коллык богаулары белән алыштырды. Фазыл Туйкинның «Тормыш корбаннары» драмасында да татар әдәбиятына хас традицион конфликт — кызы Әминәне көчләп күрше авылның надан шәкертенә кияүгә бирергә җыенучы таш бәгырьле ата Мәхмүд мулла образы сурәтләнгән. Аның алдынгы фикерле улы Хәсән «Кызыңны кол итеп сатасың, бу — вәхшәт», дигән сүзләр белән әтисенең башбаштаклыгына каршы чыга. Мәхмүд мулла исә улына: «Минем баламда синең эшең юк. Теләсәм, утка салырмын, теләсәм — суга!» — дип җавап бирә. Шигъриятне яратучы укучы бу сүзләрнең хатын-кызны бик олылаган, аны Алиһә дәрәҗәсенә күтәргән Сәгыйть Рәмиевтән, аның «Син» шигыреннән үзгәртелгән цитата-реминисценция икәнлеген шунда ук танып ала (*«Мине утка аткан ул — син, / Мине суга салган да — син, // Утта янсам, суга батсам, / Тартып алган Аллам да — син!» [5:30]).* Җир гүзәлләрен идеаллаштырган, илаһилаштырган Сәгыйть Рәмиев мәдехләрен Фазыл Туйкин хатын-кызлар хокуксыз булырга тиеш дигән капма-каршы эчтәлекле тезис белән алмаштыра.

«Тормыш корбаннары» драмасында аталар һәм балалар арасындагы конфликтны, феминизм мәсьәләләрен гендер теориясе күзлегеннән яктыртканда, интертекстуальлек беренчел һәм хәлиткеч рольне уйный. Моның шулай икәнлеген кабат «Гамлет» трагедиясеннән алынган «курайда уйнау» реминисценциясе белән дә дәлилләп була. Сеңлесе Әминәне үз ихтыяры, үз вөҗданы белән яшәүдән мәхрүм итәргә теләгән кешелексез Мәхмүд мулланы улы Хәсән Шекспирның шымчыларны тәнкыйтьләгән Гамлеты рухында фаш итә: *«Юк, әти,* — ди ул, — *алай адәмне теләсәң нишләтә ала торган заманалар үтеп бара инде, соңгарак калгансыз! Ул син уйнаган яки мин уйнаган курайга биер өчен үсмәгән, ул үзенең вөҗданы хакиме астында яшәр өчен дөньяга килгән» [6:263].*

Шул рәвешчә, Фазыл Туйкин татар тормышына җайлаштырып Шекспирдан кабул ителгән интертекстуальлек ярдәмендә хатын-кызлар үз язмышларының иҗатчылары булырга тиеш дигән әһәмиятле мәсьәләне көн тәртибенә куя. Автор бу фикерен хатын-кыз «үзенең вөҗданы хакиме астында яшәр өчен дөньяга килгән», дигән җөмлә белән дә җөпли. «Вөҗдан хакиме» дигәндә, Фазыл Туйкин VII гасырда ук мөселман дөньясында Коръән тәгълиматы белән гамәлгә кергән кеше ихтыяры мәсьәләсен күздә тота дип фаразларга кирәк, чөнки Изге Китапның буеннан-буена әйдәп баручы төп мотив — намус белән гадел яшәргә чакыру.

Мәкаләдәге сүз сөрешеннән күренә ки, татар язучыларының Шекспир иҗатыннан яратып кабул иткән интертекстлары — «курайда уйнау». Ул шагыйрь Габдулла Тукайның «Мәкаләи махсуса» исемле юлъязмасында да очрый. Шагыйрь аны Өфенең шәһәр бакчасында матур киенеп, үзен әллә кемгә куеп, горур кыяфәттә йөрүче шәкерттән көлү өчен файдалана. Бу хакта ул: *«өстенә җөббә, башына зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка «батинкә», авызына кош төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур*

шәкертне туктатып, җүри, «вәкар вә мәһабәтен» бозар өчен: «Син курай уйный беләсеңме?» — дип сорыйсым килде. Мин үзем, гомумән, шундый «кәмитле» мәһабәтлекне бозудан ләззәт табам. Аннан соң без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек аның «вәкар»ен бозарга кирәк» [7:56].

Аңлашыла ки, Габдулла Тукай үз-үзенә гашыйк булган, нарциссизм чире белән авырган шәкертнең тышкы кыяфәтен дә, рухи хәерчелеген дә кабул итә алмый. Шуңа күрә ул Шекспирның Гамлеты, Әмирханның Йосыфы кебек, кием калыбына әйләнгән шәкерткә: «Син курай уйный беләсеңме?» — дигән сорау биреп, аның горурлык канатын сындыра, кәефен төшерә. Шул рәвешчә, шагыйрьнең юльязмалары текстына «кәеф прозасы» элементлары килеп керә.

Татар әдәбият белемендә Шекспирдан кабул ителгән бу реминисценцияне икенче төрлерәк мәгънәдә шәрехләү очрагы да булды. Әдәбиятчы Энгель Нигъмәтуллин: «Играть на курае означало для поэта понимание самых тонких струн души народа, его мыслей, его музыки», — дип яза [8:96]. Безнең уебызча, «курайда уйнау» интертексты — кәеф кырылуны, нервлар бозылуны аңлатучы киная, ягъни аллегория. Аңа «халык җырының нечкә кылларын тибрәтүче» дигән мәгънә салганда, совет чорындагыча социологик анализ булыр иде.

Шекспирның «Гамлет» трагедиясе белән текстара бәйләнешләрны Тукайның «Юбилей мөнәсәбәте белән» (1913) мәкалә-эссесында күзәтергә мөмкин. Ул Романовлар династиясенең якынлашып килүче 300 еллык юбилее уңае белән язылган. Бу «олугъ тарихи вә ватани вакыйга» шагыйрьне Россия империясендә яшәгән татар халкының авыр язмышы, «дөньяда тигезлек юклыгы» турында хәсрәтле уйларга батыра. *«Кичә,* — дип яза ул, — *минем өчен төн үткәрү, әллә ничек, милләтебезнең җансыз тормышы кебек, күңелсез вә эчпошыргыч булды. Исемә төште ки, шундый чакта бераз көйләсәм, шыңгырдасам, күңелем ачыла торган иде» [9:256].* Мондый мәгънәдәге сүзләрне Дания корольлеге турында Гамлет та әйтә. Король Клавдий сараендагы икейөзлелектән, бозыклыклардан, җинаятьләрдән акылы томаналанырлык дәрәҗәгә җиткән, дөньяда торуның мәгънәсен югалта язган принц Гамлет язмыш белән тартышып яшәргәме, әллә үләргәме, дигән чишә алмаслык сорау алдында кала һәм «Быть или не быть!» исеме белән мәгълүм булган атаклы монологын әйтә. Шекспир иҗатын өйрәнүче галимнәр язганча, «жить для него — это покоряться пращам и стрелам яростной судьбы, умереть — ополчась противоборствам» [14:88]. Башка бер тарихи чорда, башка бер максатны күздә тотып мәкалә-эссе язган Тукай Шекспирдан алынган «Яшәргәме, әллә үләргәме?» дигән экзистенциаль эчтәлекле, экзистенциаль яңгырашлы реминисценциягә бөтенләй үзгә эчтәлек сала. Ни өчен моның шулай икәнлегенә шагыйрь «Ике ихтар» исемле мәкаләсендә аңлатма да биреп үтә.

Шагыйрьнең «Юбилей мөнәсәбәте белән» мәкалә-эссесында Романовлар нәселенең олы бәйрәме уңаеннан Казан татарларының патша хәзрәтләренә нинди булса да бина корып бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итүләре хакында сөйләнә. Берәүләр хәерче кызлар өчен приют сорауны,

икенчеләре яшьләр өчен гимназия ачуны кулай күрәләр. Шул хакта әллә никадәр җыелыш-мәҗлесләр үткәрелә, матбугат битләрендә бәхәсләр куба, хәтта башкалага «патша хәзрәтләренә депутация» дә бара. Әмма милләт хадимнәренең тырышлыклары Печән базарындагы хәерче кызларга бер йорт-приют салып бирүгә рөхсәт алудан узмый. Гимназия ачуны дүрт күз белән көткән яшьләрнең өмете Шекспирның зур каһарманнарының берсе булган Гамлетның «Быть или не быть!» афоризмы сыман күкләрдә асылынып кала.

«Юбилей мөнәсәбәте белән» мәкаләсенең буеннан-буена Тукай, табигатьтә һәм кешелек җәмгыятендә тигезлек булмаган кебек, Казан татарлары арасында да патшадан хәйрия бүләге итеп бина төзүне таләп итү мәсьәләсендә фикер чуарлыгы хөкем сөрү, милләтнең табигый куәте — биоэнергетикасы түбән булу турында фәлсәфи фикер йөртә, замандашларының «милләтнең чын ихтыяҗына вакыйф булмаудан» (төшенмәүдән) астыртын ирония белән көлә. Автор, Романовлар династиясенең юбилей бәйрәме уңае белән өметләнеп тә төзелми калган гимназияне күк капусы ачылган мизгелдә Аллаһыга ялварып та кабул ителмәгән дога-теләкләр белән чагыштыра. Мәкалә-эссе Гамлетның мәшһүр канатлы сүзләре белән тәмамлана:

«Әмма яшьләр, күк капусы ачылганда, зуррак дога кыйлмакчы булганнар иде. Кабул булмаса булмас.
Янә тәкрар итәмез:
«Быть или не быть!» [9:259].

Кыскасы, Габдулла Тукай Шекспирның «Гамлет» трагедиясеннән «курайда уйнау», «Яшәргәме, үләргәме?» дигән интертекстларны куллану белән генә чикләнмәгән. Теге яки бу фикерне үткеррәк, үтемлерәк әйтер өчен, ул еш кына Шекспирдан цитаталар кертеп җибәрә, я булмаса, аның күпләргә мәгълүм образларына, гыйбарәләренә — реминисценцияләргә мөрәҗәгать итә, һич булмаса, таныш вакыйгаларга, образларга аллюзия-ишарәләр ясый. Менә шундый текстара бәйләнешләр ярдәмендә Шәрекънең тәкълидчелек, нәзыйрәчелек традицияләрендә әдәби чыныгу алган Тукай Көнбатыш Аурупа әдәбиятлары өчен хас интертекстуальлек — әңгәмәдәшлеккә таба хәрәкәт итә.

Әдәбият

1. Хализев В.Е. Теория литературы. — М.: Высшая школа, 2000. — 398 с.
2. Введение в литературоведение: литературное произведение: основные понятия и термины. — М.: Высшая школа, 2000. — 556 с.
3. Шекспир В. Гамлет. — М.: Молодая гвардия, 1980. — 367 с.
4. Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. 2-т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. — 486 б.
5. Рәмиев С. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1962. — 162 б.
6. Бертуган Туйкиннар: тарихи-документаль җыентык. — Казан: Рухият, Җыен, 2007. — 392 б.
7. Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда. 5-т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. — 368 б.
8. Нигматуллин Э. Раздвигая века и границы. — Казань: Татар.кн.изд-во, 1977. — 137 с.
9. Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда. 4-т. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. — 351 б.
10. Шекспир. Энциклопедия. — М.: Алгоритм, Экспо; Харьков: Око, 2007. — 448 б.

ШАГЫЙРЬ ҺӘМДӘМИ ЯКИ МЕЛЛА МАМАЙ

МАРСЕЛЬ ӘХМӘТҖАНОВ,
филология фәннәре докторы



Әдәби мирасыбыз хәзинәләре эчендә әлегәчә үзенең галим-тикшеренүчеләрен көтеп ята торган язма истәлекләр бар. Аларның безнең көннәргәчә сакланып калу очраклары да үзе бер гаҗәп инде.

Әйтик, берәр шагыйрь нинди генә бер әсәр язса да, аны, үзе генә күчереп, төрле җирләргә тарата алмый бит. Ә алар, тарихта шундый киң төбәкләргә таралып, меңләгән казалардан зыян күрә-күрә сакланып калганнар.

Шундый гыйбрәтле язмышлар кичереп, безнең көннәргәчә кульязмаларда килеп җиткән әсәрләрнең берсе XVII гасыр татар шагыйре Һәмдәминең «Нәсихәтнамә» исемендә йөргән.

Һәмдәминең бу әсәре, беренче булып татар халкының зур әдәбият белгече Нил Юзиев һәм танылган археограф Альберт Фәтхи тарафыннан экспедиция вакытында табылып, ачыкланып һәм анализ ясалып, кыскача гына 1963 елда матбугатта игълан ителде [1].

Искәрмәләр

1. Нил Юзиев, доцент, экспедиция җитәкчесе; Альберт Фәтхи, Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәнең Көнчыгыш кульязмалары бүлеге мөдире. Уралда сакланган хәзинәләр // Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр. — Казан: «Тамга» нәшрияты, 2007. — 34-39 б.

Дөрес «Нәсихәтнамә»нең кулъязмаларын 1934 елда Казан артында археографик экспедиция вакытында Вәли Зәбиров исемле татар археографы да табып, ул вакыттагы Ленинградта Көнчыгышны өйрәнү институтына алып кайтып тапшырган булган. Әлеге кулъязмаларның икесе XVIII гасырда, берсе 1806 елда, дүртенчесе 1852 еллар тирәсендә күчерелгән булган. Кызганычка каршы, ул кулъязмаларның эчтәлегенә зыян салып, атаклы рус тюркологы Л.В.Дмитриева фәнни әдәбиятта бу турыда бик соң — 1980 елда гына хәбәр итте [2].

Әдәбиятчы Фәрит Яхин 1996 елда Әлмәт шәһәре мәчетеннән «Нәсихәтнамә»нең 1786 елгы күчермәсен табуы турында этрафлы хәбәр бастырды [3]. Ләкин галимебез, минем карашымча, эш процессында тупас ялгышлар җибәреп, аның язылу тарихы турында буталчык фикерләр язды һәм соңыннан бу темага кагылышлы язмаларында аларны тирәнәйтте [4].

Бүгенге татар археографиясенең иң күренекле вәкилләреннән — Рәиф Мәрданов тарафыннан «Нәсихәтнамә»нең 1659/1660 елларда һәм 1844 елда күчерелгән нөсхәләренең Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклануы хакында 2011 елда матбугатта хәбәр ителде [5].

Безнең тарафтан 1980 елда Ташкентта Җәвад Алмаз китапханәсеннән алынган кулъязма җыентыкта да «Нәсихәтнамә»нең начар сакланган бер күчермәсе бар иде. Ул күчермә XVII гасырның соңгы чирегендә язылганга охшый.

Шулай итеп, бүгенге көндә «Нәсихәтнамә» әсәренең тугыз күчермәдә булуы мәгълүм.

Моннан тыш Уфа әдәбиятчысы Г.Хөсәенов «Нәсихәтнамә»нең 1102 ел (һиҗри), 1690/1691 ел (милади) күчермәсенең башкортларда укылуы хакында яза, ләкин кайда саклануын хәбәр итми [6]. Бу ачыклауны сорый.

Әсәр текстының язма чыганакларына килгәндә, аны Фәрдетдин Гаттарның «Пәнднамә» китабыннан тәрҗемә итеп карыйлар. Хәтта Ф.Яхин аны Казанда басылып та чыккан дип күрсәтә [7]. Әлбәттә, Гаттарның бу әсәре татар шәкертләре арасында инде кулъязма хәлендә үк фарсы телен өйрәнү өчен ярдәмлек сыйфатында йөргәне билгеле иде. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать үзәгенең Мирасханәсендә генә дә аның 75 кулъязмасы саклануы мәгълүм. Ә инде башка җирләрдә саклана торган Гаттар әсәренең кулъязмалар саны аннан да ким булуында шик юк.

Гаттарның «Пәнднамә» әсәренең Казанда төгәл ничә мәртәбә нәшер ителүе өйрәнелмәгән. 1884-1899 елларда аның һәр шигъри юлына проза белән татарча бирелгән тәрҗемәле варианты дүрт мәртәбә басылганлыгы ачык мәгълүм. Кызганычка каршы, кайберәүләр язганча, Гаттар әсәре тәрҗемәсе белән Һәмдәми язган «Нәсихәтнамә»нең уртаклыгы аз.

Андагы тәрҗемәләр стиль һәм шигъри вәзеннәрнең булмавы белән аерылып торалар:

2. Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской Академии наук. — М.: Изд-кая фирма «Восточная литература» РАН, 2002. — С.368 (№1496-1499). (Впервые опубликованы: Дмитриева Л.В. Описание тюркских рукописей Института востоковедения. III том. — М.: Изд-во «Наука», 1980. — С.142).

3. Яхин Фәрит. Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә» әсәре // Әдәбият чыганаклары һәм текстология. — Казан, 1992. — 13-24 б.

4. Яхин Ф.З. Тобольский татарский поэт Амдами и его произведение «Насихатнамэ» («Книга наставлений) // Материалы V Сибирского симпозиума «Культурное наследие Западной Сибири: Тюркские народы». — Тобольск, 2002. — С.601-602.

5. Мәрданов Р.Ф. Татарстан Милли китапханәсендә татар һәм Көнчыгыш кулъязмаларын туплау һәм өйрәнү тәҗрибәсеннән // Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения. — Казань, 2011. — С.43.

Мисал:

Улдур падишаһ һәрнәрсәне теләсә, аны кыйлур,
Дөньяны бер сулуда хәраб кыйлур.
Бардур падишаһлык, тапшырылмыш аңа,
Йукдур кешигә такать, ничүк вә ни өчүн димәк.
Ул берәүгә нигъмәт хәзинәсени бирәдүр,
Ул икенчегә ръне җни дәхи зәхмәтни бирәдүр.
Ул берәүгә алтынны ике йөз капчык бирүр.
Икенче күмәч хәсрәтендә җаныны бирүр.
Ул берәү тәхетдә гыйззәт берлә дәхи йөз наз берлә,
Ул икенче кыйлган агызны фәкыйрълекдин ачка.
(Гаттар. Панднамә. — Казан, 1899. — 5 бит.)

Барча йирдә ки — дисәң, үткән сүзүң,
Барлык эшләрдин йырак торгыйл үзүң!
Йул йарагы һич йукдыр азыгың,
Бар салаватта өйелсен йазыгың.
Түрт эшдер кем ирүр гайн хәтәр,
Гакыйл ирсәң, кыйл ул эшләрдин хәзир.
Падишаһларга йавык тормак бери,
Кем торыр булса гаҗәб кыйлгай йири.
Бел, икенче, дуст булмак залимләрә,
Гакыйл ирсәң дуст бул галимләргә.
(Һәмдәми. Нәсихәтнамә. — 19а бит.)

Гаттар әсәре басмада 64 бүлектән тора (китап күләме 92 бит). Кулъязма текст (24 бүлек) «Пәнд нәсихәт» дип кенә бирелә. Басма текстта бүлекләрнең фарсыча исемнәре һәм татарча тәрҗемәләре дә бар.

Әлбәттә, Гаттарның «Пәнднамә» китабының әхлакый, тәрбияви идеясе Һәмдәми әсәренең нигезендә ята. Ләкин татар авторы аның идеясен, колониаль коллыкка төшкән халыкның менталитетына җайлаштырып, татарның үз образлы теле белән бәян иткән.

«Пәнднамә»нең татар вариантын идея структур яктан ачыклау өчен, аның тугыз күчермәсе белән дә таныш булу кирәк.

Һәмдәми әсәренең язылу вакытын ачыклауда конкретлык таләп ителә. Моның өчен Әлмәттә табылган кулъязмадагы Ф.Яхин укыган «Тарих мең дә ун» дигән дата белән килешеп булмый. Чөнки язманы «ун» түгел «ут» дип укырга кирәк. Ул сүз ачык рәвештә اوت дип (гарәпчә) язылган. Аннан Яхинга, һиҗри 1010 ны милади белән 1601-1602 гә туры килгәнен билгеләү авыр булмас иде... Ә инде 1030 ел булса да, дата бары тик милади буенча 1620/1621 елларга туры килә. Безнең фикеребезчә, язылу датасы 1621-1630 еллар арасында булырга тиеш, чөнки кулъязмадагы «тарих мең дә ут...» датасы язы-

6. Хөсәенов Г. Быуаттар тауышы. — Өфө: Башкорт.кит. нәшр., 1984. — 187 б.

7. Әгәр Һәмдәминең «Нәсихәтнамә»се 1872 елда басылган булса, аның авторы итеп Гаттар күрсәтелмәс иде. Һәмдәми әсәр ахырында аның үз хезмәте булуын күрсәтә.

лып бетмәгән. Р.Мәрданов тапкан кулъязманың су билгеләре (кәгазь җитештерүче оста тарафыннан төшерелгән тамга) 1659-1666 елларга туры килүе әсәрнең XVII гасырның икенче яртысында иҗат ителмәгәнен катгый рәвештә раслый.

Һәмдәми тәхәллүсенә карата. Бу сүз фарсы теленнән «иптәш», «дус» дип тәрҗемә ителә ала. XVII гасыр татар шагыйрьләре әсәрләрен яшерен имзалар белән язганнар. Аларның чын исемнәрен ачу шактый кыен.

Инде югарыда күргәнебезчә, Һәмдәми әсәре Идел ярларыннан алып Зәй буйларына, Ашыт-Казанка буйларына кадәрле милли татар җирлегендә 380 еллар элек язылып сакланган, укылган.

Бу төбәктә Һәмдәми тибындагы әсәрләр язучылардан Татарстанның хәзерге Питрәч төбәгенә керә торган Чыты һәм Колай авыллары белән килеп чыгышы бәйләнгән Мәүла Колый дигән шагыйрь иҗаты кызыклы.

Мәүлә Колый да суфый шагыйрь. Аның иҗаты XVII йөзнең икенче яртысыннан мәгълүм. Мәүла Колыйның да хикмәтләре Һәмдәминең әсәрләрендәге идеяләргә бик аваздаш. Ләкин Һәмдәми әсәренең башлам өлешендә затлы акыллы, юмарт, шәфкатьле, укымышлы шәхес тәрбияләүгә күбрәк игътибар ителә.

Ике авторның да әсәрләрендә төп идеяләр булып җир кешесенең холкын, фигылен, аның кеше гомеренә карата акыллы фикердә булуына өйрәтү нәсихәте бирелә. Мәсәлән, Мәүла Колыйда һәм Һәмдәмидә кеше нәфесенең киң амплуасы тасвирланып, беренчесендә авторның 4, 32, 33, 40, 57, 82 нче хикмәтләрендә бәян ителә. Һәмдәми әсәренең кулъязмасының тексты тулы булмаганлыктан, анда нәфес «Пәнд»ләрдә түгел, бәлки кулъязманың 7б, 12а, 14б, 15а, 18б, 26б, 27б, 28а, 28б, 29а, 30а, 30б, 33а, 33б, 37б, 40а битләрендәге сәхифәләрдә «нәфес-шайтан» образы аша искә алына.

Ике шагыйрь өчен дә төп проблема дөньяның фанилыгы, аны яхшы, игелекле эшләр белән уздыру нәсихәтләре аша тасвирлана.

Мәүла Колый җыентыгындагы 29, 42, 48, 60, 64, 72, 77, 78, 89, 98 нче хикмәтләрдә, Һәмдәми кулъязмасында 22а биттәге ике юл нәсихәтләрнең гүзәл үрнәге:

Кайтмас өченче, йәйәдән чыкган ук,
Һәм кичкән гомер кайтырмы? — Йук!

Тәкәбберлек сыйфатларының Адәм углына зыян салуы хакында ике чыганакта да языла. Мәүла Колыйда ул 14, 44, 97 нче хикмәтләрдә, Һәмдәми җыентыгында исә 8б, 19б, 24б, 25а битләрдәге нәсихәтләрдә күренә.

Моннан тыш, икейөзле мөнафыйкъ-тәкәбберләр турында ике

авторда да нәсихәтләр бирелә. Мәүла Колыйда 13, 14, 39, 84 нче хикмәтләрдә, Һәмдәмидә 5а, 6а, 24б, 25б битләрдә андый нәсихәтләр теркәлгән. Һәмдәмидән бер бәет:

Багла билеңни мөнәфыйкъ касдыйна,
Кауми мөнафыйкъны кара йир астыйна!..

Аллаһка мәхәббәт темасына да ике автор бердәм рәвештә аны матур сүзләр, фикерләр белән бизәп, нәсихәтләр бәян итәләр. Мәүла Колыйда 6, 7, 18, 34, 35, 36, 50-53, 62, 63, 67-71, 75, 91, 92, 103, 104 нче хикмәтләр һ.б. Һәмдәмидә 36а, 38б битләрдәге нәсихәтләр шул темага багышлана.

Җумартлык (Мәүла Колыйда шулай язылган) һәм сәхилек (юмартлык) турындагы нәсихәтләрдән беренчесендә 12 нче хикмәт, Һәмдәмидәге кульязма текстта 10а, 24б, 29б битләрдәге нәсихәтләр шуңа карыйлар.

Әүлиялар, дәрвишләр темасы һәр ике шагыйрь иҗатында да карала. Аңа кагылышлы сәхифәләр Мәүла Колыйда кимрәк: 9, 15 нче хикмәтләр; Һәмдәмидә мулрак: 40а, 40б, 37а, 37б битләрдәге нәсихәтләрдә күренә.

Кешедәге сабырлык сыйфатының югарылыгы һәр ике шагыйрьдә дә тасвирлана. Мәүла Колыйда — 7 нче хикмәт, Һәмдәмидә — 26б бит.

Максатыбыз Һәмдәми мирасы белән таныштыру булгач, без Мәүла Колыйның үзенә генә хас темаларга тукталмадык һәм Һәмдәми кагылган темаларны гына искә алып уздык.

Һәмдәминең кульязма нәсихәтнамәләрендә без авторның татар мөселманнарга искиткеч акыллы һәм матур педагогик, фәнни яктан дөрес булган киңәшләре системасын искә алырбыз.

1. Кунак кабул итү

Кунак — Аллаһ тарафыннан җибәрелгән, сине сынарга килгән образ. Хуҗа аннан качып, аңа кадер-хөрмәт күрсәтмичә йөрергә тиеш түгел. Һәмдәминең бу өйрәтүләре татар халкы арасында әле XX гасырда да онытылып бетмәгән иде.

2. Әдәп кагыйдәләре

1. Дошманың үлсә, булма шадман,
Кем үлемдин булмас һич кеши азад.
2. Кем ки кыйлдый синең сериңне фаш,
Дуст кыйлмагыйл аның берлә киңәш.
3. Итәгең берлә сөрмә йөзеңни.
4. Ишегеңне тотканны каулама.
5. Балчык, тупрак илә йума кулыңны.
6. Адәм углыйна уйку әйләр зыйан,
Гәр тәнеңдә булса җаның — уйан!
7. Садакә биргел, кайтсын синдин бәля,
Кыйлма үзиңни бәляга мөбталя.

8. Бусагага утырма.
9. Чалма белән нә бизәрсең башыңны,
Җәһәд кылыб бирә күр ачларга аш,
Чалмаңны йыртып, гидайларга өләш.
10. Сүзне андаг әйт, кем, гәр булса фаш,
Димәсен һичкем күзең өстен каш.
11. Гакыйль ирсәң, дошманга укъ атмагыйл,
Уйкусындин фитнәне уйатмагыйл.
12. Тоттың ирсә, кисмә дошман башыны,
Гакыллы ирсәң сачгел аңа ашыңны.

Бу шигырьнең мәгънәсе татар тарихында Олуг Мөхәммәд ханның Василий Дмитриевич дигән Мәскәү князен 1432 елда Олуг князь итеп билгеләвенә бәйле. Моңа җавап итеп Мәскәү князе Василий 1437 елда авыр хәлдә калган Олуг Мөхәммәдкә каршы зур — 40 мең кешелек гаскәр җибәрә. Ханның гаскәре фәкать 3 мең чамасы булып, сугыш бик каты була, татарлар рус гаскәрләрен тар-мар китерәләр. Василий Олуг Мөхәммәд кулына әсир булып төшә. Шул вакытта Олуг Мөхәммәд русның имансыз князен хыянәте өчен үтерми, исән калдыра [8].

8. Һади Атласи. Казан ханлыгы // Атласи Һади. Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. — Казан: Татар.кит. нәшр., 1993. — 218 б.

13. Һәмдәми, дөнья кууны гаеплә, алтынга табынучылар шайтанга сатылучылар дип саный:
Алтын өчен сүвмә дөнья шәһрини,
Кем күрерсен ул йаманның зәһрини.
Агъзын ачыб бу йылан агу пошман,
Һәр кеши ки гакыйлдур, аннан качан.

Бу ике шагыйрьнең дә әсәр кульязмалары, нигездә, бүгенге Татарстан чикләрендәге һәм аның чигенә якын булган бер татар авылында табылганнар. Аларны Башкортстанның кайбер милли галимнәре башкорт әдәби мирасы итеп күрсәтергә тырышалар. Ләкин ике шагыйрь дә, нигездә, Казан һәм татар авыллары белән генә бәйләнгәннәр. Башкорт коллегаларыбызның бу фаразлары нигезсез.

9. Дәүләтшин К.С. XVIII гасыр шагыйре Мәүла Колый. — Уфа: РИЦ БашДУ, 2010. — 51-52 б.

Мәүла Колыйның хикмәтләре арасында №5 дип билгеләнгән хикмәте бу ике шагыйрьнең бәйләнешләрен һәм яшәеш рәвешләрен күрсәтә торган бер чыганак булып тора [9].

Безнең Һәмдәми әсәрләре таралыш географиясен, хронологиясен өйрәнүебез шагыйрьнең иҗаты, һичшиксез, 1660 елларга хәтле күптән башланган икәнен раслый. Аның әсәренең структурасы Мәүла Колый хикмәтләре тематикасына якын тора.

Һәмдәми XII гасыр фарсы шагыйре Фәрдетдин Гаттарның «Пәнднамә» әсәрен иҗади тәрҗемә юлы белән эшләгән һәм ул бу иҗат методын Сәйф Сараи, Хисам Кятибләр үрнәгендә ала. «Нәсихәтнамә» авторы, һичшиксез, Бохара мәдрәсәләрендә белем алган. Әлеге әсәрдән авторның инде тормыш тәҗрибәсе, зур белемле кеше булганлыгы аңлашыла. Ул, һичшиксез, татар дөньясының танылган лидеры була.

Степан Разин һәм Хәсән Карачурин тарафыннан 1671 елда Казан татарларын баш күтәрүгә өндәп язылган тарихи хатта халык арасыннан дүрт лидер телгә алына. Алар — Икшей мулла (Ишкәй мулла), Мамай мулла, Ханыш морза, Мәскәү морза исемле кешеләр.

Бу шәхесләрдән Ханыш (Каныш) морза Яушев Татарстанның хәзерге Әтнә төбәге Олы Әтнә авылында яшәгән. Тулы исеме — Каныш (Ханыш) Ишмәмәт улы Яушев (морза). 1656 елда [10] 23 дисәтинә җир биләгән. Бу нәселнең токымнары әле дә Күшәр авылында яши.

Искә алынган Мәскәү морза Хуҗаш улы Сөендеков исә Татарстанның Питрәч районына керә торган Татар Тау Иле авылында 1656 елларда яшәгән, 170 дисәтинә җир биләгән [11]. Бу нәселдән атаклы Әхмәтһади һәм Садри Максудилар чыккан.

Өченче зат — Ишкәй мулла Татарстанның Теләче төбәгендәге Максабаш авылында яшәгән. Иштирәк Хафиз Ишәй суфи углы да шул авылда 1681 елда үлгән [12]. Хәсән Карачурин язган хатларны Тау ягындагы Каратай авылына илтеп ул тараткан.

Дүртенче затның исеме — Мамай мелла. Аның турында Мәүла Колыйның бишенче «хикмәт»ендә бай гына мәгълүмат сакланган. Хикмәттән аңлашылганча, Мамай мелла Мәүла Колыйның остазы булган.

Мелла Мамай Аллаһка гашыйклар рәтендә йөргән зур суфый галимнәрдән саналган. Әлеге «хикмәт»тә аның, халыкка «Коръән»гә керүне җиңеләйтү өчен, тәфсир төзегәнлеге дә аңлашыла. Мамай мелла Казанда мәдрәсә һәм көтепханә төзи, күпсанлы мөридләре дә булуы мәгълүм. Мәүла Колыйга да ул үзенең иҗазәтен биргән. Кызганычка каршы, татар суфиларының XVII-XVIII йөзләргә караган силсиләләре сакланмаган.

Мелла Мамай Болгарда һәм Бүләр шәһәрендәге борынгы дөрбәләрне торгызган. Дөрбәләр янына Казан өязеннән үзенең мөридләрен дә күчереп утыртканлыгы турында тарихи хәбәрләр сакланган [13]. Мелла Мамай бу эштә Каныш (Ханыш) морза Яушев белән берлектә эшләгән.

Мелла Мамайның дөрбәләр торгызып йөрергә нинди матди нигезе булды икән? Зөя өязенә караган бер документта 1656 елларда таза хәлле Камай Мамаев дигән морза искә алына [14]. Камайның бу вакытта яхшы эшкәртелгән дистәләгән иген кырлары, печәнлек җирләре булган. Әлеге кешенең Мелла Мамайның улы булуы бик мөмкин, чөнки бу Казан имамының үз матди җирлеге булмаган булса, яшьлегендә Бохара якларына барып гыйлем ала алмаган булыр иде.

Мәүла Колый хикмәтеннән күренгәнчә, Бүләр шәһәрендә Мелла Мамайның остазы — шәехнең дөрбәсе булуы да аңлашыла:

10. Писцовая книга Казанского уезда 1647-1656 годов. — М., 2001. — С.180.

11. Писцовая книга... — С.202.

12. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую этнографику. — М.—Л.: Изд-во АН СССР, 1960. — С.320.

13. Шагыйрь Мәүла Колый шәҗәрәсе турында // Әхмәтҗанов Марсель. Татар кулъязма китабы. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2000. — 80 б.

14. Перечневая книга Свияжского уезда. По материалам писцового описания 1646-1652 годов. — Казань, 2004. — С.38.

Остазым газизләрдин мәдәт табты,
Балүм хуҗа эстанәсен әүвәл япты,
Андин соң шәехга эстанә тәмам итте,
Шәһре Болгарда ике эстанә төзди дуслар.
Остазым мәгъсыйәтдән әман ирди,
Туган йири Сенбер-Казан ирди.
Мәсҗед эчрә менбәр үзрә имам ирди,
Ул мәками куйдый, рихләт итди дуслар [15].

15. Дәүләтшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый. — Уфа: РИЦ БашДУ, 2010. — 298 б.

Китерелгән мәгълүматлардан Мамай мелланың Бүләрдә һәм Болгарда эстанәләр торгызып йөрүе, Бүләр зиратында Мамай мелланың шәехе күмелгән булу, Балум хуҗа дөрбәсен төзәттерүе дә ачыла. Бу кабергә әле XX гасыр ахырында да татар халкы зиярәт итә.

Шигырь-хикмәттә Мәүла Колый Мелла Мамайның туган җире итеп Сенбер-Казанны күрсәтә. Шул җәһәттән, Тау ягында 1646-1652 елларда яшәгән Камай Мамаев дигән морзаның язмышы кызыклы [16]. Бу морзаның Сәет дигән авылда 10 дисәтинә эшкәртелгән җире һәм 600 печән кибәне була. Әлеге милектән хисаплаган вакытта, Камай Мамаев шактый бай, хәлле кеше булган [17].

Мелла Мамайның Казан-Сенбер кешесе дип аталуы очрагыннан аның нәселе Иделнең Тау ягыннан икәнлеге раслана [18]. Ничек кенә булса да, Мелла Мамайның йомышлы татарлар арасыннан, Тау ягыннан икәне ачыла, Казанда мәдрәсә, китапханә салдыруы хәлле гаиләдән икәнен раслый.

Ихтимал, Мелла Мамайны хаҗга уллары озата баргандыр, карт кешенең шундый озын һәм авыр юлга берьялгызы чыгып китүе икеле. Аның үлеме турында да, Казанга кайткач, юлдашкардәшләре хәбәр иткәнлеге күренә.

Мәүла Колый, остазы үлгән вакытта, инде Казанда яшәмәгән, Мелла Мамай мөридләрен туплап, Бүләрдә гомер иткән. Остазының үлемен Болгар шәһәре тирәләрендә 1088 (һиҗри), 1677 (милади) елда ишеткән.

Мелла Мамайның «Нәсихәтнамә» әсәре татар поэзиясен XVII йөздә яңа биеклеккә күтәрде һәм ул шул чорда Мәүла Колый, Габди, Мансур Борындыкый, Габдрахман Тайсуганый, Габдессәлам кебек шагыйрьләрнең үсеп чыгуына этәргеч бирде. Ул дәвердә XVI гасыр татар шагыйре Мөхәммәдьяр кебек әдипләрнең мирасы киселеп, татар поэзиясенең Казан ханлыгы чоры фәкать Мөхәммәдьярда туктап калды. Һәмдәми исә татар поэзиясенә куәтне фарсы шагыйре Фәрдетдин Гаттардан алып, аның фикерләрен татарча яңгыратып, татар поэтик чишмәсенә яңа юл салып җибәрә. Әлбәттә, XVII гасырдагы татар поэзиясенең яңарышына татар халык поэзиясенең куәте дә зур көч биргән.

16. Перечневая книга Свияжского уезда. По материалам писцового описания 1646-1652 годов. — Казань, 2004. — С.38.

17. Перечневая книга… — С.38.

18. Дәүләтшин К.С. XVII гасыр шагыйре Мәүла Колый. — Уфа: РИЦ БашГУ, 2010. — 298 б.

28 март, 2012 ел

#ҺӘМДӘМИНЕҢ «НӘСИХӘТНАМӘ»СЕННӘН ҮРНӘКЛӘР

№1 [Пәнд нәсихәт]

…Һәр кешинең кем, ирүр күб дошманый
Кайгу утындин ирүр җаный — тәни.
Һәр кеши кем гыйәли[1] күб торур,
Кайгудин бикем ичи күб торур[2].
Түрт[3] эшдүр кем ирүр гайни[4] хата —
Кем ки булса Тәңредин табгай гата[5].
Басма асуның ишекигә кадәм[6],
Кем йыракдин күрсәң, аны сорма һәм
Нәкасиниң[7] эшин бийурма зинһар,
Эш бийургыл аңа, чиктер интизар[8].
Биһөнәрни[9] дуст тотмакдур хата,
Гәр аны[10] дошман дисә булгай рәва[11].
Йөз гавер[12] ики кешедин фәкыйрь[13],
Әйтелеш — тиңлә икәвен бер-бер.
Берси дошмандыр йөзи кара,
Кем имәс аның йөзен күрмәк рәва[14].
Бери һәм йөз дүндүр[15], әйлә дустыйн,
Кем сини, әйлә, чыкардур пустдин[16].
Моттасән[17] дошман күзидин бул йырак,
Сал белеңсез дуст йулыйна фирак[18].
Халыкның йөзиндә[19] каты сүз димә[20],
Соңра сагыйш кыйл пәшәманлык йимә[21].
Гәр ишетсә йахшы сүзни фәкыйрь,
Андыйн артукдур ки кидүрсәң хәрир[22].
Билгәсин[23] кичүрмәк ирәнләр[24] эши,
Ир дорур — каһәрни[25] йотса кеши.
Һәр кеши булмаса ил берлә эши,
Гомеренең билмәс хозурдин кыши.
Дөньйада һәркемдә кем йукдур хәййа[26],
Җеремә йил бардур аслыйнда хата.
Һәр кешинең хәййаси[27] аздырур,
Асылсызлыкдин ишини эздүрүр[28].
Асылсызыклардин изүңни тот йырак,
Чик мөлләмәтләрдин[29] уңны пырак[30].

[1] Гыйәли – бала-чагасы
[2] Ичи күб торур – эче күбеп торыр
[3] Турт – дүрт
[4] Гайни – әһәмиятле
[5] Гата – бүләк
[6] Кадәм – аяк
[7] Накәсинең – кешелексезнең
[8] Чиктән интизар – зарыгып көтүгә куй ул кешене
[9] Биһөнәрни – һөнәрсезне
[10] Гәр аны – әгәр аны
[11] Рәва – яраклы
[12] Гавер – имансыз
[13] Фәкыйрь – ярлы
[14] Рәва – ярый
[15] Йөз дүндүр – йөзеңне бор
[16] Чыкардыр пустдин – тиреңне чыгарыр
[17] Моттасән (мөттәсыйль) – өзлексез
[18] Фирак – аерылып кит
[19] Халыкның йөзиндә – халык каршында
[20] Димә – әйтмә
[21] Пәшәманлыйк йимә – буш эш белән йөрмә
[22] Хәрир – ефәк
[23] Билгәсин кучермәк – күңелдән искә алу
[24] Ирәнләр – изгеләр
[25] Каһәрни – кайгыны
[26] Хәййа – оят
[27] Хәййасы – оятсызлыгы
[28] Эздүрүр – өздерер
[29] Мөлләмәтләрдән – шелтәләр, гаепләүләрдән
[30] Уңны пырак – уңга кит

№2 [Пәнд нәсихәт]

Сигез эшдин хурлык күргәй кеши,
Гакыл ирсәң кыйлма зинһар ул эши.
Башда улдур, кем чебен тик һәр заман,
Булса анда иксез[31] кешигә миһман[32].
[Хәййа][33] өндәксез[34] кешинең ашыйна,
Хәййа ардур, һәр кем барур үз башыйна.
Бери һәм һәр сүзни белмәй әйтәр,
Бери һәм әйтеб сүзүндин танар.
Кем тамыгъдин[35] падишаһны хар[36] итәр,
Хурлыкдин үзини пәймар[37] итәр.
Чөн колак тотмасын җәмәгать сүзигә,
Чик телеңни ә пәх(е)т[38] булгыл үз сүзиңә.
Содурлардин[39] кем ки ултурса бик,
Хурлыкдин син рәкым[40] адина чык.
Дошманыңдин кыйлма[41] хаҗәт, кыйл хәзар[42],
Кем әйтмәстүр хурлык андин бәдтәр[43].
Асылсызлардин морадыйң эстәмә,
Хурлык берлә үзеңә кыйтымә[44].

№3 [Пәнд нәсихәт]

Дөньяда алты нәмәрсә җау[45] бетерүр,
Бери күкчек[46] миһербан[47], мәхбүб матур,
Берси һәм йахшы, ләззәтле тәгам[48].
Кем хәлал[49] ирсә сиңа йавык[50] хәрам[51].
Йахшыдур ул һәм ки хуш халак[52] вә чәст[53],
Эстәң сүзни мәхалинә[54] дөрест.
Ул ки йуктур кыйммәти галәмдә ул,
Гакыл камилдүр[55] барындин шад бул.
Кем ки гайбәтдин тилени багладый[56],
Бел ки шәйтан ләгыйнни ул дагладый.
Һичкемнең гайбәтин йөзинә бәрмәгел,
Намусындин һичкемни айырмагыйл.
Мөэмин ирсәң — сүвмә Тәңри дошманын,
Үз тәниңә күзләр тигүрмә тәнин.
Барчаның морадыйн биргән Хак дорур,
Үзгә дин һәм ким тиләр — ахмак дорур.
Хакдин[57] эстәгән морад[58] бар исә,

[31] Иксез – малсыз
[32] Миһман – кунак
[33] Хәййа – оят
[34] Өндәксез – чакырылмаган
[35] Тәмыгъдин – ач күзлелегеннән
[36] Хар – хур
[37] Пәймар – ???
[38] Пәхет – кысылу
[39] Содурлардин – бер эшкә башлаучылардин
[40] Рәкым – сан
[41] Кыйлма хаҗәт – соранма
[42] Кыйл хәзәр – саклану кыл
[43] Бәдтәр – начарлык
[44] Кыйтымә – начар кылма
[45] Җау – сугыш, дошманлык
[46] Күкчек – бөек
[47] Миһербан – шәфкать
[48] Тәгам – ризык, аш
[49] Хәлал – йараклы
[50] Йавык – йакын
[51] Хәрам – тыелган
[52] Халак – әхлак
[53] Част – хәрәкәтчән, тиз
[54] Мәхалинә – чара
[55] Камилдүр – тулыдыр
[56] Тилени багладый – телен бәйләде
[57] Хакдин – Алладин
[58] Морад – максат, теләк

Халикъга йалбар[59] гаклың бар исә.
Һәркемнең куркунычдур хакъдин иши,
Бигөман[60] бил, куркар андин кеши.

№4 Пәнд нәсихәт

Миһман[61] Тәңри гатасыйдур[62] сиңа,
Миһманең килсә, гыйззәт[63] тот аңа.
Һәр кеши хезмәт кыйлур — миһманинә,
Үзинә йавык әйләр Хак рәхмәтинә.
Кем ки миһманә хуш йөз күрсәтүр,
Хак Тәгалә беринә-йөз күрсәтүр.
Миһман бер һәдийә[64] дүр Алладин,
Һәр кешигә бел килү нәгяһдин[65].
Кем ки баглар капусин[66] миһманинә,
Тәңре ләгънәт әйләтебдүр җанинә.
Җәһәд[67] кыйлгыл, бүлмә, әлбәттә, миһманә,
Миһман һәм килсә качма хилвәтә[68].
Миһманың булса һәркем хасс[69] гам,
Хәййалыйк[70] кыйлма, куй алдыйда тәгам[71].
Бирә күр Тәңри өчүн ачларга нан,
Та ике галәмдә булгайсын ашан.
Кем ки бирсә бер йалангач тәнгә тун,
Хак гавази[72] биргәй һәр беринә ун!
Әйләгел миһманә гыйззәт и, хәлил[73],
Та[74] газиз[75] итсүн сини Рабби[76] җәлил[77].
Бил бәхилең нанины[78] раныж[79] гына,
Әснабийә[80] наны булур нур сафа.
Өндәмәй кешигә булма миһман,
Булдун ирсә хур булдуң бигөман[81].
Йахшылыйк күр, тотмагыйл нәҗес[82] нидин,
Кем имәс нәҗси булгай инесидин[83].
Хәйерәтиндә[84] һич кем хәб[85] күрмәгил,
Билмәс ирсәң[86], үз төшеңни йурамагыйл!

№5 Пәнд нәсихәт

Өч галәмәт ахмакныйң затындадур,
Бу ривайәт Тәңри айәтиндәдүр.
Колы — йалгандыр, гәр — Тәңри аз,
Һәм өченчи, бел аны — кяһил[87] намаз.
Әй, йегет, кяһиллеккә нан[88] бирмәгил,
Тагать[89] ит күңлеңни, йатыб кермәгил!
Һәр кеши хак йадидин[90] гафил[91] дорур,

[59] Халикъга – Аллаһка
[60] Бигөман – шиксез
[61] Миһман – кунак
[62] Гатасыйдур – кунагыдыр
[63] Гөйззәт тот – хөрмәт ит
[64] Һәдийә – бүләк
[65] Нәгяһдин – көтмәгәндә
[66] Баглар капусин – ишеген бикләр
[67] Җәһәд – сәбәп
[68] Хилвәтә – аулакка
[69] Хасс – тоючы
[70] Хәййалык – оятлык
[71] Тәгам – аш, ризык
[72] Гавази – өстәп, алмашка
[73] Хәлил – якын дус
[74] Та – фарсы телендәге кисәкчә; «шунда хәтле», «шуның хәтле» дигән мәгънәгә ия
[75] Газиз – бердәнбер
[76] Рабби – Аллаһ
[77] Җәлил – бөек
[78] Нанины – ипиеңне
[79] Раныж – авыруга
[80] Әснабийә – синең
[81] Бигөман – уйламаганда
[82] Нәҗес – пычрак
[83] Инесидин – энесеннән
[84] Хәйерәтиндә – хәерендә
[85] Хәб – ваклык
[86] Билмәс ирсәң – белмәсәң
[87] Кяһил – ялкау, иренчәк
[88] Нан – икмәк
[89] Тагать – буйсыну
[90] Йадидин – күңленнән
[91] Гафил – сизмәүче

Бел ки, ахмаклыйк кыйлур, батыйл[92] дорур.
Тәңре хикмәтендин кайырма буйының,
Кем бычак астында гаҗиздүр, куйуң!
Дустмын — дип, тотма һәркемниң кулыйн.
Бари тормай күр ирәнләрнең йулыйн,
Сакла намәхрәм[93] йөзендин күзеңни.
Элгәри бел гали… кә төз йулыңны,
Игри… күзл… төз йулыңны.
Куй таммигъни[94] бар исә синдә тәмиз[95],
Та ики галәмдә улгайсын газиз.
Әйтмә һәр кимгә булса зарыйңны,
Кем бери килсә күтәрмәс зарыңны.
Итмә золым итеб, алма йәтим малыны,
Рәхим итеб сорагыйл аларның халини.
Өч галәмәттүр шакыйларда[96] белең,
Гәр шакый килсә, кыйлуңыз ни илең.
Башда бер үләксә тәһарәтсез дорур.
……………… йыракдин…………………
……………… халыкъдин һәм ни эстәр, ни сорар?
……………… эстәсә, тамагыйна урар.

№7 Пәнд нәсихәт

И, мөселман, гәр теләрсең син абруй[97],
Түрт эшдин кыйл хур сүзгә уй.
Һәркем артында олугларны сүгән[98],
Гакыйбәт[99] үз абруйыны үз түгәр.
Ил кашында кемдә йукдур әдәб,
Үзинең сүзи түгүлсә ни гаҗәб?
Тәрк[100] кыйл йалганчылыкныйң дуыйный[101],
Кем ки тәркәй[102] йалган йөзнең сөйини.
Гыйззәтеңни кыйл, йөклик[103] кыйлмагыйл,
Абруйың сагыйн[104] айырылмагыйл.
Гәр җиһан эчрә теләрсең абруй,
Куй йаман эшләрни, кыйл йахшы уй.
Кибер[105] вә тәхмин[106] күңелгә салмагыйл,
Бизыйалыкны бу йулга алмагыйл.
Бул хилафәтдин[107] зыйанындин йырак,
Ничә кем булсаң йырак, ул йахшырак…
Һәр нә әйтерсүн, и, гакыйл чыйн[108] әйт,
Кайда кем йалганчы күрсәң, барма — кайт!
Эстәрсәң йахшы дигәйләр ил сини,
Бар димәсин йаман һич кем сини.
Түрт эшдин абруйың артар ит,

[92] Батыйл – пычрак
[93] Намәхрәм – ят, чит
[94] Таммагъни – комсызлыкны
[95] Тәмиз – чиста, пакь
[96] Шакыйларда – мәшәкатьләрдә
[97] Абруй – дәрәҗә
[98] Сүгән – сөйгән
[99] Гакыйбәт – азакта, ахырда
[100] Тәрк – ташла
[101] Дуйыный – чүбе
[102] Тәркәй – ташлый
[103] Йөклик – авырлык
[104] Сагыйн – тазасын
[105] Кибер – тәкәбберлек
[106] Тәхмин – чамалауны
[107] Хилафәтдин – урынбасарлык
[108] Чыйн – чын, дөрес

Әйтәлем бер-бер ул түрт эшләрни, ишет.
Әүвәл кермә дөньйалыкыйң гәр бар исә,
Ас казан, дөньйада, гаклыйң бар исә.
Белген эшеңни теләрсәң абруй,
Йахшы йылмай, кыйлма эшни гаклә уй.
Бар кичүргин халыкдин күрсәт вафа[109],
Саклагай абруйыңны Хода.
Һәр кешинең кем ирүр йахшы сүзи,
Арттырур үз абруйыны үзи.
Дошманлардин күрмәйем дисәң зыйан,
Сериң әйтмә дусларга һәм гайан[110].
Үз кулыңа куймаганны алмагыйл,
Ил катында соң буйанга калмагыйл.
Гайебен ачма үзгәләрнең, и фәкыйрь,
Кем синең һәм гайебең ачар үзгә бер.
Үзгәнең кадрини и бел, мөхтәрәм[111],
Та[112] синең кадрең белгәй үзгә бер һәм.
Кем ки дөньяда әйтүрди гыйз [зәт][113] телин,
Улдур белмәсен териклик ләззәтин.
Кем дә кем йукдур канәгать[114] уйы бел,
Гури эчрә чайандин [катый] бел.
Дошманың илгә төшәсинә шад кыйл,
Илгә килсә, аны азад кыйл.
Барсалар сөхбәтини[115] кыйл таләб,
Бул тәвазыг[116] берлә булма би әдәб[117].
Хушдардур белең данә[118] сүзи,
Агудыр надан сүзи, белкем үзи.
Белки агудин булур катыг хәййат,
Хуш дарудин табар идсәм нәҗат[119].
Һәр кешидә кем тәвәккәл йук дорур,
Үзини йөз мең бәляга йулыкдорур.
Гәр тәвәккәл әйләгерсәң йула,
Кайда барсаң, Хак сиңа йулдаш була.
Һәр кешидә Тәңри гыйшкы булмаса,
Син аны үтүр, үзи үлмәсә!
Кем ки җәйә хәйасездүр җансыз,
Бихәйалар[120] белең аны — имансыз.
Бер хәйалыкдин таба иман рәван[121],
Бихәйалык кылма, Тәңридин ойал.

Нәсихәтләрне иске татар язуының тәкъликъ
ысулыннан хәзерге графикада укылышын филология
фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов бирде,
аларга сүзлекчәләр төзеде.
31 март, 2010 ел

[109] Вафа – тотнаклылык
[110] Гайан – ачык
[111] Мөхтәрәм – хөрмәтле
[112] Та – фарсы телендәге кисәкчә; «шунда хәтле», «шуның хәтле» дигән мәгънәгә ия
[113] Гыйз[зәт] – хөрмәт
[114] Канәгать – риза
[115] Сөхбәтини – әңгәмәдәш
[116] Тәвазыг – түбәнчелек
[117] Би әдәб – әдәпсез
[118] Данә – энҗе бөртеге
[119] Нәҗат – котылу
[120] Бихәйалар – оятсызлар
[121] Рәван – китүче

ЙӨРӘК ҖЫРЛЫЙ

ФЛЁРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

Сабан туе гөрли болыннарда,
Йөрәк җырлап җиңү маршы суга.
Тәбриклибез хезмәт батырларын,
Кош очыртып кояш каршысына.

Сабан туе тәмам кызып ята:
Яшь киленнәр йөгереп судан кайта,
Күзен бәйләп егет чүлмәк вата,
Кызлар түли назны кояшлата.
Трат-та-та! Трат-та-та!

Киләчәккә булган өмет сула,
Батыр үз көндәшен җиңалмаса.
Җиңү теләп хезмәт батырына,
Гасыр белән гасыр бил алыша.

Гасырларга илтер һәр ярышның
Җилкендереп торган моңы була:
Җиргә кайнар тояк моңы кагып,
Мәйданнарга атлар томырыла.

Күтәрепләр сайрый җырчы тургай
Сабан туен үзәгенә күкнең...
Мәйдан тоткан батыр көрәшченең
Йөзе якты, күз нурлары үткен.

«УНҖИДЕНЧЕ ЕЛНЫҢ АЛДЫНДА УЯНДЫК БЕЗ КӨЛЕП...»

(ӘБРАР СӘГЫЙДИ ИҖАТЫНДА БЕР ТУКТАЛУ)

ФӘРИДӘ ХӘСӘНОВА,
филология фәннәре кандидаты,
КФУ доценты

ӘБРАР ЗАКИР УЛЫ СӘГЫЙТОВНЫҢ БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬЛӘРЕ МАТБУГАТТА XX ГАСЫРНЫҢ УНЫНЧЫ ЕЛЛАРЫНДА КҮРЕНӘ БАШЛЫЙ. ДИМӘК, БУ ШИГЫРЬЛӘРНЕҢ ДӨНЬЯ КҮРҮ ВАКЫТЫННАН СОҢ 100 ЕЛЛАП ВАКЫТ УЗГАН. БҮГЕН МОННАН БЕР ГАСЫР ЭЛЕК ШАГЫЙРЬЛӘРНЕ НИНДИ ПРОБЛЕМАЛАР БОРЧЫГАН ИКӘНЛЕГЕНӘ КҮЗ САЛСАК, БЕР ДӘ АРТЫК БУЛМАС КЕБЕК. ӨСТӘВЕНӘ, Ә.СӘГЫЙДИНЕҢ 1992 ЕЛДА ЧЫГАРЫЛГАН ТАТАР ПОЭЗИЯСЕ АНТОЛОГИЯСЕННӘН ДӘ ТӨШЕП КАЛУЫ (ТӨЗҮЧЕСЕ – Г.РӘХИМ), «ӘДИПЛӘРЕБЕЗ» (2 ТОМ, ТӨЗҮЧЕЛӘРЕ: Р.ДАУТОВ, Р.РАХМАНИ) БИОБИБЛИОГРАФИК БЕЛЕШМӘЛЕК РАСЛАВЫНЧА, ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТЫ ТУРЫНДА БАРЫ ӨЧ КЕНӘ ЯЗМА БАСЫЛГАН БУЛУЫ, ӘЛЕГЕ МИРАСКА 100 ЕЛДАН СОҢ ӘЙЛӘНЕП КАЙТЫП БУЛСА ДА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮНЕ СОРАП ТОРА ТОРГАН ФАКТ. Ә.СӘГЫЙДИ ИҖАТЫНА КАРАТА СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ТАНЫЛГАН ТЕКСТОЛОГ ГАЛИМ ЗӨФӘР РӘМИЕВНЕҢ ДӘ ХЕЗМӘТЕ БАСЫЛЫП ЧЫГУЫН ИСКӘРТЕП ҮТҮ УРЫНЛЫ БУЛЫР.

Әмма, безнең карашыбызча, күрсәтелгән хезмәтләр Ә.Сәгыйдине шәхес буларак, тагын да төгәлрәк әйтсәк, «давыллы дәвер шагыйре» (Марат Закир), «катлаулы чор һәм шагыйрь язмышы» (Зөфәр Рәмиев) ягыннан яктыртуга юнәлтелә. Аларда шигырьләрнең поэтик кыйммәте билгеләнми, шагыйрь буларак осталыгы ачылмый кала. Бер мәкалә кысаларында мондый зур бурычны тулысынча тормышка ашырып булмавын аңлаган хәлдә, проблемага укучы игътибарын гына булса да юнәлтеп куйыйк дип эшкә керешәбез.

Әбрар Сәгыйди (икенче рәттә уңнан өченче), Кәрим Әмири (уңнан икенче) яшь татар мөгаллимнәре әзерләү курслары шәкертләре белән. 1917-1918 еллар.

Күренекле татар галиме, шигърият белгече Хатип Госман билгеләп үткәнчә [1], «бу елларда (XX гасырның 20 еллары) поэзияне аерым алып тикшергән хезмәтләр булмаган. Жанрның үзенә караш, аның казанышларын бәяләү, кимчелекләрен тәнкыйть итү аерым шагыйрьләрнең иҗатларына караган мәкаләләрдә генә гәүдәләнгән». Х.Госманның бүгенге көн өчен үзе үк кыйммәтле мирас булган әлеге хезмәтендә дә Ә.Сәгыйди шигырьләренә анализ сизелми, бәлки, шагыйрьнең теге яки бу китабы чыгу уңае белән берничә информация генә бирелә. Ә менә Ф.Бурнаш, Һ.Такташ, М.Гафури, С.Рәмиев, Х.Туфан, Н.Исәнбәт, Д.Фәтхи кебек шагыйрьләр иҗатын галим тәфтишләп карый. Бигрәк тә традицияләр һәм новаторлык мәсьәләләрен алгы планга чыгара. Шулай да галимнең кайбер фикерләре бүген бәхәс уятырлык дәрәҗәдә беркатлы кебек тоела. Менә шуларның берсе: «Поэзиядә туган яңалыклар тиз үсеп киткән булырлар иде. Ләкин тагын бер бәхетсезлек килеп чыкты: 1921 елның көзендә Идел һәм Урал буйларында коточкыч ачлык башланды. Партия һәм хөкүмәт ачлыкка каршы көрәшкә кереште. Бу эштән язучылар да читтә калмады» (күрс. хезм., 88 бит).

Хезмәттә алга таба Г.Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте, М.Гафуриның «Ачлык тырнагында» исемле җыентыгы телгә алына. Галим Х.Госман язучыларны ачлыкның сәбәпләрен дөрес күрсәтә алмауда гаепли һәм «ачлык фаҗигасе өчен империализм һәм контрреволюция гаепле иде» дигән катгый нәтиҗәсен чыгара (күрс. хезм., 89 бит). Такташның «Күләгәләр» шигыре, сурәтләүдә романтик-психологик алымнар куллануы сәбәпле, каты тәнкыйть утына тотыла.

Ачлык темасын шагыйрь Ә.Сәгыйди дә читләтеп үтми. Әмма әлеге ши-

гырьләр, ни сәбәпледер, үз вакытында бөтенләй искә дә алынмый кала. Менә 1917 елда Казанда чыккан «Ирек азаны» китабындагы «Булдырды» шигыреннән берничә өзек [2]:

Бетте байлык илдә,
ачлыктан бөтен җан зарлана,
Кемгә очрасаң да,
ул тик тормышыннан зарлана.
...Илдәге байлыкны читләргә
озатты һәрвакыт,
Халкына белгерми уртын,
бәдбәхет торды сатып.

...Без тигезләр: хөррият барсын,
баетыр безне ул,
Шундый шәп тормышлы итәр
бер әле бу илне ул:

Булмас ачлар, бер телемгә
зар елау булмас әле,
Әкрен-әкрен җайланыр,
тормыш шулай тормас әле.

Бай булырбыз һәммәбез без,
һәммә җан бер тук булыр,
Безнең ил, дуслар, әле бер пакь,
саф алтыннан тулыр.

Шигырьдә егерменче еллардагы ачлыкны китереп чыгарган сәбәп ачык күрсәтелә һәм ул бердәнбер сәбәп булып чыга: ул да булса Совет системасы ясалма рәвештә китереп чыгарган ачлыкка күпкә алдан атып үтерелгән Николай патша гаепле икән?!

17 бәет строфасыннан гыйбарәт булган әлеге шигырь тулысы белән «бәдбәхет елан патша Николайны» фаш итүгә юнәлдерелә. Әмма әсәр барыбер өмет белән тәмамлана. Хөррият ачлыкны барыбер бетерәчәк, дигән фикер җиткерелә. Әмма ул «Хөррият» булмаган ипине кайдан алачак, анысы турында ләм-мим.

Шигырь «Булдырды» дип исемләнгән. Әсәрнең эчтәлегеннән чыгып карaганда, әлеге исем ироник планда алынган дип уйларга урын калдыра. Атып үтерелгән патшаның әлеге ачлыкка турыдан-туры катнашы була алмый дип фараз итсәк, «булдырды» дигән ирония яңа хөкүмәткә сатира формасында кабул ителә. Әмма Ә.Сәгыйди үзе мондый карашны шигырь юллары арасына «яшергәндер» дип уйлау дөреслеккә туры килмәс иде. Агитация шигырендә эзоп теле яшеренә алмас.

Ә.Сәгыйди күпчелек шигырьләрен бәет строфасы белән язган. Янәшә рифмалардан файдаланган. Рифмалары бик гади, нигездә бер үк сүзне кабатлаудан ясалган. Шигырьдә ритм аксый дигән фикер кала. Прозаизм үзен бик нык сиздерә. Бездә шагыйрь сәяси-публицистик шигырьләрен бик теләп язмагандыр дигән тәэсир калды. Аларда, мәсәлән, пейзаж лирикасы шигырьләре белән чагыштырганда, шигъри гармониянең дә бозылуы күренә. Гаруз аһәңен дә тулысынча тоеп булмый. Бәлки, сәяси публицистиканы силлабика белән язу кирәктер.

Шундый шигырьләрнең берсе «Әйдә Уралга!» дип атала. Бу — «кызыл шигырь». Биредә «саф кызыл байрак», «кып-кызыл Урал», «кызыл илнең җырлары» кабатланып бара. Шагыйрь фикеренчә, бу кызыл төс ахырда кызыл байрак тоткан ачларны якты юлга илтүче бердәнбер юл булып чыга. Шагыйрьнең мондый «агитка» шигырьләре сурәтләү чараларының фәкыйрьлеге белән аерылып тора. Бәлки, ул аларны мәҗбүри язгандыр, дигән фикер дә туып куя.

Хөррият сүзе Ә.Сәгыйди шигъриятендә үзәк урыннарның берсен били һәм төп символ мәгънәсенә дәгъва итә (шулай ук символик «таң» сүзе). Шагыйрь «Кан эчүче» дип исемләнгән әсәренең жанрын хәтта «хөррият по-

Әбрар Сәгыйди (уңнан икенче) дуслары белән Зөя болыннарында. 1930 еллар.

эмасы» дип билгели. Поэма дүрт бүлектән гыйбарәт. Әсәрнең нигезе мондый вакыйгага корыла. Ямьсез кара төн. Авыл. Ачуланып төньяк җиле исә. Агачлар бар да ялангач, дер-дер киләләр. Бәндә йоклый. Әмма явыз тәкъдир залим хәбәр китерә. Хәтта агачларга да кабер казыла. Беренче бүлектә менә шулар турында хәбәр ителә. Күренеп тора: шагыйрь укучыны авыр хәбәрне кабул итәргә әзерли.

Икенче бүлек түбән очтагы бер ызбада моңсу гына ут яну күренешеннән башланып китә. Өйнең бозлы тәрәзәсеннән юаш кына гөнаһсыз нурлар тарала. Җитмәсә, ут та куркып кына яна. Әлеге деталь үзе үк бу шигырьнең «агитка» булмыйча, психологик юнәлештәге әсәр булуы турында сөйли. Бу урында автор, сиздермичә генә, әсәргә үзе дә «кереп китә».

«Ялгыз, мескен, фәкыйрь» эпитетлары аша сурәтләнгән, алты-җиде сабые булган ана образы бирелә. Аның ире ике ел элек сугышка киткән дә югалган. Ярдәмчесе юк, «анага Алла гына юлдаш». Өйдә ашарга бернәрсә юк. Ананың өенә патша урядныгы килгән. Ул җир өчен түләү сорый.

Ә.Сәгыйди иҗатының буеннан-буена сузылып бара торган бер деталь бар: ул да булса начарлыкны елан эпитеты аша бирү, эпитет урыны-урыны белән чиктән тыш көчәеп китеп, метафорага да әверелеп ала. «Булдырды»да Николай патша «елан» булса, «Кан эчүче»дә патша урядныгы еланга «әверелә». Бу урында шагыйрьнең иҗатында XIX гасыр мәгърифәтче язучылары Һибәтулла Салихов, Баһаветдин Вәисев, Яков Емельянов традицияләрен тоярга мөмкин дип әйтү дөрес булыр. Елан метафорасын Һ.Салихов үзенең шигырьләрендә бик яратып кулланган. Аның «еланы» кешелексез бай кеше образы иде.

Өченче бүлек ялгыз ананың явыз урядник белән тарткалашуын тасвирлый. «Кан эчүче вәхшәт»нең кылган гамәлен күктәге йолдызлар гына күрә, алары да чыдый алмый, дөресрәге, җирәнеп сүнәләр. Ай да болыт астына яшеренә. Әлеге бүлек авторның «ярдәм ит!» дип, Ходайга ялваруы белән тәмамлана.

Дүртенче бүлек табигать күренешен тасвирлаудан башланып китә. Тышта буран, җил үкерә. Өйләрне кәфен сарган. Бөтен ил җан иясез кебек буш калган. Урядник әле һаман китмәгән. Хатынның инде хәле беткән. Ул шешенгән, Ходайдан ялварып үлем сорый. Шул рәвешле, ул йоклап китә. Поэманың дүртенче бүлеге, нигездә, Ходайга ярдәм сорап ялваруга кайтып кала.

Күренгәнчә, әсәрдә сюжет үстерелми, вакыйгалар җәелдерелми, бары тик геройның психологик халәте генә урын ала. Билгеле, үгет-нәсихәт тә юк түгел.

Ә менә табигать күренешен шагыйрь үзенчәлекле тасвирлый. Тематик юнәлешкә игътибар итсәк, әлеге иҗатта табигать тематикасы «агитка»дан өстенрәк тә чыга. Ә.Сәгыйди табигать турында шактый күп язган. Билгеле, ул авыл табигатен тасвирлый. Табигатькә крестьян психологиясе аша карый. Шигырьләрнең күбесе кыш фасылын сурәтләүгә юнәлдерелә, яз фасылы да еш очрый. Шагыйрь кышны авыр кичергән булса кирәк. Шигырьләрендә кышкы гүзәллек сизелми. Аның өчен кыш моңсу, рәхимсез, җир кайгылы:

Авыл бик ямьсез, анда күңелсез.
Тик авыл буранда торадыр үксез,

— дип яза ул «Кыш көне авыл» шигырендә. Ә.Сәгыйдинең иҗатында Тукай интонацияләре сизелүен З.Рәмиев тә билгеләп үтә. Менә «Кыш башы» шигырен укып карыйк:

Инде көз китте, кыш башы җитте.
Ап-ак болытлар карларны сипте.

Үзгәрде һава, карлар да ява.
Хәзер ак юрган җир йөзен яба.

Кырлар, урманнар җансыз
калганнар.
Сулар, бозланып, күр, йоклаганнар.

Җилләр дә өрде, карларны сөрде.
Буран, салкынлык берлә кыш керде.

Күрәсең, гасыр башы шагыйрьләренең һәрберсе җылыга мохтаҗ булгандыр. Ә.Сәгыйдинең дә Тукай кебек гел җаны туңган булса кирәк. Һәрхәлдә шигырьләреннән шулай аңлашыла.

Ә менә кыштан язга күчү мәлен ул бик позитив рәвештә сурәтли. Шундый шигырьләрнең берсе «Бетте!..» дип исемләнгән.

Бетте салкынлык, буран-кар,
җил, караңгы кыш хәзер;
Җылмая нурлы кояш,
инде җылынды тыш хәзер.
...Уйганырлар карга күмлеп
йоклаган бар карьялар,
Инде шатланыр бөтен гамьле,
сагышлы бәндәләр.

...Онытылып тыңларбыз без
ул моңлы кошлар өнен,
Гамьле кыш бетте!.. Хәзер күрдек,
шөкер, бу яз көнен.

Шагыйрь иҗатында фәлсәфә бик сизелми. Ул конкрет фикер йөрткән булса кирәк, шигырьләрендә күз белән күреп, кул белән тотып була торган әйбер-күренешләр турында язу өстенлек ала. Әмма «Кызыл чор»да яшәсә дә, шигырьләрендә Ходай, Алла кебек сүзләр күренә. Аның шигырьләрендә яз Ходай кушуы бу-

енча кила, ач кеше Аллага ялвара, хәтта мәктәпкә дә бала Алланы таныр өчен бара. Шуңа «Мәктәп» исемле шигыре матур язылган шигырьләрнең берсе буларак кабул ителә дә.

Дөньяда иң изге йорт шул:
ул танытыр
Алланы,
Анда кергән яктырыр тиз,
тиз таныр ул
Алланы!
Дөньяда иң изге йорт шул:
күрсәтер ул якты юл,
Бар бозык юлдан күңелләрне агарта,
пакьли ул!

Дөньяда иң изге йорт шул:
Ул галим, изге итәр,
Анда кергән бар күңелләрдән
Начарлыклар китәр!

Дөньяда соң кайда ул йорт? —
Улмы? — Изге мәктәп ул!
Мәңге, мәңге якты юлдан
дусларын җитәкләр ул!

Күренеп тора: XIX гасырдагы мәгърифәтчелек идеяләре шигырьдә ярылып ята.

Ә.Сәгыйди иҗатында пейзаж лирикасы белән Туган як патриотизмы бик нык керешеп китә. Дөрес, ул туган ягына аерым шигырьләр дә багышлый (без унлап шигырь санадык). Шулардан «Туган илгә» [3], «Илкәем», «Авылыма» шигырьләрен аерып чыгарып булыр иде. «Туган илгә» шигырен туган авылына мәдхия итеп кабул итү дөрес булыр.

Синдә дус күргән иде, авылым,
рәхәт, шатлык мине,
Һәм дә һәрчак синдәге
бер рахмани пакьлек мине.

Күрмәдем, авылым, сагыш-хәсрәт
дигәнне синдә мин,
Һәрвакытта шат идем
син җанга йомшак илдә мин.

...Күпме моң кошлар җырын
синдә эреп тыңланмаган?
Таңда яңгыраган ачык тәкъбир —
матур, изге азан.

...Бар да булган, әй авыл!
Җырчы балаңны үстереп,
Ташлыйсың, ахры, бүтән җиргә
еракка, чит күреп.

«Илкәем» шигырен [4] татар авылы тарихы дип исемләргә мөмкин. Бала туа. Аңа кечкенәдән үк «һәммә нәрсәдән якын сиңа илкәең» нәсихәте сеңдерелә барыла. Үсә барган саен, бала әлеге җөмләгә охшаш яңгыраган сүзләр эзли. Туган илен мактап җырлар җырлый башлый. Тагын да үсә төшкәч, кап-кара төннәр дә күренә, моңлы җырлар туа башлый. Торабара бу җырлар ярлы халыкның михнәтен чагылдыра. Шуннан соң шигырьдәге интонация капма-каршы якка үзгәрә. Илдә тоташ бәйрәм башлана. Ал-кызыл байраклар балкый башлый. Әмма шигырьгә сискәндерә торган бер юл килеп керә: ул да булса «ачларның көләч айдай балкыган көләч йөзләре». Шагыйрь тафтологияне махсус кулланганмы, әллә шигъри осталык җитенкерәмәгәнме? Әллә көләч йөзле ач кеше образын сатира буларак кабул итәргәме? Безнеңчә, шигырь сатирага ук «барып җитмәгән».

«Авылыма» шигыре [5] шулай ук мәдхия характерында. Шагыйрь биредә авылның пейзажын, таңдагы изге азанын, шәфкатьле ана каберен, игенле кырларын, мәһабәт урманын онытмаячагы турында ант итә кебек.

«Яз матур ул, эш көтә...» [6] шигыре беркадәр XIX гасыр шагыйре Гали Чокрыйның «Фосуле әрбага»сын

хәтерләтә. Шигырь ике бүлектән гыйбарәт. Беренчесендә язгы пейзаж сурәтләнә. Үзенчәлекле детальләрдән «кояшның сабый күк елмаеп чыгуы», «тамчыларның күз яшедәй булуы», «елганың чырлап агуы», «ак болыттай очкан тезмә кошлар» кулланылган. Алда әйткәнебезчә, шагыйрьнең пейзаж лирикасы бик матур язылa, шигъри гармония саклана, рифма, ритм мәсьәләләре дә үз дәрәҗәсендә күренә.

Шигырьнең икенче бүлеге эшкә өндәү характерында. Ул «язның бер көне ел туйдыра» мәкален хәтерләтә. Биредә игенченең яз көне генә эшләп була торган хезмәтләре санала. «Карда чап һәм карда у!» — ди шагыйрь.

Ә.Сәгыйди иҗатының тагын бер тармагын игенче һәм эшче хезмәтләре турындагы шигырьләр тәшкил итә. Эшчегә кагылганы күбрәк тә кебек тоела. Болары, нигездә, 20 нче елларда язылган. Игенче турындагы шигырьләре сурәтлерәк булулары белән аерыла. Әлеге шигырьләрдә сандугач тавышы, «баллар катыш кәүсәр чишмәләр» «күренеп» тора. Ә эшче кеше Ә.Сәгыйдидә сөялле куллы, чүкеч тоткан тимерче образында чагыла. Аның вазифасы — сабан һәм урак ясау. Шулай да шагыйрьнең эшче образына симпатиясе күбрәк кебек тоела. Эшче сыйныфына ул зур өметләр баглый, хәтта «Язгы таңда» шигырендә әлеге детальне аерып та куя.

Эшләңез, әй яшь егетләр,
әйдәңез сез шатланып,
Эшче сыйныфы мәңге, белегез!
Калмас инде таптанып.

Шагыйрь, нинди генә темага тотынмасын, үзәккә һәрвакыт татар милләте язмышын куя. Читләтеп кенә татар халкы өстенә төшкән михнәтне һәр шигырендә әйтә бара. Дөрес, ул турыдан-туры тарихка кагылмый. Әмма гасыр башы тарихын күздән дә ычкындырмый. «Кызыл заман» килгәч, шагыйрь ачлык бетәр дип ышана. Ачлык язучының үзәгенә үткән булса кирәк, һәр өч шигырьнең, ким дигәндә, берсендә ачлык сүзе килеп керә. Хәер, татар шагыйрен язмыш беркайчан да аямаганлыгы билгеле.

XX йөз башы татар әдәбияты тарихында үз эзен салган, ләкин ни өчендер күләгәдә кала килгән Ә.Сәгыйди исемле шагыйрьнең кайбер шигъри әсәрләрен укучылар хөкеменә тапшырабыз. Укучы аны үзенчә бәяләр.

Шагыйрь гади халык — эшче һәм крестьяннарның мәнфәгатьләрен күздә тотып язган, табигать матурлыгын җырлаган, Туган илне сакларга, якларга чакырган.

Бу — безнең тарих. Кытыршы булса да, үзебезнеке...

Искәрмәләр

1. Госман Хатип. Егерменче елларда татар поэзиясе / Хатип Госман. — Казан: КДУ нәшрияты, 1964. — 397 б.
2. Мирас, 2006. — №1. — 42 б.
3. «Тормыш» газетасы, 27 март, 1916 ел. — № 438.
4. «Кызыл Армия» газетасы, декабрь, 1919 ел. — № 228.
5. «Кояш» газетасы, 23 март, 1915 ел. — № 661.
6. «Эшче» газетасы, 2 апрель, 1920 ел. — № 27.

ӘБРАР СӘГЫЙДИ

ТУГАН ИЛГӘ

Синдә дус күргән иде, авылым, рәхәт, шатлык мине,
Һәм дә һәрчак синдәге бер рахмани пакьлек мине.

Күрмәдем, авылым, сагыш-хәсрәт дигәнне синдә мин,
Һәрвакытта шат идем син җанга йомшак илдә мин.

Иркәләп үстерде мин — җырчы балаңны ак көнең,
Ул тын эңгерләрдә, таңнарда сөеп искән җилең.

Яшь күңелгә чын кот, чын рух иде ул саф суың,
Бер сабый төсле була идем сулаган мин, улың.

Иркәләде һәр кошың таңда биреп моңлы аваз,
Кыш соңында тәмле исле, якты йөзле, нурлы яз.

Иркәләде тәмле исләр чәчеп ал гөлләрең,
Тын көмешкә манчылып торган авыл, айлы төннәрең.

Синдә мин, авылым, шулардай күпме ләззәт алмаган?!
Күпме һәр тарсынганында яшь күңел рухланмаган?!

Күпме моң, кошлар җырын синдә эреп тыңланмаган?!
Таңда яңгыраган ачык тәкъбир — матур, изге азан.

Күпме аллы-гөлле чәчкәле кырың тапталмаган?!
Күпме аркамдин һаман шатлык, азатлык какмаган?!

Бар да булган, әй авыл! Җырчы балаңны үстереп
Ташлыйсың, ахры, бүтән җиргә, еракка чит күреп.

«Тормыш» газетасы, 27 март, 1916 ел

ИЛКӘЕМ

Яшь чагымнан ук миңа ятлатты
Бер сүз әнкәем: «Һәммә нәрсәдән сиңа
Бигрәк якын, дип, илкәең».
Мин шушы сүзне, күңелгә
Яшь чак ук бикләп алып,
Һәрвакыт тәкрарладым,
Чиксез сөеп, аулак калып.
Шул матур сүздән тезәргә
Башладым җырларны мин.
Мактый башладым, туган ил,
Болын, кырларыңны мин.
Язгы гөлдәй елмаеп аткан
Матур илнең таңын,
Шаулап аккан чишмәсен,
Зур тауларын, зур урманын.
Шактый үскәч, мин илемдә
Кап-кара төннәр күреп,
Гөл-чәчәкләрен, болынын,
Кырларын җырлап туеп,
Башладым көйләргә илнең
Зарлы, моңлы өннәрен,
Ярлы халкымның газап,
Михнәттә үткән көннәрен.
Җырладым «аһ, бер телем», дип
Егълаган ачлар хәлен,
Җырладым изге бәгырьдән
Кара кан аккан мәлен.
Җырларымнан, мең шөкер,
Илемдә атты гөл-чәчәк;
Ул хәзер, хуш ис чәчеп,
Ил күкрәгендә үсәчәк.
Инде күрәм илкәемдә
Мин хәзер бәйрәм көнен,
Ал-кызыл байрак, көләч айдай
Көләч ачлар йөзен.

«Кызыл Армия» газетасы,
декабрь, 1919 ел

ТАҢ

Таң матурмы? Син сөямсең?
Син сөйсәң, ал таңны сөй.
Таңны сөй, үпсен сине бер,
Елмаеп, таң яктысы.
Син йөзеңне чытма таңга;
Таң яратмас, таң тумас;
Моң, караңгы дөньяны
Ул соңра һич нурландырмас.
Күр дә якты, нурлы таңны,
Елмаеп, син бер кара.
Син сөйсәң, һәрчак сөй таңны —
Сиңа яктысын сибәр.
Җирдә син өзелеп сөйгәнне
Гарше әгъзамга сөйләр.
Йоклама син, таң сызылгач,
Ул көләч, ал таңны күр!
Хәсрәтең бетсен, җуелсын,
Якты көнгә урын түр!

«Кояш» газетасы, 1914 ел

ЭШЧЕ ҖАВАБЫ

I

Нәрсәгә тоз юк, дисеңме?
Шул сүзеңне куй әле.
Әй, авылдагы игенче,
Син илеңне күр әле.

Анда юл юк, вагоннар да
Ягылмыйча тик тора.
Һәм дә күп фабрик-заводлар
Эшләми туктап тора.

Анда җимерелгән, ватылган
Йорт белән тулган җиһан,
Монда кар-таулар өелгән,
Ташланып калган урам.

Син боларның зир-зәбәр
Килүен, эштән чыкканын,
Ул завод-фабрик, поездлар
Эшләвеннән туктавын

Әллә уйлыймсың Советтан,
Дип, туган, барсын моның?
Ул харап итте, дисеңме
Әллә шул ачлар илен?

Уйласаң, зур яңлышасың,
Бу уеңнан кайт, туган!
Һәммә җирне бәдбәхетләр
Таптаган, каннан юган.

Вәхшиләнгәннәр ләгыйньнәр,
Һич тә юкка көчләнеп.
Зир-зәбәр кылды алар
Илләрне, безгә үчләнеп.

II
Шул өзек юлларны ялгау
Һәм төзек итмәк өчен,
Туктаган барлык поездны
Гөрләтеп йөртмәк өчен,

Шул завод-фабрикларын —
Барсын да эшләтмәк өчен,
Бар күперләрне төзәтеп,
Илне чистартмак өчен,

Көч кирәк, күп көч кирәк,
Иптәш игенче, бел хәзер!
Илдә хезмәт яулары — без;
Синнән икмәк мөнтәзыйр!

Без ял итми эшлибез,
Төннәрдә йолдыз яндырып,
Төн буе керфек тә какмый,
Таңнарын нурландырып.

Син күрәмсең: бу бина лар,
Бу җиһазлар кемнеке?
Барысына аккан, түгелгән,
Бел, туган, эшче көче.

Син дә аңар зур көчеңне
Куш та, дускай, бел хәзер:
Без ясарбыз нурлы оҗмах
Ил өчен, ал-гөл хәзер.

Әй, игенче дус, онытма,
Илдә эшче әле дә бар,
Бир көчең аңар, туган, син,
Эшкә ябышып, алга бар!

ПАРОВОЗГА

(Демьян Бедныйдан)

Әй паровоз, нинди җыр белән
Юатыйм мин сине?
Белмисең, зарыгып көтә
Күптән сине ачлар иле.
Ташла шул гафләт йокың син,
Әйдә кычкыр, кит торып,
Тоз китер, икмәк китер,
Барысын китер, гайрәт орып!
Бул вагоннарга маяк син,
Кит алып, иптәш итеп,
Кычкырып таулар аша,
Таш-тауларын дер селкетеп!
Ватма, чү! Җитте! —
Вагоннарны,
Сиңа бу зур язык,
Инде азыклар китерсеннәр
Алар җирне казып!
Күр син илне, анда эшче,
Ярлы икмәк, тоз сорый,
Күр, завод-фабрик, пароход
Кычкырып нефте сорый.
Күр, балалар, карт-коры,

Эшче хатыннар кул суза.
Бар да күз теккән сиңа,
Тырышып алар ак юл сыза.
Күр, әнә данлы кызыл яу
Рәтли тырышып юлларың,
Көч белән берләштерә
Җирнең еракка илләрен.
Күр, агар суга салынган
Ул күперләр тип-тигез,
Юк комачау, юк манигъ;
Юлларда бар җир төз, тигез.
Әйдә, тор, кычкырт, паровоз,
Сакчылардан юл сорап!
Кит еракларга, югал урманга
Икмәкләр сорап!
Кит әнә син Көнчыгышка,
Анда тулган мал-туар,
Зур, биек тауларны үт тә
Илгә аннан мал чыгар!

ЯЗ МАТУР УЛ, ЭШ КӨТӘ...

I

Яз... Кояш балкып чыга,
Күр, Көнчыгыштан нурланып,
Бер сабый күк елмаеп,
Ап-ак томанга чолганып.
Нурларыннан тезмә-тезмә
Күктә юллар тезеләләр.
Күз яшедәй тамчылар,
Кар һәм дә бозлар өзеләләр.
Тауда каткан карт агачлар
Әкрен-әкрен селкенә,
Кыр, болын, урман, алан
Яшел чирәмгә өртелә.
Уһ, күңелле манзара!
Елга әнә чырлап ага,
Йөзләреннән нур тама.
Күз сал әнә бер кыйблага!
Ак болыттай тезмә аккошлар
Туган якка кайталар,
Күк-галәмне яңраталар,
Сазларын да тарталар.
Ташланып зур тау башыннан,
Гөрләвекләр гөр килә,
Якты, ямьле көн белән
Илләргә нурлы яз килә...

II

Әй, буранда юл адашып,
Рәнҗегән син, карт бабай,
Мич башыннан төш хәзер,
Тор, бик вакыт, ятма алай!
Тор, алашаң бик йөдәү түгелме?
Күбрәк онлап из,
Инде тиздән эшлибез, дип,
Эшкә өндәп, җырлап из!
Әй, озын төннәр төнәткән,
Җепләр эрләгән матур,
Бозлы тәрәзәдән карап,
Яшьләр күзләгән матур!
Чык чабып тышка, киләпләреңне
Кар суларында ю!
Җәйгә күлмәкләр әзерлә,
Карда чап һәм карда у!
Әй, сукачы, тор, уян тиз,
Шәп, төзекме ул сукаң?
Тиз әзерлә, эш көтә яз,
Эш көтә бу нурлы таң.
Чәчүче, орлык әзерме?
Тор да барысын куй җыеп,
Җир матурмы? Уңсын иген,
Куй тиз тиресне өеп.
Монда эшчеләр һаман да,
Армыйча, чүкечен суга,
Сезгә сабаннар әзерләп,
Эшләрен кичкә суза.

«Эшче» газетасы,
2 апрель, 1920 ел

Р.Якупов фотосы

ЯКТАШЛАРЫМА БӘЙРӘМ

ФӘНИС ЯРУЛЛИН

Якташларым, сезгә күчтәнәчкә
Өр-яңа бер шигырь җибәрәм.
Шигъри гөлләр үсеп чыга минем
Һәрвакытта туган җирләрдән.

Йөрәгемдә җылы кимеп китсә,
Каләмемнең кипсә карасы,
Туган якларыма кайтып төшәм,
Мин һаман да авыл баласы.

Якты йөзле дусларыма рәхмәт,
Сезнең җанда шәфкать, миһербан.
Сезнең белән кими кайгыларым,
Сезнең җанда эри минем җан.

Яшик шулай бер-беребезне зурлап,
Туган җирне зурлыйк иң элек.
Гомер — мизгел, гомер үтә-китә,
Яхшылыклар гына мәңгелек.

УЙГАНУ ВӘ ЯҢАЛЫК ТАРИХЫ

РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН

(Дәвамы. Башы беренче санда)

IV

Зур мәдрәсәләрнең дәрес тәрбияләре күбрәк ошбу рәвештә вә ошбу китаплардан булыр:

1 нче ел. «Бөдан», «Шәрхе Габдулла».
2 нче ел. «Кәвагыйд», «Гавамил».
3 нче ел. «Әнмүзәҗ».
4 нче ел. «Кафия», «Мулла Хаҗи», «Исагуҗи».
5 нче ел. /-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/
6 нчы ел. «Шәмсия», «Шәрхе Гакаид».
7 нче ел. /-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/
8 нче ел. «Сөлләм», «Тәһзиб», «Тәвзих».
9 нчы ел. /-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/
10 нчы ел. «Мулла Җәлал», «Һидая», «Хикмәтел-гайн».
11 нче ел. /-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/-/

Бу дәресләр ошбу китаплар, ошбу программа буенча укылыр, Русия мөселманнарының иң атаклы вә иң шөһрәтле мәдрәсәләрендә булыр иде. Болардан кала тагын бер нуг [төркем] зур мәдрәсәләр булып, аларда исә мантыйкъ, ысуле фикъһе, хикмәт дәресләре укылмас, ләкин алар урынында «Мохтәсар», «Шәрхе викая», «Гайнел-гыйлем», «Тарикә», «Ширгә» кебек китапларның бәгъзеләреннән [кайберләреннән] дәресләр булыр иде. Бу икенче нугтан түбән тагын бер нуг зур мәдрәсәләр булып, аларда исә нәхү [синтаксис] вә сарыф [морфология] гарәби китаплары вә гомумән әдәбият гарәбия фәне истигъмаль кылынмас [укылмас] иде.

Әгәр дә ошбу өченче нуг зур мәдрәсәне городской школа дип фарыз итсәк, икенче нугсы реальная гимназияләр, беренчесен университетлар дип фараз кылынмак лязим [тиеш] булыр. Ягъни, халык нәзарендә вә шәкертләр каршында бу өч нуг зур мәдрәсәләрнең аермалары ошбу нисбәт илә йөрер иде.

Монда зикер ителгән китаплардан «Бөдан» илә «Шәрхе Габдулла», балаларга тиеш дәрәҗәдә ашнә булмаган [аңлашылмаган] фарсы лисанында (телендә) язылдыкларыннан өстен, сарыф гыйлеменә мөнәсәбәтсез бәхәсләр илә чуалтылып укытылыр вә шуның өчен дә балалар аңламыйча укырлар иде. Әгәр дә мәмләкәтебездә гарәп нәхү вә сарыфын яхшы белүче адәмнәр булса, алар мәзкүр китаплардан дәрес алу сәбәбеннән бигрәк, соң вакытларында, хәлфәләрнең әйтүләре вә үз иҗтиһадлары [тырышлыклары] илә ашнә булмышлар. Гарәби сарыф вә нәхү дәресләрендә балаларга тәлкыйн ителә [аңлатыла] торган бәхәсләргә керешелсә, сүз озаер, укучыларның күбесе аңа тәхмил дә итә [төшенә] алмас, борынгы мәдрәсәләр хакында каннары кайнап ихтимал матлуб [тиеш] түгел сүзләр сөйләргә керешерләр. Шәкерт вакытыбызда Уфа шәһәренә барган идек. Шул вакыт Шәрәфеддин әфәнде Абыйзов безгә бер зур китап күрсәтеп, Казанда Күл буе мәдрәсәсендә олуг хәлфәләрдән Галиулла әт-Тәүкилди исемле кешенең әсәре идекен сөйләгән иде. Хәтер дәфтәремдә язылдыгына күрә, мәзкүр әсәр 1304 елда язылып [һиҗри ел хисабы белән] тәмам булган вә 1305 елда табгы [басылган] ителгән иде. Гарәп сарыфлары, нәхүләре нинди бәхәсләр илә укылдыгына мәзкүр [әлеге] әсәр үрнәк булса кирәк.

Ошбу ике китапның мөәллифләрен [язучыларын], кайсы мәмләкәт кешеләре идеген, заманнарын белә алмадык. Гарәп сарыфыннан бәхәс итү ноктасыннан «Бөдан» зарарсыз булса да, «Шәрхе Габдулла»сы чеп-чи ялгыш бер әсәрдер. Гарип адәмнәрне, читтән килүче мөсафирларны ялгыш юлларга төшереп җибәрмәк максудларыннан калуга сәбәп булмак гөнаһ булса, гарәп сарыфын үгрәнү касдында [максатында] булган мәгъсум [гөнаһсыз] балаларның адашуларына вә гая [ахыр] әмәлләреннән мәхрүм вә насыйбсыз калуларына сәбәп булган адәмнәрнең дә гөнаһ эшләгән вә вөҗдансызлык иткән булуларында шөбһә юк.

Мәмләкәтебездә Мортаза мөфти вә аның әсәрен укыттыклары хәлдә, Бохарадан кайтып та аларга кире төшеп, сарыфны фарсы телендә укытучы вә хосуса «Шәрхе Габдулла» китабын интихаб итүчеләр [сайлап алучылар] хакында «Ля-мәрхәбан биһим!» [аларга мәрхәбә булмасын] диелсә кирәктер.

***

Монда күрсәтелгән 11 нче ел дәресләр тәхмин [азак] булып, хакыйкать хәлдә, иске мәдрәсәләребезнең дәресләре вә гомерләре бервакыт илә мәхдүд булмас [чикләнмәс]. Гомере вафа итсә [җитсә] йөз ел укып ятса да, гаҗәп күрелмәс иде.

Монда саналган дәрес китаплары, өстән каралганда, бик күп күрелмәс, хәтта җөссә [китап] вә бит саннары игътибары илә реальный гимназияләрдә укылачак дәрес китапларының мәҗмугыннан [барыннан] күп артып китмәслек дәрәҗәдә булса да, асыл дәресләр ошбу китаплар исеменнән, аларның хашияләреннән [шәрехләүләреннән] вә хашияләренең хашияләреннән булыр иде. Әгәр дә асыл дәрес китаплары йөк ташучы кечкенә пароходларга охшатылса, хашияләр исә шул пароходлар артына тагылган зур-зур корабларга охшар.

Бу программада иң олуг ялгышлык — балаларның хәлләре мөсагыйд булып булмаячакларын [мөмкинлекләрен] тикшермәстән, һәрбер баланы шул юлга төшереп җибәрмәк ноктасында иде. Ун-унбиш ел укырга ният итеп торучылары да шул юлга керерләр. Өч ел укырга ният итүчеләр дә, аталары урынына мулла булырга хәзерләнүчеләр дә шул программага муафикъ [туры китереп] укырлар, аталары урынына сатучы вә игенче булучылары да!

Түбән мәктәпләрдән яхшылап бернәрсә аңламаган балалар, зур мәдрәсәләргә кереп, аның дүрт яки биш-алты еллык дәресләрен укып чыксыннар — шул шәкертләр диннәре вә дөньялары өчен нинди сәрмая [бәя] хасыйл итеп чыккан булачаклардыр?

Имам булыр өчен тамга җыючы шәкертләрдән форсатлары барлар хәдис вә фәраиз[1] укырлар вә ошбу мөнәсәбәт илә рәкым [сан], җәмегъ вә тәфрикъ [кушу-алу], зарып вә тәкъсим [тапкырлау-бүлү] белерләр иде. Ләкин бу дәресләр программада булмадыгыннан, күбесенчә укылмас вә шуның нәтиҗәсе буларак үгрәнмәсләр иде.

Муллаларның рәкемнәрне [саннарны] фәхеш [бозык] сурәттә ялгыш язуларын Оренбург Диния нәзарәтенә барып хезмәт итә башладыгымда белдем. Никах кылынучы кызның яше, мисал өчен, 17, егет яше 19 дип язылачак җирдә, рәкымнәрне 107 вә 109 рәвешендә язулары вә «мәһәр суммасы 150 сум» дию касды [теләге] илә «мәһәр суммасы 10050 сум» дип куюлары күп күрелде. Собраниенең 1893 ел 15 октябрь 3999 нчы номерда булган тәнзыймәтенең [канунының] 8 нче маддәсендә мәһәрләрне сыйфыр [цифр] илә язудан тыюның заһири [ачык] сәбәбе башка булса да, асыл сәбәбе бик күп муллаларның рәкым белмәдекләре вә ялгыш язулары сәбәбеннән, шәригать вә низам каршында хаҗәт булган метрикаларның куәттән төшүенә сәбәп булуларыннан сакланмак өчен иде. Казан губернасында мәшһүр

[1] Фәраиз — варисларга мирасның күпме тиюен билгели торган кагыйдәләр.

бер карьянең [авылның] метрикасында 9 рәкыме матрад [баш хәреф] сурәтендә «Р» рәвешендә язылганы һәмишә [һаман да] күзем уңгындадыр. Әгәр дә мондый хәл Оренбург губернасында, Сибириядә, Бөрҗан вә Исергәп эчләрендә булса иде, гаеп саналмас вә бик күп җәһәттән мәгъзүр [сәбәпле] күрелер иде. Ләкин метрика Казан губернасында һәм дә бер гасырдан артык вакытлар әтрафка [төбәккә] муллалар җитештереп торган зур мәдрәсәле авылдадыр.

Казан шәһәрендәге мәдрәсәләрдә шәкертләргә имля вә рәсме хат [матур язу] үгрәтүләр, ихтимал ки, булгандыр, ләкин авыллардагы мәдрәсәләрнең шәкертләре күбесенчә мондый эшләрдән мәхрүм булырлар, инша-фәлән белмәсләр иде. Авыл мәдрәсәләрендә бу тугрыда булган бөтен иҗтиһад, хәлфәләр тарафыннан шәкертләргә: «Ул — алдым бер дистә куян тиресе, хакы булды 30 тиен», янә, «алдым ике дистә төлке тиресе, хакы булды 3 сум», — кабиленнән язулар язып бирү, шәкертләр дә шуларны күчереп язудан гыйбарәт булыр иде. Ошбуның өчен, хәтта ачык максатларын аңлатырлык рәвештә хат яза белүдән дә насыйбсыз булырлар иде. Зур мәдрәсәләрнең берендә хәлфәлек итеп торучы бер затның шул өяздәге бер ахунга төркичә бер китап дибаҗәсеннән [кереш сүз] күчереп язган мәктүбе күрелде. Хәлфәләрнең күпләре зуррак бер адәмгә хат язарга булсалар, китап дибаҗәләреннән күчерергә вә өйдән өйгә: «Иптәш, хат башы биреп торчы!» — дип соранып йөрергә мәҗбүр булырлар иде. Мәркәзләргә ригаятьсезлекләрен [игътибарсызлыкларын], гарәби кәлимәләрнең мөһмәл [ноктасыз хәреф] вә мәгъҗәмәләренә [нокталы хәреф] игътибар кылмауларын, ذ хәрефе урынына ز , ث урынына س , ت урынына ط язуларын сөйләргә дә урын юк.

Тәфсир вә хәдис, әхлак вә сира [пәйгамбәребез тарихы], тарихе ислам вә фикъһе[2] фәннәреннән хәбәрсез вә яки бик аз хәбәрдар булган бу шәкертләр ифрат дәрәҗәдә мөтәкәббир [тәкәббер], һавалы, үзләренә хөсне занлы [яхшы уйда] булырлар, дөньядан да үзләреннән галим вә мөдәррисләреннән дә әгъләм [укымышлы] адәм булуына шикләнмәсләр. Шәригать тәклиф [таләп] иткән мәсьәләләр хакында сүз чыктыгында, үзләренең хәбәрсезлекләрен ноксанлык [кимчелек] дип беләчәк җирдә, бильгакес [киресенчә], алар шул мәсьәләләрне белүне вә шунлар илә шөгыльләнүне ваклык хисап кылалар, шуның өчен мәсьәләләрне нинди урыннан эзләргә идеген дә белмәсләр иде. Шушы шәкертләр үзләре түгел, бәлки мәгъруф [танылган] остазларының береннән: «Дуңгыз ите илә сату кылу дөресме?» — дип сорадыкларында «Шәрхе викая» китабының фиһристиннән [эчтәлегеннән] «китабе-әллахем» [итләр мәсьәләсенә кагылышлы бүлек] исемендә бер сүз башы эзләдеге вә андый бер китап тапмадыгыннан соң, «Китабе әз-

[2] Фикъһе — ислам хокукы.

зөбаех» не [корбан чалу мәсьәләсенә кагылышлы бүлекне] ачып, шуны карарга керештеге риваять кылыныр.

Болар бер тарафта торсын, «Бу заманда суфсаталар [хаталанып бәхәсләнүче] бармы, юкса монакыйраз булып беттеләрме?» — дип соралган сүзгә Бохараның олуг галимнәреннән вә безнең Мәрҗаниебез[3] илә Габделхәбир әл-Мөслими вә Борһан казыйга остазлыгы булган мөдәррисләреннән беренең: «Монакыйраз түгелләр, һәмишә [һаман да] барлар икән, моннан фәлән еллар кадәр генә мөкаддәм [элек] вакытта бересе Мәккәгә килеп хаҗ кылып киткән дип ишеттек!» — дип җавап бирүне вә моны да латифә [мәзәк] вә уен көлке тарызында [рәвешендә] түгел, бәлки җитди рәвештә сөйләнүен хикәят кылалар.

[3] Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) — дин галиме, тарихчы, мәгърифәтче. Казан шәһәренең беренче җамигъ мәчете имамы, 1867 елдан Казан шәһәре мөхтәсибе.

Адәм баласының белмәве, ялгышуы гаеп түгел, ләкин моның да бер чиге бар. Бохарада олуг мөдәррис булып торучының суфсатаның Мәккәгә килеп хаҗ кылып китүен хакыйкать сурәтендә сөйләве кирәк ялгыш вә кирәк хата булсын, гаептер.

«Шәрхе викая»дан «китабе-эллахем»не [итләр мәсьәләсенә кагылышлы бүлекне] эзләүче мөдәррис илә суфсатадан хаҗ кылдыручы мөдәррис җавабы иститрад [максаттан читтә] булу сөйләнсә дә, югарыда мәзкүр булган дәрес китапларының голум шәргыягә мөнәсәбәтләре бик аз вә моның өстенә дә мөһиммат [әһәмиятле] дөньяда милек хасил кылыр өчен аларның ярдәмнәре тимиячәге мәгълүмдер. Шуның өчен зур мәдрәсә шәкертләреннән күпләр михраб сахибләре [ияләре] булдыклары соң, үзләре белмәдекләреннән, белүчеләрдән сорарлык дәрәҗәдә гыйлемгә хөрмәтләре булмадыгыннан, галимнәр өчен лязим [тиеш] вә шарт булган тәрбияләрне мәдрәсәләрдә ала алмадыкларыннан, җөзаф [чамасыз] сөйләргә, белсәләр-белмәсәләр дә фәтвалар бирергә, Аллаһның дине хакында мөҗәррәд [саф] раи [Коръән һәм сөннәткә таянмаган фикерләү] илә тәгълим кылырга [өйрәтергә] мәҗбүр булырлар иде. Мәмләкәтебездә хакыйкый гыйлем тарала алмадыгының, ялгыш сүзләр үрчеп торуының бер сәбәбе дә ошбу нәрсәләр булды.

Хөласан [нәтиҗәдә]: иске зур мәдрәсәләребездә сарыф гарәби башландыгыннан соң унбер еллар түгел, хәтта егерме бер еллар торып та язу-сызу вә мөһиммат динияне яхшылап белми дөньяга чыгу зур гаеп саналмас иде. Авылларда приговорларга кәкре-бөкре тамгалар салучылар арасында иске мәдрәсәләрдә бер кач [ничә] еллар торып чыккан адәмнәрнең күплеге мәгълүм.

Көрәк кадәр зур сакаллы бер хәлфәнең икенче өйдәге шәрике [иптәше] янына кереп: «Иптәш! Тырыша торгач, деби-не чыгардым бит!» — дип шатлануы исемдәдер. (Унга кадәр җамигъ белдем димәк буладыр). «Әнмүзәҗ» укучы бер шәкертнең рәкымнәр язып утырганын күрдекләренә шул өйнең хәлфәләре (шул вакыттагы ислахка күрә зурлары), баланы

сәясәт мәйданына чакырып: «Син бит әле... малае. Сиңга рәкым үгрәнергә кайда? Безнең шикелле сакал чыксын, авыл мужиклары да сине үзләренә муллалыкка сайлап хәзрәттән сорарга килсеннәр. Менә шуннан соң рәкым-сифер язарга керешерсең!» — дип орыштыклары да хәтеремдә.

Иске зур мәдрәсәләрнең гаталәт [эшсезлек] вә баталәт [бозыклык] урыны булуы бездә генә түгел, бәлки бу эш бөтен ислам мәмләкәтендә шулай идеген шәех Җамаледдин Әфгани[4] хәзрәтләреннән белдем. Бу көн Төркиядә мәшһүр шагыйрьләрдән булган Габделхак Хәмид[5] әфәнде дә бу тугрыда ошбу шигырьне сөйли:

«Халык аңа җаһил кереп, җаһил чыгар,
Сән кеби мәҗһүл [белемсез] вә мөстиһҗәл [әдәпсез] чыгар.
Кырык сәнә әйләр дә тәхсил кәлям
[Кырык ел Коръән гыйлемен өйрәнсә дә],
Язмай белмәс гарәпчә бер сәлям!»

Оренбург Диния нәзарәтендә имтихан кылынырга баручы шәкертләрнең үзләрен тәгъриф итеп [теркәп] язар өчен махсус бер дәфтәр бар. Безнең заманыбызда моның өченче җилде [томы] тәмам булып, дүртенчесе башланган иде. Габделвахид мөфти[6] заманыннан (1840 еллардан) ошбу дәфтәр дәвам итмәктәдер. Монда гүзәл вә рәсем хатлары [язмалары] дөрес язулар юк түгел. Әмма кәсри [күбесе] гаҗәиб рәвештә бозык вә шәкелсез нәрсәләрдер. Хәлбуки [шулай булгач], бу язуларның эчтәлеге бик мәгълүм булып, күбесе шәкертләрнең үз исеме вә фамилиясе, волость вә авыл, укыган мәдрәсәсе вә мөдәррисенең исемнәреннән гыйбарәт буладыр. Заманнарында милләтнең иң югары сыйныфы саналган бу халыкларның язулары шушы рәвештә булгач, түбән сыйныфларына бер сүз әйтергә дә урын юк.

Бу җирдәге хөкемнәр, фәрдләр [аерым затлар] вә шәхесләргә түгел, бәлки мәдрәсәләр вә тәгаллим (укыту) ысулына гына гаидтер [кайтып каладыр]. Әүвәлге тәртипсез мәдрәсәләрдән яхшы галимнәр вә бәгъзе бер олуг затларның заһир булуына [барлыкка килүләренә] вә соңгы низамлы мәктәпләрдә дә бозык вә начар кешеләр җитешүенә монда сөйләнгән сүзләрнең хилафлыгы юк. Бу ике матдә тугрысындагы асыл сәбәпләр мәдрәсә вә ысул тәгаллимнән зиядә [күбрәк], башка нәрсәләрнең тәэсирләре булырга мөмкин. Безнең монда зикер кылган [искә алган] фәннәребез вә китапларыбыз арасында да, Бохарадагы дәрес программаларына күрә дә Курсавилар[7], Мәрҗаниләр җитештерерлек нәрсәләр күренми. Арабызда Мәрҗаниләр, Курсавилар җитешкән булсалар, аның сәбәбе монда мәзкүр булган китаплардан башка китаплар вә безләргә

[4] Җамаледдин Әфгани (1838-1897) — үзенең идеяләре белән панисламизмга нигез салучы күренекле мөселман дин һәм сәясәт эшлеклесе, реформатор. Чит ил колонизаторларының көчләүләренә каршы чыгуы, деспотизмны кискен тәнкыйтьләве белән танылган шәхес.

[5] Габделхак Хәмид (1852-1937) — төрек язучысы һәм шагыйре. Парижда гыйлем ала. Төрек әдәбиятында романтизмны нигезләүче шәхес.

[6] Габделвахид бине Сөләйман бине Сөгълүк бине Габделхаликъ әл Җәбәли әл-Әрбәшчи — Петербург каласы имамы, 1840-1863 елларда Диния нәзарәте мөфтие.

[7] Габделнасыйр Курсави (1776-1812) — Казан өязендә Югары Курса авылы имам-хатибы, мәгърифәтче, дин галиме, реформатор.

мәгълүм булмаган кешеләр вә газиз китапханәләр, Аллаһы Тәгаләнең һибәсе [бүләге] булган иҗтиһадлар, гадәт тышындагы кабәлият [камиллек] вә истигъдатлар [сәләтлек], мохит вә рәфикъләр [иптәшләре] булырга мөмкин. Габделхәбир, Хөсәен Фәезхановларның[8] Габделхәбир вә Хөсәен булуларына Мәрҗани сәбәп булса, Мәрҗанинең Мәрҗани булуына Хөсәеннәр, Габделхәбирләр сәбәп булуында да безнең шөбһәбез юк. Имам Шафигый хәзрәтләренең Ләес бине Сәгыйдь хакында: «Олуг галим булачак адәм иде, фәкать үзен иптәшләре заигъ кылды [бетерде]», — дип тәәссеф кылуларының [үкенүенең] сәбәбе ошбудыр.

[8] Хөсәен Фәезханов (1828-1866) — Ш.Мәрҗанинең шәкерте, тарихчы, филолог, педагог. Санкт-Петербург университеты мөгаллиме.

Иске мәдрәсәләребездә укулардан вә шәкертләрнең дә: «Бу дөньяларның оҗмахы — мәдрәсәләрнең почмагы!» — дип мәдрәсәләрнең почмакларында, мичләренең артларында озын гомерләр ятуларыннан асыл максад нинди нәрсә иде?

(Шура, 1913. — № 18. — Б.559-561)

V

Иске мәдрәсәләребездә булган укулардан вә озын гомерләр сарыф кылып мәдрәсәләрдә ятулардан максад берәр мәхәлләгә мулла булмак иде. Муллалык вазифасы, мәдрәсәләрдә ятучы шәкертләрнең зур хыяллары булып, һәрбере ошбу максадка ирешмәк нияте илә, укыса-укымаса, аңласа-аңламаса, мөдәррисендә икътидар [сәләтле] булса-булмаса, укыган вә укый торган нәрсәләре эшкә яраса-ярамаса мәдрәсәдә ята бирер, карт муллаларның дөнья куюларын вә яки указлары алынуны дүрт күз берлә көтеп торырлар иде. Соңгырак, заман байлары арасында, үз кызларын остазбикә итү касды [нияте] илә авылның бер очына мәсҗед салып, мәхәллә аеру гадәте чыктыгында, шәкертләр өчен Америка ачылу кадәр бер яңа эш булган иде.

Хөлясан [нәтиҗә]: иске мәдрәсә шәкертләре мулла булудан башка да яхшы эшләргә мөмкин икәнлегенә гакыл ирештермәсләр вә ошбу сәбәптән дә имам булуны дөньядан хәерле бер муаффәкыять [уңыш] игътикад итәрләр [дип инанырлар] иде. Ошбу игътикадның әсәре хәтта бу көннәрдә дә бетеп җитмәде. Сәнәви [еллык] өч-дүрт йөз варидәтләре [керемнәре] булган хөкүмәт вә земство учительләре эченнән әүвәлге вазифаларын ташлап, фәкыйрь генә мәхәлләгә мулла булучылар күрелде. Инде башкача тәэмин истикъбаль кылырга [киләчәген тәэмин итәргә] муафикъ [яраклы] була алмаган шәкертләр хакында сүз сөйләргә урын да юк.

Укыдыгыбыз бер мәдрәсәдә М… исемендә бер шәкерт бушап кала торган җомга кичәсендә, сандыкларны өеп, мөнбәр рәвешендә урын ясар, кара кытат хөлләсе[9] өстендә вә чалмасы да башында булганы хәлдә мөнбәр өстенә менәр, суфи хәлфәнең таягын кулына тотып (үзен бер авыл мәчетенең мөнбәрендә фарыз итә), хөтбә укыр һәм халыкларга вәгазь сөйләр, моның соңгында да: «Әй, Алла! Мулла булып бер генә ел булса да мужикларны үземә каратып торып, мөнбәрдә ошбу рәвештә хөтбә укысам вә җомгадан чыгуыма: «Хәзрәт, әйдә ашка алырга килдем», — дип түренә ястык салынган чана илә көтеп торсалар, дөньядагы бөтен максатым хасил булган булыр иде», — дип ихлас күңел илә сөйләр иде. (Мулла булдыгыннан соң ике-өч елдан артык тормый вафат булды).

Шәкертләр йоклар өчен яттыкларыннан соң, мәдрәсәнең олуг хәлфәләренең берсе булган суфи мич артындагы урыныннан чыгып, шәкертләргә йөзен юнәлдергән хәлдә: «Әй шәкертләр! Ата вә аналарыгыз сезне укып яталар дип белә торганнардыр, ләкин сез укымыйсыз, бары икмәк черетеп кенә ятасыз, монда ятуыгыздан бөтен максатыгыз мулла булудыр. Һәрберегез бер мәхәллә көтәсез, ләкин бу булачак эш түгел. Бу көндә безнең мәдрәсәбездә биш йөздән артык шәкерт бар, Тымытык илә Бәйрәкәнең һәрберендә дә шулай бардыр, Тайсуганда да дүрт йөздән ким булмас. Инде үзегез хисап кылып карагыз: шул кадәр кешегә ничек итеп муллалык урыны табылып җитсен! Шуның өчен сезнең бик азыгыз гына, мең мәшәкать илә генә мулла булыр, әмма калганнарыгыз ни эшләр? Аны да әйтим: калганнарыгыз аталарыгыз урынына мужик булырсыз. Укыган кеше мужик булса, инде ул бер бәла була. Шуның өчен аталарыгыз урынына мужик булганнарыгыз куштанлык кылып, дөнья корытып йөрерсез, старста вә старшина булып ришвәт ашарсыз, фәкыйрьләргә золым кылырсыз, бик күбегез ат карагы булыр вә бик күбегез Себергә сөрелер, суфи абыегызның сүзләре дөрес булганлыгын сез шул вакытта гына белерсез!» — дип кычкырып көләдер вә бөтен мәдрәсә халкын көлдерер иде.

Моңа каршы бәгъзеләре (хәтта үзенең шәкертләре дә) яткан җирләреннән: «Суфи абзый! Аллаһы Тәгалә рәхмәт кылып, карт муллаларга үләт җибәрер әле», — вә бәгъзеләре: «Суфи абзый! Бер кәсеп кирәк бит! Мулла булмагач, ат карагы булмый, ни эшләрсең?» — дип җавап кайтаралар иде.

Суфиның ошбу сүзләре саф шәкертләр мәгыйшәтеннән [тормыш-көнкүреш] вә мәдрәсәләр дөньясыннан алынып сөйләнгән бер хакыйкать булса да, мәдрәсә шәкертләре моны саф хыялый көлкегә санарлар вә бер мәзәккә хисап кылырлар, вә үзләрен һәмишә дә [һаман да] бер мәсҗед михрабында имамлык урынында күрерләр иде. Моссадак[10] һәр җирдә вә һәркөн тәкрар [кабат-кабат] булып торган ошбу хәлне суфи үзе дә мөҗәррәд

[9] Хөлләсе — мамык тукымадан тегелгән өс киеме.

[10] Моссадак — расланган, дөрескә чыккан мәгънәсендә.

[бары тик] шәкертләрнең күңелләрен күтәрер, хәтерләрен ачар өчен генә сөйләр иде. Хакыйкать хәлдә [чынлыкта] шулкадәр күп шәкертләрнең һәрберенә дә муллалык урыны җитешмәс, йөз дә туксаны суфи хәбәренә моссадак булып калыр вә шушы кешеләр ошбу табигый хәлне тәкъдиргә вә остазларының фатихасы булмавына хәмел кылырлар [сылтарлар], гомер буйлары янып, көеп, саргаеп йөрерләр иде.

Иске мәдрәсә шәкертләренең барлык хыяллары муллалык булса, бөтен мәсләкләре моназарәлектән [сүз көрәштерүдән] гыйбарәт булыр вә бөтен сәгадәтне [бәхетне] моназарәгә икътадарда [сәләтлелектә] дип белерләр иде. Фәкать бу моназарәләре «Тиҗарәт әл-ахмак мага әһле бейттһи» [ахмакның үз әһле белән сәүдә итүе] кабиленнән үз араларында эшкә яраса да (ярый саналса да), читләр берлән эш кылырга ярамыйдыр иде. Моназарәдә мисалсызлык илә исем чыгарган хәлфәләрнең читләр илә яхшы моназарә кыла алулары вә читләр тарафыннан ислам сурәтенә язылган рисаләләргә җавап бирүләре мәгълүм булмады. Хәлбуки [шулай булгач], үзләре: «Бу моназарә ни өчен кирәк? Моның файдасы нинди нәрсәләрдән гыйбарәт?» — дип сораучыларга: «Динебезгә шик салучыларга җавап бирер вә исламны мөдафәга кылыр [саклар] өчен кирәк», — дип сөйлиләр иде.

Иске мәдрәсәләрдә иң олуг кимчелек әхлак мәсьәләсе иде. Әхлак үз күзлегеннән каралмый вә шуның өчен бик күп бозык әхлаклар [гадәтләр], шул вакытларда мәдрәсәләр каравына күрә, әхлаксызлык саналмыйдыр иде. Моннан башка әхлаксыз шәкертләр даими чыгарылып тормадыкларыннан, шулар мәдрәсәләрдә күбәеп хуҗалык кылырлар, бөтен көтүне корчаңгы итүче корчаңгы хайваннар кабиленнән [кебек] мәдрәсә әһелләрен бозарлар иде. Шуның илә бәрабәр иске мәдрәсәләрнең даими сагынырлык бер хәлләре бар иде ки, бу хәл бәгъзе бер шәкертләрнең «иҗтиһадлы» булуларыдыр. Боларда булган тырышлык каләм илә тәгъриф ителмәслек [аңлатылмаслык] дәрәҗәдә булыр иде.

VI

1874 елда гамәлгә куелган гаскәрилек законы буенча, башкорт вә типтәр халыклары хезмәткә алынырга башладылар. Сибириядә булган бәгъзе [кайбер] таифәләр [кабиләләр], кыргыз вә казахлар, Кавказ халыклары, төрекмән вә үзбәкләр истисна ителдегеннән соң, ошбу яңа низам [канун] хөкеменә күрә, гомумән, Русия ис-

ламнары руслар илә бәрабәр вә берлектә гаскәрилек хезмәте кылырга тиешле булдылар.

Мәдрәсәләребездә шәкертләребезнең ләззәт алып укырга, аңлылары аңсызларыннан аерылып, халык арасында исем чыгарырга башлаган вакытлары 20-25 яшьләр булыр иде.

Ошбу гомуми гаскәрилекнең әхвәл иҗтимагыябезгә нисбәт илә беренче тәэсире мәдрәсәләребездә күрелде. Файдасы булып-булмавыннан, үзләренең истикъбальләре [киләчәкләре] хакында берәр төрле сәмәрәсе [нәтиҗәсе] күрелеп-күрелмәвеннән катгый назир ителдеге [боерылдыгы] хәлдә, дәресләрен мәхәббәт илә укырга башлаячак егетләрнең күпләре гаскәрилек хезмәте итү илә мөкәллиф [дучар] булдылар вә берьюлы ике көймә койрыгын тоту мөмкин булмадыгыннан зарури, укуларын дәвам иттерә алмаслар иде.

Моннан башка агалары яки энеләре йорт хезмәтләрен кылып тордыклары сәбәбеннән, мәдрәсәләрдә ятарга, яхшы укымасалар да, шәкерт исемен күтәреп торырга муаффәкъ булган [ирешә алган] шәкертләр, ошбу ага вә энеләре гаскәрилек кылыр өчен китүләре сәбәпле, алар урынына кайтып, йорт хезмәтләрен кылырга мәҗбүр булырлар вә мәдрәсәләргә йөрмәктән туктарлар иде.

Ошбу вакыйганың тәэсире хәтта кыз балаларның укуларында да күрелмештер. Мисал: кияүгә киткәнгә кадәр муллаларның йортларына йөреп сабак укучы вә кечек балаларны укытучы кызлар, ир туганнары солдатка китә башладыкларында сабакка йөрүләрен дәвам иттерә алмас булдылар, берәм-берәм тукталдылар. Боларга ияреп йөрүче яшь сеңелләре дә, иптәш юклыгыннан вә яки башка бер сәбәптән йөри алмас булдылар вә күпләре укытучылар җитешмәдегендә сабакка йөрмәскә башладылар.

1874 елдан мөкаддәм [элек] мәдрәсәләребезнең ни рәвештә вә дәресләрдә ни юлда булганлыгын белүчеләр бу көндә дә күптер. Әгәр дә шул адәмнәр ошбу тугрыда, тәфсил илә язып, матбугатта гарыз итсәләр [бастырсалар], файдасыз булмас иде. Чөнки 1874 елдан соңгы үзгәрешләр илә кыяс кылып [чагыштырып] карар өчен мәдрәсәләребезнең шул вакыттагы хәлләрен белергә ихтыяҗ зурдыр. 1874 сәнә мәдрәсәләребезнең иске хәлләре илә яңа хәлләре арасында аермалар игътибар кылынырга тиешле.

Һәрхәлдә яшьләр, сакаллары билләренә җиткән карт хәлфәләрнең кычыткан арасында хыялны хифыз кылып [ятлап] ятучы моназар [бәхәсче] вә пишкадәмнәренең артларыннан җитешеп тә урыннарын тутырып тормадыклары сәбәбеннән, 1874 сәнәдән хәлфәләр, пишкадәмнәр аз булырга башладылар. Соңгырак вакытларда бик күп мәдрәсәләрнең шәкертләре хәтта тәмам монакыйраз булдылар [беттеләр].

[11] күпнокталар авторныкы.

[12] шулай ук.

Укыдыгыбыз без бер мәдрәсәдә … …[11] исемендә бер хәлфә һәрвакыт безгә: «16 яшендә угылым бар», — дип сөйлидер иде, … …[12] исемендә икенче бер хәлфә дә, сарыф укырга башлаган угылын алып килеп, үзенең урынына урнаштырдыгыннан соң, үзе мәдрәсәдән чыгып китте. Әгәр дә угылы илә бергә казандаш булып торсалар, хәтта беркадәр сәнәләрне бәрабәр кичерсәләр дә, тәгаҗҗеб итүче [гаҗәпләнүче] булмаячак иде. Чөнки бу вакытларда мондый эшләр гадәти вакыйгалардан булып, мисаллары күп булыр иде.

1879-1880 еллар иде, әүвәлге наборларда алынган яңа гаскәриләребез йортларына кайта башладылар. Иске вакытлардагы егерме-утыз еллар кадәр хезмәтләренә хәзерге хакыйки хезмәтләре бары тик 4-5 сәнәләргә генә калган иде. Болар тимер юл вә пароходларның юлларын бик кыскартып, шәһәрләрне бер-беренә күрше ясадыклары сәбәбеннән, күп мәмләкәтләр йөреп, дөнья күреп килдекләреннән, әүвәлге хәлләренә күрә [караганда] хыялы ачылган вә күбесе дә икмәк вә тозлык булса да русча да үгрәнгән булырлар иде. Беркадәр җитдилек вә әхвәл рухияләрдән хәбәрдар булуларыннанмы вә яки башка сәбәпләрдәнме болар борынгы солдатлар кабиленнән: «Кояш чыккан җирдә хезмәт иттек, кояшны күсәкләр илә каерып чыгарадыр идек, тулган айны ваклап йолдыз ясыйдыр вә йолдызларны падишаһның тавыкларына ашатадыр идек, Петербург шәһәренең бер читеннән икенче читенә ике ай чыктык», — димәк кеби хорафатлар сөйләмәсләр, бәлки күбесенчә, үзләренең хезмәтләренә, шәһәр вә сәфәр хәлләренә мөнәсәбәтле шәйләрне хикәят кылырлар иде.

Ошбу хикмәт өчен булса кирәк, Нигъмәтулла хаҗи[13] мәрхүм үз кабиләләре булган бохаралылардан гаскәргә алынмавы өчен тәссеф кылыр [үкенер] вә бу хәлне үз кабиләсенең юаш вә куркак булуына һәм дә рәзаләт [түбәнлектә] вә сәфаләттә [хурлыкта] көн күрүләренә сәбәп итеп күрсәтер иде.

Югарыда сөйләдегебезчә, гаскәриләр хыялы ачылып кайтырлар иде, фәкать моның илә бәрабәр мәдрәсәләрдә торган вә шәкертлек дәверен үткәргән егетләребез үз-үзләрен тота белерлек икътидар [сәләт] вә тәрбиядән мәхрүм үсүләре сәбәбеннән, хыялы бозыклыкларга да өлфәт итеп [аралашып] сүэ [бозык] халык илә мөбтәляләнеп [бәхетсезлеккә эләгеп] килүләре дә инкарь ителмәс иде.

Шулай итеп, Русия мөселманнарының иҗтимагый җәһәттән булган инкыйлабларының беренче һәм дә иң куәтле дәверләре гаскәрилек низамы сәбәбеннән булган инкыйлаб иде. Ләкин бу вакытта үзләрендә булган инкыйлаб вә тәбәдделләрне [алышынуны] сизәрлек аң, хадисәләрнең [вакыйгаларның] сәбәпләрен вә нәтиҗәләрен тикшереп чыгарырлык икътидар [сәләт], мәгыйшәтләрне зарарсыз әсасләргә [нигезләргә] бинаән

[13] Нигъмәтулла бине Карымшмак бине Сәед бине Касыйм бине Шәриф бине Әшрәф бине Шәбабеддин (1829-1901) — Төмән өязендә күренекле дин эшлеклесе, сәүдәгәр, хәйрияче. Р.Фәхретдиннең бу шәхескә багышланган мәкаләсендә Нигъмәтулла хаҗиның бохаралыларның солдатка алынмавына үкенүен һәм: «Халкыбыз яшьтән үк куркак булып үсәләр, бер дә кеше күрә алмадыкларыннан, вәхши табигатьле булалар, һичнәрсә белмиләр, ни сөйләүче булса, шуңа ышаналар, хәтта иң зәбун [куәтсез] халыклар да үзләрен һәртөрле юллар илә алдый алалар. Фикерләре ачылмый, зиһеннәре эшли алмый, бернәрсәгә дә йөрәкләре җитми. Әгәр дә Харьков илә Полтава, Тифлис [Тбилиси] илә Варшаваны күреп кайтсалар, аякларын кайдан алып кая куярга икәнлеген үгрәнеп килсәләр, дөньяның бик күп төрле хәлләре бар идеген белсәләр, бәлки бик күп файда булыр иде», — дип әйтүе турында яза. Кара: Р.Фәхретдин. Нигъмәтулла хаҗи // Шура. — 1913. — № 18. — Б.545-548.

итәрлек (төзерлек) куәт вә мәгърифәт булмадыгыннан, Русия мөселманнары моны белмәделәр, тарихлары язылачак дәфтәрләргә ошбу хәлләрне теркәмәделәр. Әгәр дә Мәрҗани хәзрәтләре илә «Мөстәфадел-әхбар» истисна кылынса [искәрмә булса], бу вакытта мөәррихләре дә [тарихчылары] тарихлары да, язылачак дәфтәрләре дә юк иде.

(Шура, 1913. — № 23. — Б.722-724)

VII

1888 елның июль аенда игълан ителмеш фәрманга күрә, 1891 сәнә башыннан Оренбург Диния нәзарәтендә әгъза булачак кешеләр өчен гимназиянең әүвәлге дүрт классլы программасыннан яки уездный вә яхуд городской һәм учительский школа мәктәпләренең программаларыннан имтихан бирмәкләре, шәһәрләрдә ахун вә хатиб урыннарына керүчеләр өчен русча укып-язарга, карьяләрдә имам булучылар өчен бераз русча сөйләшә һәм дә укырга белергә шарт кылынды.

Ошбу низам сурәте мөгътәбәр «Тәрҗеман» газетасында нәшер кылыну илә[14] мәдрәсә шәкертләре русчадан хәбәрсез кешеләрнең имамлык урыннарына керер өчен хаклары бетүен аңладылар вә һичкем сүзенә карамый, үз истикъбальләре [киләчәкләре] өчен кайгырырга, шәһәрләргә вә рус авылларына китеп русча укырга башладылар.

Бу җирне укучыларның күңелләренә: «Шул вакыттагы милләт рөкенләре [терәкләре] әгәр дә бу тугрыда ысул илә хәрәкәт иткән вә табигый булган юлны ихтыяр кылган булсалар иде, һәр олуг мәдрәсә хозурына русча укыр өчен махсус школлар ачып яки башка дәресләр арасына кертеп, русча дәресләр дә укыттырган булырлар, вә моның өчен шул вакыттагы падишаһлык хәзинәсеннән вә земстволардан лязим [тиешле] дәрәҗәдә матди вә мәгънәви ярдәм күргән булырлар иде», — эчтәлегендә бер бәхәс киләчәгендә шөбһә юк.

Хакыйкать хәлдә, шул вакыттагы мөселманнар русча укыр өчен никадәр акча сорасалар да, хәзинә вә земстволар мөмкин кадәр шуны бирерләр иде. Дәресләр аз гына ысулга куелу сәбәбеннән, имамнар, ахун вә казыйларга шарт ителгән кадәр русчаны мәдрәсәләребездә укыту бик мөмкин булыр иде. Хәлбуки, ул вакыттагы мәдрәсәләребезнең дәресләре шулкадәр низамсыз [тәртипсез] вә шулкадәр бер бад [бозык] иде ки, дәресләр ни өчен кирәк вә файдалары кайсы вакытта күреләчәк — моны шәкертләр түгел, мөдәррисләр үзләре дә мәхкәмә итеп [тикшереп] карамаслар иде.

Шулай булгач, милләт рөкеннәре [терәкләре], аңлы сыйныфлар бу тугрыда ни өчен мөсаһәлә [йомшаклык] кылдылар

[14] Император фәрманы Дахилия нәзарәте [Эчке эшләр министрлыгы] тарафыннан Оренбург Диния нәзарәтенә 1888 ел, 7 сентябрьдә 4777 рәкымле [номерлы] кәгазь илә тәблигъ ителмеш [ирештерелгән] вә аның тарафыннан ташбасма илә табгы булынып бәгъзе җирләргә таратылмыш исә дә, Собраниенең бу эше ялгыз формальностьны ригаять кылу [кайгырту] өчен генә булдыгыннан, бик аз кешеләргә генә җибәрелмештер. Гомум әһали [халык] моны ачык «Тәрҗеман» газетасы аркылы аңладылар. — Р.Ф.

вә ни өчен шул дини мәдрәсәләрдә бераз русча укыту юлын ихтыяр кылмадылар?

Тарихыбызны язучылар, ошбу сөальнең җавабын бирүдә ялгышмасыннар өчен, бу җирдә түбәндәге сүзне сөйләргә мәҗбүрбез.

Шул вакыттагы халыклар ысул илә хәрәкәт итә алмадылар вә русча укуга каршы килделәр. Гавам [гади халык] вә шул җөмләдән муллалар вә мөдәррисләрнең күбесе русча белмәдеге тәкъдирдә дә милләтнең рәфаһ хәл [муллык] илә яшәвенә ышандылар. Русча укып та саф мөселман булу мөмкинлеген тасвир итә алмадылар. Шул замандагы мөселманнар указлы муллалар хакында иң галим вә иң гакыллы, һәм дә иң тәдбирле [эшнең ахырын уйлап эшләүче] кешеләр дип белерләр, тасрих кылып [аңлатып] әйтмәсәләр дә, зымный [ачык булмаган] сурәттә аларның ля юхтый [хаталанмый торган] икәнлекләре берлә игътикад кылырлар [инанырлар], үзләрендә гакыл, фикер вә истикъляль [бәйсезлек] кеби көчләр һәм дә яхшы илә яманны, файда илә зарарны, бозык илә төзекне аера белерлек мизан [үлчәү] барлыгын игътибарга алмаслар иде. Шул сәбәпле хөр фикер вә иҗтиһадка мәбни [төзелгән] вә хөр фикерсезлек вә җөзафка [чамасыз сөйләүгә] мәбни булсын указлы муллаларның сүзләрен мөхаз [бары тик] савап вә халис [саф] хикмәт белеп, куй көтүләре кабиленнән [мисалында] аларның сүзләре артыннан авышып йөрерләр иде. Бөгелмә өязе Сөләй вакыйгалары ошбу хәлләрнең меңнән бер мисалы булырга ярар. Указлы муллалар (бәгъзе бер гакыллылары мөстасни [искәрмә]) имамлык мәнсабе [вазифасы] өчен русча белүне шарт кылырга күнмәделәр вә: моны да мәгъкуль [аңлаешлы] сәбәпләргә бинаәнкылачак [нигезләячәк] җирдә, һәрвакыттагы гадәтләренә муафикъ [туры китереп], дин исеменнән инкяр иттеләр вә «Русча белгән адәмнәрнең шивәләре бозылып Коръәнне дөрес укырга кодрәтләре калмый», — димәк кеби вөҗүһләр [сәбәпләр] бәян иттеләр. (Моңа күрә, Муса әфәнде Җарулла[15], Бәйрәкәдә мөдәррис Мәсгуд әфәнде, Уфада ахун Җиһангир әфәнде кеби адәмнәрнең Коръәнне дөрес укый алмаулары лязим киләдер).

Гомумгә гаид [караган] эшләрдә бөтен хәрәкәтләре вә бөтен сәгый [тырышлык] вә иҗтиһадлары: «Хәзрәтләр ни әйтерләр?..» — дип торучы вә үзләрен кабер ташлары мисалында шөгурсез [аңсыз] вә хиссез танымакта булган гавам [гади халык], хәзрәтләренең сүзләрен шул хәленчә кабул итеп: «Русча белүче адәмнәрнең кыйраәтләре [укулары] дөрес булмый, шуның өчен андый кешеләрнең имам булуларына безләр риза түгел!..» — дип тәкрарлап [кабатлап] тордылар.

Дахили вәзиргә [Эчке эшләр министрына] бирелгән хисап-

[15] Бигиев Муса Ярулла улы (1875-1949) — дин галиме, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, публицист. Петроград, Мәскәү мәчетләре имамы. Бу шәхеснең Коръәннең татар телендә тәфсирен эшләве мәгълүм.

сыз гариза вә илтимаснамәләр [үтенечләр] безнең бу җирдә сөйләгән сүзләребезнең дөреслегенә дәлил булырга яраса кирәк. Шушындый илтимаснамәләрнең [гаризаларның] бер кыйсеме [өлеше] Оренбург Диния нәзарәте архивында да сакланадыр.

Гавам вә күбрәк меллалар вә мөдәррисләрнең русча укуга бу кадәр каршы килүләренә мәгъкуль [аңлаешлы] бер сәбәп тә бар иде. Бу исә шул гасырда Победоносцев[16] вә Ильминский[17] кеби адәмнәрнең тусияләренә муафикъ [сәясәтләренә туры китереп] руслаштыруны мәсләк итүдән гыйбарәт иде. Мәзкүр [әлеге] затларның фикерләренә тикълид итүче [иярүче] маэмүрләр [түрәләр] русча укыту сәбәпле, мөселманнарны руслаштыру җиңел булачагын хыял кылырлар иде. Бу адәмнәрнең ошбу хыяллары хөкүмәт адәмнәре өчен дә хәерле булмады, мөселманнар өчен дә!

Чөнки бу эшләрнең нәтиҗәләре мөселманнарның, мәдәният дөньясыннан ерак булып, гыйлемсез, һөнәрсез калуларыннан гыйбарәт булды. Мөселманнар шул замандагы хөкүмәткә шөбһә илә карарга, хәтта яхшы эшләр тугрысында да: «Монда берәр төрле хәйлә вә мәкер булмасын», — дип куркырга башладылар. Бик күп гаиләләр һиҗрәт иттеләр [күченделәр], анда-монда торып шәзер-мәзер булып [таркалып] беттеләр. Табигый, бу хәлләр хөкүмәтнең үзе өчен дә файдалы булмагандыр.

Милләт рөкеннәре [зыялылары] вә хосуса русча укыган мәгълүматлы затлар, Победоносцев илә Ильминский фикерләрен дәстүрелгамәл [канун] тотылдыгын белдекләреннән, русча уку хакында әһалине [халыкны] димләмәделәр. Димләгән булсалар да, сүзләре кабул булмас, бәлки үзләре Ильминский фикеренә хезмәт кылу илә гаепләнгән булган булырлар иде.

Мөселманнарның руслаштыру сәясәтеннән имин булулары вә шуның сәбәбеннән дә үз ихтыярлары илә русча укырга керешүләре 1905 ел 17 октябрь Манифесты игълан кылынганнан соң гына булды.

***

Югарыда сөйләп килдегебезчә, гомумхалык: «Русча уку илә тәклиф кылынмасак [көчләнмәсәк] иде, муллалык мәнсабе [вазифасы] өчен указ бирелергә русча белү шарт булмаса иде!» — дип таләп иттекләрендә, карьялардәге укучы шәкертләр, читләргә китеп, русча укып йөрергә башладылар.

Шушы рәвештә русча укып йөрүләрдән мөселманнар зарар күрделәрме? Юкса файда күрделәрме? Моның җавабы киләчәктә язылыр.

(Шура, № 1914. — № 3. — Б.80-81)

Басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

[16] Константин Петрович Победоносцев (1827-1907) — дәүләт эшлеклесе. Россия дәүләтенең нигезен чиркәү һәм диндә күрә.

[17] Николай Иванович Ильминский (1822-1891) — миссионер. 1860 елларда аның тарафыннан Урта Идел буендагы рус булмаган халыкларны чукындыру эшчәнлеген камилләштерү максатыннан, белем бирүне христианлаштыру белән бәйләү, гыйбадәтнамәләрне, дини китапларны милли телләргә тәрҗемә итү һәм тарату, чукындырылганнарга рус телен өйрәтү кебек алымнар тәкъдим ителә һәм гамәлгә куела.

БАТЫР ТӘКӘ

ШАМИЛ МАННАПОВ

Сабан туе. Мәйданда
Бил алыша батырлар.
Табылмады быел да
Тиңнәр безнең Абдулга.

Адәм түгел, җендер бу! —
Бөтенесен җиңде бу.
Гөрнадирдай ирләрне
Баш аркылы чөйде бу.

Әттә-тә-тә, әттә-тә,
Батыр Абдул нишләтә!
Соңра аңа бүләккә
Китерделәр зу-у-ур тәкә.

Үзеннән зур мөгезе,
Тәкәме бу, үгезме?
Батыр Абдул тегенең
Мөгезенә үрелде.

Их, күтәреп алмакчы,
Җилкәсенә салмакчы.

Күрче тәкә-сантыйны,
Кинәт артка тартылды
Һәм җиңелмәс Абдулны
Атты башы аркылы.

Абдул җиргә шап итте,
Бөтен халык аһ итте!
«Әттә-тә-тә, әттә-тә,
Сөбханәкә, вәт тәкә!»

Бер шаяны шунда ук
Билгеләде батырны:
«Тәкә — батыр, аңа без
Бүләк итик Абдулны!..»

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

Сабан туе — шатлык, бәхет туе,
Сабан туе — тарих көзгесе!
Сабан туе — безнең бәйрәмнәрнең,
Иң танлысы һәм иң изгесе.

Лена Шагыйрьҗан

ТАМЫРЛАР КАЯ ТОТАША?

ГАМИРҖАН ДӘҮЛӘТШИН,
тарих фәннәре докторы, КФУ профессоры

САБАН ТУЕ – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ҖАНЛЫ ГӘҮДӘЛӘНЕШЕ, АЕРЫЛГЫСЫЗ ХАСИЯТЕ, ТРАДИЦИОН КУЛЬТУРАСЫНЫҢ ЙӨЗЕК КАШЫ. САБАН ТУЕ, ҖЫЕН КЕБЕК БӘЙРӘМНӘРНЕҢ БИК БОРЫНГЫ ЗАМАННАРГА УК КИТҮЧЕ ТИРӘН ТАМЫРЛАРЫ БАР. УЛ БОЛГАР БАБАЛАРЫБЫЗДА ҖУЧИ ОЛЫСЫ ЧОРЫНДА ДА БӘЙРӘМ ИТЕЛГӘН БУЛСА КИРӘК. БЕР БОЛГАР-ТАТАР КАБЕР ТАШЪЯЗМАСЫНДА МӘРХҮМНЕҢ ҮЛГӘН КӨНЕ ТУРЫНДА «САБАНТУЙ КӨН ИДЕ» ДИЕЛӘ.

Бу ташъязмаларны өйрәнүче, укучы галим Ф.Хәкимҗанов әлеге язмада телгә алынган мәрхүмнең 1292 елның 15 июнендә үлүен әйтә. Белүебезчә, бу хәзер дә Сабан туйлары чорына карый. Әмма монда иң әһәмиятлесе шунда: бу чорда ук Сабантуй көне календарь, вакыт ориентирына әверелгән, борынгыдан килеп, тотрыклы күренешкә, болгар-татар тормышында иң әһәмиятле бөтен халык вакыйга-бәйрәменә әйләнгән. Әле XIX-XX гасырның беренче яртыларында да ел әйләнәсендәге вакыйгалар безнең татар халкында «Сабантуйга кадәр» һәм «Сабантуйдан соң» булган чорларга бүленгән.

Шундый бөтен халык бәйрәме хакында XVI гасырның беренче яртысында Казанда 20 ел яшәгән исеме билгесез, әмма «Казан тарихы» исемле күләмле китап язып калдырган рус авторы да искә ала. Ул Казан халкының сәйранда зур бәйрәмдә күңел ачулары хакында яза: «Патша һәм аның якыннары — аксөякләр корбан итеп симез үгезләр чалалар. Ә гади, кара халык сарык-тәкә, тавык корбан итеп чала. Һәм шуннан соң гомум күңел ачу, шатлык башлана. Йөз-битләрен ясанып, гөслә, кубызларда уйнап, матур җырлар башкаралар, кулларын чәбәкләп, сикерәсикерә бииләр». Әлеге бәйрәм корбан чалулар белән мөселман «Корбан бәйрәменә» тартым кебек. Әмма бию, җырлар белән ул гомум күңел ачуга кайтып кала. Бу, беренче чиратта, Сабантуйга тартым. Аның үткәрелү вакыты да сабантуйлар вакытына туры килә.

Әмма Сабантуй үзенең хасияте, тамырлары белән тагын да борынгырак чорларга китә. Аның тамырларына төшәргә күп кенә татар, рус галимнәре омтылыш ясап карады. Берәүләр Сабантуйның беренчел мәгънәсен язгы чәчүгә яки аграр культ белән бәйле болгар бәйрәме (Н.Загоскин, Г.Әхмәров, Я.Коблов, Р.Кәшәфетдинов, Р.Уразманова, Я.Ханбиков, Г.Бәширов), икенчеләр — яз бәйрәме (П.Рычков, Д.Асылов), өченчеләр «уянып килүче табигатькә гимн, югары, күк алласы — Тәңрегә табыну» (Б.Урманче) рәвешендә аңлаталар. Шулай итеп, күпчелек тикшеренүчеләр, нигездә, аның исеменә генә игътибар итеп, бу бәйрәмне сабан, язгы чәчү бәйрәме буларак карыйлар. Комплекслы чыганакларга нигезләнеп, борынгы карашлар белән бәйләп, татар милли бәйрәме Сабантуй тулырак рәвештә тарих фәннәре докторы Д.Шәрәфетдинов хезмәтләрендә тикшерелә. Автор Сабантуй — уянып килүче табигатькә, язгы чәчүгә бәйле борынгы календарь бәйрәм, дип яза.

Сабан туе бәйрәме бик борынгы чорларда ук барлыкка килгән. «Сабан туен күпчелек галимнәр игенчелек белән бәйләп карасалар да, бәйрәм-йоланың җисеме түгел, исеме генә чәчүне күз алдына китерә. Әмма Сабантуйның үз хасиятендә игенчелеккә, чәчүгә ишарә дә юк. Киресенчә, ул күчмә кабиләләр йоласына тартым (ат табанын кыздыру йоласы, ат чабышлары һ.б.). Шуның өчен дә, күрәсең, борынгылыкта аның исеме дә икенче мәгънәне аңлаткан булса кирәк. Дөрес, Сабантуй борынгы дәверләрдә барлыкка килгәнчә генә сакланмаган, һәр чорда үзгәреш кичергән. Игенчелек алга киткән Идел буе Болгар дәүләтендә Сабантуй язгы чәчү бәйрәме, сөрүлек җирләрне хөрмәтләү бәйрәме буларак яңа төсмер алган булуы мөмкин.

Әмма аның әлеге хасияте, ясалма рәвештә аеруча совет чорында күпертелеп, сәясәт белән бәйләп, «кырлар батырын» данлау өчен генә эшләнде. Шул рәвешле, бу бөек бәйрәмнең киң, югары эчтәлеге чикләнде.

Сабантуй — туган җиргә, табигатькә, тормышка дан җырлаган бәйрәм.

Һуннар, борынгы төркиләр үзләренең туган илләрен, җирләрен яратуны да культ дәрәҗәсенә җиткергәннәр. Аларда туган җирне ярату шул кадәрле көчле булган ки, хәтта аның аерым алласы да билгеләнгән. Бу — Урта, Җир өсте алласы — «Удук Йир-Суб» (изге җир-су), «Җир-су» — туган җирнең, илнең синонимы. Аның культы тау, кыя, күл, елга, җир ияләренә баш ию белән бәйле. Бу — табигатькә, «туган ягым — яшел бишек»кә Аллага баш игән кебек табыну. Изге таулар, биеклекләр, биек ялгыз агачлар да «Җир-су» культының аерылгысыз бер өлеше булган. Биек таулар һәм агачлар Җир белән Күкне, Тәңре белән аңа табынучы кешеләрне тоташтырган. Н.Бичурин Кытай елъязмасы «Вейшу»дан төркиләрнең Бодын-инли дип аталган башы шәрә биек тауны изгеләштерүләре хакындагы хәбәрне китерә. Көнчыгыш Төрки каганлыгы каганнары һәм халкы «Күк рухына» биек тауда табынганнар. Аның исеме «ил химаячесенең рухы» дигәнне белдерә икән. Димәк, бу тау һәм аның рухы ил иминлеген саклый дип ышанганнар. Тау атамасындагы «бодын-будун» борынгы төрки язмаларда «халык, ил» дигәнне аңлата. Шунысы гыйбрәтле: соңгы чорларга кадәр авыл аксакаллары Сабантуй уздырыр өчен урынны тау башында яки тау итәгендә сайлаганнар. Сабантуй репертуарында хәтта «тауга каршы йөгереш» ярышы булуы да мәгълүм. Элек Мамадыш төбәгендә, Сабантуй башлануын хәбәр итеп, тау башына ут ягу гадәте булган.

Борынгы төркиләр зур горурлык белән үзләренең туган җирләрен «төркиләрнең җир-сулары» дип йөрткәннәр. VI гасыр Византия тарихчысы Феофилакт Симокатта борынгы төркиләр турында «алар җиргә дан җырлыйлар», дип язган. Алардагы тылсымчылар «җирне чакыралар», ягъни җиргә эндәшеп, аның көчен сорыйлар, дип өсти. Туган җирне «җирсу» дип атау телебездә бүген дә кулланылышта. Телебездә туган җирне бик нык сагынуны белдерә торган тагын бер сүз бар: җирсү, җирсенү. Бу сүзләрнең «җир-су» сүзе, төшенчәсе һәм борынгы Җир-Су алласы белән бәйле булуы әллә ни шик тудырмый. Җиргә табыну халкыбызда соңгы чорларга кадәр дәвам иткән. Аңа багышлап төрле йолалар үткәргәннәр, аны искә алып ант иткәннәр: «Җир йотсын». Бу ант, сүзне раслау рәвешендәге гыйбарәне без бүген дә кулланабыз. «Йоту» фигыле, билгеле, туры мәгънәдә җан ияләренә нисбәтле әйтелә. Димәк, антыңда, сүзеңдә тормасаң, сине Җир (бик зур җан иясе) йотарга мөмкин. «Җир тота» да. Аның бу сыйфаты «Кыйссаи Йосыф»та ук теркәлгән. Зиндандагы Йосыфка хәбәр китергән гарәп дөясенә сугарга дип ниятләгәч, «аягын җир тота». Гарәп тәүбә кылгач кына, «аякларын җир җибәрә». Бу борынгы «Удук йир-суб» кыяфәтен төсмерләү дә кебек. Халкыбыз келәүләрендә дә аңа илаһи затка мөрәҗәгать иткән кебек эндәшелә. Аңарда кешегә хас кыяфәтләр дә чалымлана: «Җир атасы — җирән сакал! Җир анасы — асыл бикә!»

Бу изге җиргә урнашкан «түрк будунның» (түрк халкының) иле Тәңре иле дип йөртелгән.

Сүз дә юк, һуннарда да, борынгы төркиләр кулында да иксез-чиксез далалар, җирләр булган. Шуңа карамастан, алар һәр карыш җирнең кадерен белгәннәр. Бу җәһәттән, моннан 1200 еллар чамасы элек идарә иткән Шаньюй Мете чорындагы вакыйга гыйбрәтле. Һуннар үзара ызгышып яткан бер вакытта күршеләре бу форсаттан файдаланып калырга омтылганнар: аларның иң кадерле байлыгын — искитмәле бер атны һәм Метеның яраткан хатынын бирүне таләп иткәннәр. Аксакаллар баш тартмакчы булса да, Мете: «Күршеләр белән янәшә яшәп, нәрсәгә алардан бер атны һәм бер хатын-кызны кызганырга...» — ди. Сораганнарын күршеләренә биреп җибәрә. Күп тә үтми, шул ук күршеләре — монгол дунху кабиләләре мал йөртергә дә яраксыз кечкенә генә бер җир кисәген сорыйлар. Аксакаллар бу начар җирне бирергә уйласалар да, Мете моңа каршы төшә: «Җир — дәүләтнең нигезе, ничек аны бирмәк кирәк», — ди ул.

Борынгы төркиләр Җир-Суны бербөтен итеп күзаллаганнар, дидек. Алда күбрәк җир турында сүз булды. Төркиләрнең Су белән бәйле карашлары да кызык. Кытай чыганакларында төркиләрнең бишенче айның икенче ункөнлегендә, елга буена җыелып, Күк рухына корбан бирүләре хакында сөйләнелә. Монда елга Күккә юл кебегрәк күзаллана. Аларда шундый сүзләр теркәлгән: «Тюкюлар бишенче ай буена гадәттәгечә Күккә корбан итеп, сарыклар һәм атлар чалалар» яки: «Тюкюлар бишенче айның уртасында, Күк алласына корбан бирер өчен, Тамир елгасына җыелып, күпләгән сарык һәм ат чалалар». Бишенче ай борынгы Кытай календарендә (төрки-монгол календаре, галимнәр фикеренчә, VIII гасырда гына барлыкка килә) июнь аена (5-10 араларында) туры килә. Бу йолада бөтен ыру-кабилә катнашкан. Болгар кабиләләренең июнь башында Яушир елгасы янына җыелуын безгә Ибне Фазлан хәбәр итә. Чыннан да, бу — җыеннар, сабантуйлар вакыты.

Шулай итеп, борынгы бабаларыбызда Туган ил Туган җир төшенчәсе белән аерылгысыз бәйләнештә була. Хәтта бу төшенчәләргә караган махсус Җир-Су алласы да була. Ләкин борынгы төркиләр, моның белән генә чикләнеп калмыйча, аңа көчле иҗтимагый аһәң бирәләр. Безнең экологик киеренкелек чорында мондый идеология аеруча актуаль. Югарыда китерелгәннәрнең барысы да безнең Сабантуй бәйрәменең асыл рухын, үзәк хасиятен тәшкил итә.

Инде Сабантуйның символик иң зур бүләге — тәкәгә килик. Төрки татарларда культка әйләнгән бу хайван борынгы бабаларыбыз карашында тотем хайваннан алып Сабантуй батырына бирелә торган иң зур призга җитәрлек юлны узган.

Борынгы төркиләрдә тәкә иң культлаштырыла торган һәм Тәңрегә, Күккә, Кояшка иң кулай корбан хайваннардан саналган. Аның культы алга таба да дәвам итә. Болгар, угыз, кыргыз кабиләләрендә изге хайван санала. Потка охшаш тәкә сыннары болгар археологик материаллары арасында да еш табыла.

Шулар арасыннан Биләрдә табылган зур мөгезле тәкә башы кыяфәтле куыш керамик фигура-су сипкеч игътибарны үзенә җәлеп итә (рәсемдә). Гомумән, бу — дәһшәтле, беркадәр

Бронза матрица. XI-XII гасырлар. Биләрдән.

Керамик магик җайланма – су сипкеч. Биләрдән.

куркыныч сын. Күрәсең, ул табына торган сындыр. Безнең карашыбызча, ул болгарларда корылык чорында «Яңгыр чакыру, яңгыр теләү» магик инструмент ролен үтәгән булырга тиеш. Рухи яктан Тәңре белән иң тыгыз бәйле хайван — тәкә. Ә яңгыр — Тәңре кодрәтендә.

Хәзер дә телебездәге «Алланың кашка тәкәсеме әллә син?» дигән гыйбарә дә тәкәнең борынгылыкта Тәңрегә нисбәтле хайван булуы һәм аның культы хакында сөйли. С.Кляшторный фикеренә караганда, Икенче төрки династиянең (683-744) (шул вакытта Икенче Төрки каганлыкның да) геральдик билгесе «башы ромб шәкелендәге тәкә» сурәте булган. 733 елда төзелеп бетеп, бо-



Күл-Тәгин мавзолее капкасы алдындагы тәкә сыннары. VIII гасыр.

рынгы төркиләрнең гаскәр башлыгы, тәхет варисы, Билге каганның энесе Күлтәгингә куелган мемориаль комплекс һәм андагы язмалар бик мәһабәт. Аңа керә торган капка янында мәрмәрдән бер-берсенә кара-каршы торган ике тәкә сыны (рәсемдә) куелган. Мондый сурәт Капаган каганга куелган дип уйланган мемориаль комплекстагы ташбака сынының янәгына төшерелгән.

Татарларда «Күк тәкәсе»нә (борынгы мәгънәдә — «Тәңре тәкәсе») ышану яшәгән. Аңа махсус җыен багышланган («Күк тәкә җыены»). Сабантуй һәм Җыен тора-бара бер бәйрәм булып кушылалар. Әмма борынгы чорларда Сабантуй, беренче чиратта, ирләр бәйрәме саналган, киләчәк сынауларга, көрәшләргә генераль репетиция ролен дә үтәгән. Юкка гына әлек Сабантуйны — ирләр, ә Җыенны хатын-кызлар бәйрәме димәгәннәрдер.

Кыпчак хатын-кызларының баш киемен сырланып килгән тәкә мөгезе рәвешендә (тормышта — киездән) эшләнгән әйберләр бизәгән. Бу бер үк вакытта югары катлам хатын-кызларның башкалардан аерылып тору билгесе дә булгандыр. Төрки мифологиядә мөгезнең мәгънәсен без алда карап узган идек инде. Ул — мәртәбәлелек, өстенлек билгесе. Моннан тыш, тәкәнең Тәңрегә корбан ителә торган хайван булуы һәм аның бүгенге татар әйтемнәрендә дә саклануы хакында тагын бер кат искә төшереп үтик.

Халык исеменең (этнонимның) тотем исеменә нигезләнүе — борынгылыкта киң таралган күренеш. Бу төрки кабиләләргә дә хас. Ул болгар кабиләләренең исемнәрендә дә урын алган. Мөгаен, болгар кабиләләреннән «бәрәнҗәрләр» — «бәрән (тәкә) җире» дигәнне, ә «аскел» «ас урыны» дигәнне аңлатадыр.

Аспарух ханның варислары саналган Дунай болгарлары «Исемлеген»дә ел хисабы 12 еллык җанвар календарендә сигезенче ел Теку (Тәкә) исемен йөртә.

Тәкә образы Тәңре, Күк белән тыгыз бәйләнештә булган һәм ул борынгы төркиләрнең космогоник карашларында да зур урын тоткан. Археологик ядкәрләрдән күренгәнчә, тәкә кояш, күк символын да чагылдырган. Шундый ядкәрләрнең берсендә түгәрәк җиз калыпка әйләнә буйлап симметрик рәвештә стильләштерелгән тәкә башлары сурәте урнашкан (рәсемдә). Уртада

— схематик рәвештә эшләнгән нурлы кояш рәсеме. Дүрт тәкә башы сурәте бергә соляр тамга — кояш, ай символы булган әвернә хасил итәләр. Әйтерсең, тәкәләр кояш тирәсендә очып йөриләр.

Болгар бизәкләрендәге тәкә башлары ирексездән Көнчыгыш Алтайда казып тикшерелгән һәм иң борынгы төркиләр белән бәйле Пазырык курганнарыннан табылган рәсемнәрне күпмедер дәрәҗәдә искә төшерә. Анда тау тәкәләре башлары кояшны хәтерләтә: тәкә башларыннан әйләнә буенча кояш плазмасына, ялкын телләренә охшаш чыгымтылар сузылган. Яисә тәкә башларыннан шулай ук әйләнә буенча кызгылт җепләр таралган.

«Сыңар мөгез күк тәкә, күктән төшеп су эчә» дигән табышмак та югарыда әйтелгән фикерләр белән аваздаш. Кое сиртмәсе шул рәвешле тасвирлана. Монда тәкәнең сыңар мөгезле булуы табышмак җавабына буйсындырырга тырышу нәтиҗәсе генә. Башкорт эпосларында Киек каз юлы Мөхәммәд пәйгамбәрнең алтын мөгезле тәкәгә утырып үткән юлы буларак сөйләнелә. Бу — зур игътибарга лаек сюжет. Ул һич тә турыдан-туры ислам, Коръән белән бәйле түгел. «Мөхәммәд пәйгамбәр» соңгырак чор трансформациясе генә. Борынгы төрки мәҗүсилектә аның урынында Тәңре булган. «Алланың *(Тәңренең. — Г.Д.)* кашка тәкәсе» гыйбарәсендә тәкәнең Тәңрегә корбан хайваны гына түгеллеге яхшы аңлашыла. Күз алдына күктә бик зур мөгезле гигант кашка тәкәсе өстенә утырган Тәңре сурәте килеп баса. Башка археологик истәлекләрдәге тәкә сурәтләрендә дә мөгезләр калку итеп бирелгән. Мөгез мифларда, фольклорда җир белән күкне тоташтыручы элемент буларак күзаллана. Тарихчы Г.Фәйзрахманов

Җиз камчы сабы. Биләрдән.

мәгълүматларына караганда, Арча районы авылларында түбә кыегының алдына тәкә мөгезләре кую сирәк күренеш булмаган.

Шулай итеп, Сабантуйның традицион иң зур бүләге Тәкә — бик борынгы заманнардан килгән Тәңре белән бәйле мифологик образ. Кайчак хәзерге чор Сабантуй батырларына аның урынына мотоцикл, машина кебек нәрсәләрне бирү дә күзәтелә.

Сабан туена беренче кешелек җәмгыятьләреннән үк килгән коллективизм рухы хас. Ул хезмәт, көнкүреш белән дә бәйле. Сабантуй йола бәйрәме тәҗрибәсе халык авыз иҗаты чаралары белән буыннардан буыннарга тапшырылган. Ә борынгылыкка, тарихка хөрмәт безнең бабаларыбызда бик югары торган. Шуңа күрә дә мәкаль-әйтемнәрне «борынгылардан калган сүз», «аталар-бабалар сүзе» дигәннәр. Алар борынгы дәверләрдә әле рәсми кануннар ныклап урнашканчы язылмаган законнар ролен үтәгәннәр. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, халык идеал-

ларын чагылдырганнар. Шуңа күрә дә алар зур хөрмәткә ия булганнар. Юкка гына халык: «Картлар сүзен ишеткәндә, бүркеңне куеныңа куй», — димәгән. Бу мәкаль дә болгарлардан, борынгы төркиләрдән үк килә. Ибне Фазлан аларда хөрмәтле кешеләр белән, аерым алганда, патша белән очрашканда, бүрекләрен култык астына кыстыру гадәтен сөйли. Сабантуйларда аксакалларның урыны һәрчак гаять зур әһәмияткә ия булган. Нәкъ менә алар, борынгыдан килгән традицияләргә нигезләнеп, бәйрәмнең вакытын, урынын билгеләгәннәр, уздыру тәртибен саклаганнар. Өлкән буынга карата зур хөрмәт төрки-татар тарихының бар чорына да карый. Татар халкының йөзен билгели торган бу асыл сыйфатны электән үк күп милләт авторлары тәгаенләп үтәләр.

Сабантуй — универсаль бәйрәм. Бу хасияте белән ул дөнья халыкларының күп бәйрәмнәренә тартым. Әлеге сыйфат аның киң таралышына китергән дә. Ул татар халкы белән кардәш башкорт, карачай-балкар, кумык, ногай, гагауз, дунай болгарларында гына түгел, гасырлар буе ут күршеләр булып яшәгән башка халыкларда да яратып бәйрәм итәлә.

Р.Әхмәтов фотосы

ЧАБЫШ АТЛАРЫ

САЛИСӘ ГӘРӘЕВА

Оран салды мәйдан: «Атлар килә!
Атлар килә — чабыш атлары!»
Бар микән ул татар йөрәгенең
Атка сокланмаган чаклары?!
Җилдәй җитез, җилбер яллы атлар,
Муеннары — аккош муены!
Изге йола: көч сынашыр өчен
Атлар чыга Сабан туена.
Ялларына бөдрә башын иеп,
Йөгерек атын куа бер егет.
(Бу дөньяда без бит үзебез дә
Бәйгеләрдә чапкан ат кебек.)
Канатлы ат сыйган җаны белән
Авыл йөгерә атлар каршына.
Сабантуйда чапкан малкайларны
Сөлге белән, халкым, каршыла!..
Атлар уза мәйдан уртасына:
Беренчесе… аннан башкалар —
Алмачуар, Кара-туры атлар,
Җилбер яллы җирән кашкалар…
Бер әбинең күрәм юл читендә
Чиккән сөлге тотып торганын:
Сөлгесен ул салыр муенына
Иң ахырдан килгән юрганың.

«САБАН ТУЕ – БЕЗНЕҢ ТУЙ, СӨЛГЕ-ЯУЛЫК САЙЛАП КУЙ»

РАМИЛ ХАННАНОВ,
филология фәннәре кандидаты

ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ТАМАШАЛЫККА ОМТЫЛЫШЫ БИК БОРЫНГЫ ЗАМАННАРГА БАРЫП ТОТАША. АРХЕОЛОГИК ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ВАКЫТЫНДА БАБАЛАРЫБЫЗНЫҢ ТӨРЛЕ КАРНАВАЛЛАР, МӘЙДАН ТАМАШАЛАРЫ УЗДЫРУЛАРЫНА БӘЙЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ТАБЫЛУЫ МӘГЪЛҮМ.

Милли театрларның, спектакльләр өчен нигез булган пьесаларның беренче яралгыларын төрле халык уеннарында, Җыен, Нәүрүз, Сабантуй кебек бәйрәмнәрдә, боз озату, аулак өй, бәби туе, күрсәтү мәҗлесләреннән бүләк, йорт-җир, кием-салым багулар, өй туйлары кебек йолаларда, күмәк хезмәт төрләре булган өмәләрдә (каз өмәсе, йорт күтәрү, мал сую, печән чабу өмәләре һәм башкалар), күмәк ауларда, күңел ачу чараларыннан аю биетү, ат кәмитләрендә һәм башкаларда күрергә мөмкин. Төрки халыкларның бик борынгыдан килә торган әлеге йолалары, бәйрәмнәре, уеннары, мәйдан тамашалары, маскарадлар аларның милли мәдәниятләре, сәнгатьләре формалашуга этәрә, гасырлар буена сыналган барлык рухи хәзинәләрен үзләрендә саклаган хәлдә, кешенең гармонияле үсешен тәэмин итә, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Шуңа күрә тамырлары ерак чорларга барып тоташкан халык йолаларына, гореф-гадәтләренә, карнавал уеннарына аерым әһәмият бирү шарт.

Милли бәйрәмнәрнең иң борынгысы һәм киң даирәдә уза торган Сабан туеның да халыкны тамашалыкка өндәүдә башкарган вазифасы зур әһәмияткә ия. Сабан туе — сука туе, икенче төрле әйтсәк, иген туе ул. «Сабан» сүзе суканы да, игенне дә белдерә,

Төрки халыкларның борынгыдан килә торган йолалары аларның милли мәдәниятләре, сәнгатьләре формалашуга этәрә, кешенең гармонияле үсешен тәэмин итә, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә.

ә туй — бәйрәм, тантана дигән сүз. Төрки халыкларның күбесе борын-борыннан иген үстерү белән шөгыльләнгән. Алар тормышларында иң әһәмиятле мизгелләр дип икмәкне чәчү һәм җыеп алуны санаганнар. Сабан туен борынгы заманнарда кыр эшләрен башлап җибәрер алдыннан үткәргәннәр (апрель ахырларында). Бүген исә Сабантуй бәйрәмен язгы кыр эшләрен тәмамлагач уздыралар. Аның элеккеге чорлардагы максаты, иген уңсын өчен, уңыш иясенә табыну булса, соңга табарак, ул язгы авыл хуҗалыгы эшләренең төгәлләнүе буларак бәйрәм ителә. Бүген Сабантуй — татар, башкорт һәм элек-электән алар белән янәшә яшәп килгән рус, мари, чуаш халыкларының да яраткан бәйрәме. Ул — дуслык-татулыкка, үзара аңлашуга корыла һәм «әкренләп милләтара аралашу бәйрәменә» [1] әверелә. Н.И.Ашмарин язганча [2], чуаш халкында Әкә-туй бәйрәме татарларның Сабантуй бәйрәме белән зур уртаклыкларга ия.

Әкә-туйда да ат чабышлары, көрәш һәм башка уен-ярышлар уздырыла. Әлеге бәйрәм шулай ук язгы кыр эшләре төгәлләнгәч билгеләп үтелә.

1. Марьянов Б. Праздники, обряды, традиции / Б.Марьянов. — 2-е изд., доп. и перераб. — М.: Мол.гвардия, 1979. — С.82.

2. Ашмарин Н.И. Словарь чувашского языка. Вып.XV / Н.И.Ашмарин. — Чебоксары: Чув.гос.изд-во, 1938. — С.94-95.

Р. Якупов фотолары

Р.Әхмәтов фотосы

Гасырлар катламы Сабантуй бәйрәменең кайчаннан үткәрелә башлавы турындагы мәгълүматларны бик тирәнгә күмеп калдырган. Шулай да Сабан туеның үткәрелү тарихына кагылышлы кайбер сакланып калган материаллар безнең өчен кызыксыз була алмый. Галимнәр раславынча [3], дини ышанулары тәңречелек булган төркиләр яз җитүгә, ягъни җирнең яңадан тууына багышлап корбан чалганнар. Бу йола кысаларында ат чабышлары, кылычлар белән сынашлар, җырлы-биюле уеннар, бәйгеләр үткәрелгән. Әлеге йоланың бүгенге көндә уздырыла торган Сабантуй бәйрәме белән уртаклыклары бик күп. Багдад илчесе, күренекле сәяхәтче Ибн Фадлан инде 921 елда ук үзенең хезмәтләрендә Сабантуй турында мәгълүматлар язып калдырган. Шулай ук безгә күренекле галим Карл Фуксның да әлеге бәйрәмгә карата белдергән фикерләре мәгълүм. Ул 1844 елда уздырылган Сабантуй күренешен «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях» исемле хезмәтендә тасвирлаган.

Халык бәйрәме буларак, Сабантуй өч өлештән тора: әзерлек, бәйрәмне үткәрү — мәйдан көне һәм йомгаклау. Әлбәттә, төп игътибар ярыш-бәйгеләргә бирелә.

Элек Сабантуйга әзерлек мәшәкатьләрен Карга боткасы — балаларның күмәкләшеп ботка пешерү һәм сыйлану йоласы башлап җибәргән. Бу йола аларның, кызыл башлы тастымаллардан махсус тегелгән янчык-сумкалар асып, өйдән-өйгә кереп, төрле ярмалар, сөт, май, йомырка җыеп йөрүе белән башланып киткән. Икенче көнне өлкән яшьтәге берничә хатын-кыз ярдәмендә, зур казан асып, җыелган ярмалардан сөтле ботка пешерелгән һәм балалар сыйланган. Сыйдан соң төрле уеннар уйналган, үзара ярышлар уздырылган. Биредә балаларның тапкырлыгы, җитезлеге сыналган. Бүгенге көндә инде әлеге йола шактый онытылган. Бары тик аның кайбер элементлары гына сакланып калган. Мәсәлән, балаларның Сабантуй алдыннан йомырка җыеп йөрүләре, ә бәйрәм вакытында йомыркаларның төрле ярыш-уеннар өчен кулланылуы әнә шул турыда сөйли.

Сабантуйга әзерлекнең тагын бер йоласы — бүләк җыю. Һәр йортта бүләк хәстәрен алдан күргәннәр: төрле-төрле сөлгетастымаллар, яулык-кулъяулыклар, күлмәк, ашъяулыклар әзерләнгән. Бүләк җыю эше яшь егетләргә тапшырылган. Сабан туе башланыр алдыннан, кыңгыраулар тагылган атларда яисә җәяү, гармуннар уйнатып, яшьләр авыл ураган. Ә бүләкләр

3. Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа / Р.К.Уразманова. — Казань: Татар. кн.изд-во, 1984. — С.250.

Р.Якупов фотосы

Бүген Сабантуй — татар, башкорт һәм элек-электән алар белән янәшә яшәп килгән рус, мари, чуаш халыкларының да яраткан бәйрәме.

озын колгага яисә бүләк җыючыларның җилкәләренә ике якка асылындырып бәйләнгән. Бу йола бүгенге көндә дә шундый ук тәртиптә үткәрелә.

Сабантуй алдыннан иртә таңда, кара түбәтәй, ак күлмәк, кара чалбар, киез итекләр киеп, билләренә чиккән сөлгеләр буган яшь егетләр авыл башына җыела. Кукмара районының Күкшел авылында, мәсәлән, Сабан туе алдыннан уздырыла торган Сөрән салу йоласы әнә шулай башланып китә. Авыл халкы да бу төнне йокламый, яшьләргә ишек алдында сый өстәле әзерли. Сөрәнчеләр исә, төрле такмаклар әйтеп, өйдән-өйгә кереп, Сабан туена бүләк җыялар.

Йола буенча яшь киленнәр чиккән сөлге, буй җиткән кызлар чиккән кулъяулык, хәтта кунак кызлары да яулык бирергә тиеш булалар. Сөрәнчеләр исә рәхмәтне аеруча тәмле теллеләнеп, матурлап әйтәләр, юмарт хуҗаларны күкләргә чөеп мактыйлар һәм аларны Сабантуйга чакыралар. Сөрән салу төш авышкач тәмамлана. Авылны йөреп чыккач, җыйган бүләкләрне Сабан туен үткәрүчеләргә тапшыралар. Яшьләр, өйләренә таралып, бераз ял иткәннән соң, мәйданга юнәләләр.

Бу йола халыкны бәйрәмнең кульминацион мизгеленә — мәйданга әзерли. Фәнни хезмәтләргә [4] күз салсак, Сөрән салу йоласы башка халыкларда да очрый. Мәсәлән, башкортларда ул «һөрән», чуашларда «сөрән», мариларда «сюрем», удмуртларда «сүрен» дип атала. Борынгырак заманнарда Сөрән апрель аенда, кар сулары аккан вакытта, язны каршылау бәйрәме буларак үткәрелгән. Бүгенге көндә Кукмара районында сөрәнче егетләрнең киез итек киюләре шуның белән аңлатыла булса кирәк.

4. Надиров И.Н. Татар халкының йола поэзиясе, уен җырлары, бию такмаклары / И.Н.Надиров // Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. — Казан: Татар. кит.нәшр., 1980. — Б.10.

Сабантуй бәйрәменең мәйдан өлеше батыр билгеләнгәннән соң тәмамлана. Батыр мәйдан тота. Ләкин бу әле бәйрәм бетте дигән сүз түгел…

Әлеге бәйрәм алдыннан йорт-җирләрне чистартканнар, кешеләр үзләре дә пакьләнгәннәр. Аннан төркемнәргә җыелып, төрле тылсымлы сүзләр әйтеп, сөрән салып, йорттан һәм, гомумән, авылдан явыз рухларны, авыруларны куганнар. Бу халыкның язгы кыр эшләрен сау-сәламәт һәм күтәренке кәеф белән башкарырга әзерләнүләрен күрсәткән. Яшьләр, йорт саен кереп, хуҗаларга изге теләкләр теләп, бүләкләр җыйганнар һәм авыл читенә чыгып, төрле ризыклар әзерләгәннәр, учак янында уеннар уйнаганнар.

Үзбәк халкында да татарлардагы Сөрән салуга охшаш йола бар. Беренче умырзаялар күренә башлауга (гадәттә, бу февраль ахырларында була), балалар, өйдән-өйгә кереп, җырлар җырлап, яз килүен хәбәр итеп йөриләр. Аларның такмак-җырлары күпмедер дәрәҗәдә Нәүрүз әйтү такмакларына да охшаш. Игътибар итик:

Бойчечагим бойланди,
Козон тола айрондир.
Айронингдан бермасанг,
Козон тавогинг вайрондир.

Тәрҗемәсе болайрак:

Умырзая чәчәк атты,
Казан әйрән белән тулды.
Әйрәнең белән уртаклашмасаң,
Казаның һәм тәлинкәң ярылачак.

Татар халкында Сөрән йоласына зур мәгънә салынган, аның магик функциясе булган. Сөрән үткәрелсә, җәй көне өермәләр булмый дип ышанганнар. Явыз рухлардан арыну максатыннан, төрле им-том такмаклары әйтә-әйтә, сөрән (ягъни аваз) салып, авыл кешеләре урам уртасында ягылган учак аша сикергәннәр. Әлеге ритуалларның кайбер элементлары бүгенге көндә дә сакланып калган. Мәсәлән, Самара өлкәсе Келәүле районының Назаровка авылында яшәүче керәшен татарлары, язгы кыр эшләре тәмамлангач, Яфрак бәйрәме уздыра. Ул үзенең эчтәлеге, торышы ягыннан бездәге Сабан туен хәтерләтә. Драматург Туфан Миңнуллинның бу бәйрәмгә бәйле әһәмиятле фикерен искәртү зарур. «Татарларны көчләп чукындыру заманында патша хөкүмәтләре Сабан туен бәйрәм итүне тыйганнар. Чөнки татарларны үз бәйрәмнәрендә аралаштыру патшаларның милли сәясәтенә каршы килгән. Ләкин татарлар барыбер кача-поса гына булса да бәйрәм иткәннәр. Дөньяга төнге Сабантуйлары туган. Керәшеннәр аны бүген дә бәйрәм итеп уздыралар» [5], — дип яза ул.

Дөрестән дә, бүгенге көндә татар халкында уздырыла торган

5. Миңнуллин Т. Сабан туе безнең туймы? / Т.Миңнуллин // Татарстан яшьләре. — 2004. — 28 сентябрь.

Сабан туе белән керәшен татарларының әлеге бәйрәме тарихи яктан бәйләнгән булса кирәк.

Керәшеннәрнең Яфрак бәйрәме болайрак уза: кич белән авыл халкы тау башына учак яга. Учакка машина тәгәрмәчләре (покрышкалар) салына. Ут үрләгәч, яшь егетләр, ир-атлар тау башыннан әлеге тәгәрмәчләрне тәгәрәтә башлыйлар. Тәгәрмәч тәгәрәтү йоласы күпмедер дәрәҗәдә Сөрән салу йоласы белән аваздаш. Аларның магик функцияләре уртак: явыз көчләрдән арыну. Ләкин һәрберсе аерым үзенчәлекләргә ия.

Фольклорчы галимнәр, вакытлар узу белән, татарларда Сөрән салу йоласының Сабан туе белән берләшүе турында әйтәләр. Кукмара районында Сөрән йоласының Сабан туе алдыннан уздырылуы — моның ачык мисалы. Күп кенә башка төбәкләрдә әлеге йола яшьләрнең Сабан туе алдыннан яулык җыюы буларак кына сакланып калган.

Сабантуй бәйрәменең иң зур һәм әһәмиятле өлеше — мәйдан көне. Нәкъ менә шушы көн, Сабантуйның кайсы гына җирдә уздырылуына карамастан, ярыш-бәйгеләрнең, уеннарның бер үк төрләләре үткәрелүе белән әһәмиятле: ат чабышы, көрәш, йөгерү, сикерү, гер күтәрү, капчык белән сугышу, капчык киеп йөгерү, аркан тарту, колгага мену, чүлмәк вату һәм башкалар. Болар барысы да мәйданда үтә. Шуңа да мәйдан ул — арена. Мәйдан ул — трибуна.

Мәйданда ярышлар элек-электән килгән тәртиптә алып барыла. Башлап ат чабышлары оештырыла. Беренче килүче атка иң матур сөлге тапшырыла. Ат чабышлары белән бергә Сабантуйның төп бәйгесе — көрәш башлана. Гадәттә, көрәшне биш-алты яшьлек ир балалар башлап җибәрә. Аларны үсмерләр, ир урталары алмаштыра. Көндәшен, җирдән күтәреп, аркасына сала алган көрәшче җиңүче дип исәпләнә. Батырга чигелгән сөлге һәм традицион бүләк — тәкә бирелә. Көрәш барышында махсус мәйданчыкларда башка ярышлар, уеннар оештырыла.

Аерым бер урында гармунчы, курай-кубызчылар, скрипкачы осталар көч сынаша. Җырчылар, сүз осталары үзара ярыша. Әлеге ярышлар, уеннар бик борынгыдан килә.

Сабантуй бәйрәменең мәйдан өлеше батыр билгеләнгәннән соң тәмамлана. Батыр мәйдан тота. Ләкин бу әле бәйрәм бетте дигән сүз түгел. Сабан туеның тәмамлау өлеше дә бар. Ул яшьләрнең кичке уеннарыннан гыйбарәт. Сабантуй мәйданында яки аңа якын болында төн уртасына кадәр яшьләр әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар уйныйлар. Әйткәнебезчә, әлеге җыр-биюләргә, уен-тамашаларга бай Сабантуй бәйрәме бик борынгы чорларга барып тоташа.

Казакъларның борынгы йолаларын саклап килгән һәм гаять киң колач җәйгән милли бәйрәмнәре Камал ает та татар-башкорт халыкларының Сабан туе кебек зурлап уздырыла. Күп гасырлар буена сакланган гореф-гадәткә тугры калып, казакъ-

лар язның беренче көнендә (бу — казакълар өчен яңа елның беренче көне дә, чөнки алар Григориан һәм Юлиан календарьларын үз итмиләр, Яңа ел бәйрәме алар өчен 1 мартта, ә иске стиль буенча 14 мартта башлана), өйләреннән чыгып, барлык туган-тумачалары, якыннары белән күрешәләр. Кул кысышу ачык күңеллелек, иминлек билгесе булып тора.

Элек-электән авыл халкы Камал аетны өйләрендә бәйрәм иткән. Бүгенге көндә инде казакълар әлеге бәйрәмне күмәкләшеп уздыра, халык уеннары, ат чабышлары, көрәш үткәрелә, халык балладаларын җырлап, зур концерт оештырыла.

Әмма Камал аетны бәйрәмчә бизәлгән табыннан — дастарханнан башка күз алдына да китереп булмый. Барлык концерт-ярышлар да тостлар, теләк әйтүләр белән үрелеп бара. Авылның аксакалы думбрада уйный башлый. Аңа кушылып, бер яшь кыз җырлап җибәрә, халык көе, төрле биюләр башкарыла.

Гомумән, казакъ халкының бию сәнгате борынгы чорлардан ук килә. Моның шулай булуын «Өрмәк бию», «Коян биюе», аучыларга багышланган шаян, юмористик «Аю биетү», «Насыбайшы», «Өртеке», «Каражора», «Тепекөк» кебек халык биюләре раслый. Биюләргә казакъ халкының сәнгатькә булган мәхәббәте салынган. Алар аша әлеге милләтнең тормыш-көнкүрешен ачык аңларга мөмкин, ягъни биюләр билгеле сюжетларга корыла. Шулай ук казакъ фольклорына хас булган бер үзенчәлек — җырларның төрле биюләр белән берьюлы башкарылуы да тамашалыкка омтылышның шактый көчле булуын күрсәтә.

Казакъ халкында егет белән кызның парлап башкара торган сюжетлы «Коян-бүркет» биюе бар. Бу шулай ук милли үзенчәлек саналырга хаклы. Чөнки башка төрки халыкларда мондый төр биюләр бик сирәк башкарыла торган була.

Казакъ биюләрендә тамашалыкка омтылыш үзен көчле сиздерә, дидек. Моның шулай икәнен без биюләрнең, ниндидер бер канунлаштырылган формаларга салынмыйча, импровизация рәвешендә булуыннан да күрәбез. Казакъ биюләренә хореографик драматизм хас. Мәсәлән, «Салыма» биюе әнә шундыйлардан. Шулай ук биюне атка атланган хәлдә башкару шактый кызыклы. Атны үз ритмыңа буйсындыру бары тик чын осталарның гына кулыннан килә.

Казакъ халкының театр сәнгате дә нәкъ менә шул биюләргә, төрле йолаларга (беташар, бәдик, жар-жар, жоктау, коштасу, кыз кәде, шилдеханә һәм башкалар), уеннарга (алтыбакан, кыз ойнак, кынаменде, ортеке, судыр-судыр һәм башкалар), акыннарның айтысларына барып тоташа. Борынгыдан килгән тамашалыкка омтылыш һәм татар сәхнә сәнгатенең йогынтысы нәтиҗәсендә оешып киткән казакъ театрына бәйле рәвештә, Җаек, Омск, Оренбургта рус театрлары барлыкка килә.

Татар һәм башкорт халыкларын дөньяга таныту, аларның рухи бердәмлеген, мәдәниятләрен, сәнгатен, телләрен саклау чарасы, символы буларак яшәп килгән Сабан туена да, казакъ халкының милли Камал аетына да тамашачы һәм уенда катнашучыларның берлеге хас, аларның үткәрелә торган күпчелек уен-чаралары, ярышлары уртак. Монда теләсә кайсы вакытта уеннарда, җырлы-биюле тамашаларда катнашырга мөмкин. Болар барысы да халыкның сәнгатькә мәхәббәтен, булган осталыгын күрсәтә. Әлеге һәвәслек ерак тарих белән бәйле. Археологик табышлар раслаганча, төрки кавемнәрдә халык уеннары бик борынгы заманнарда ук үткәрелә торган булган [6]. Аларда укымышлылык, осталык, зирәклек һәм үткен көлү югары бәяләнгән [7]. Сәхнә сәнгатенең комедия жанры турында сүз алып барганда, әлбәттә, әлеге әһәмиятле фактларга тукталмый мөмкин түгел. Чөнки милли драматургияләр, гомумән, милли әдәбиятлар, фән таләп иткәнчә, дөнья әдәбияты кануннарына буйсынса да, халыкның үз хәзинәләренә, үз традицияләренә нигезләнеп формалаша. Бүгенге көндә инде онытыла башлаган төрле уеннарның, йола-бәйрәмнәрнең халыкны мәдәниятле, бигрәк тә театрлы, драматургияле итүдәге роле чоры өчен бик әһәмиятле була.

Тарих тәгәрмәченнән күп кенә тамаша төрләре, матур традицияләр төшеп калса да, Сабан туе үз кыйммәтен югалтмады. Ул тагын да зуррак дәрәҗәгә күтәрелде — аны халыкара масштабта таныйлар. Бу көннәрдә авылларыбызда, шәһәр һәм район үзәкләрендә, алай гына да түгел, Россия киңлекләрендә, дөнья күләмендә, халкыбызны берләштереп, Сабан туйлары гөрли.

6. Сабиров А. Термины узбекских народных зрелищ: Автореферат дис…канд. филол.наук / А.Сабиров. — Ташкент, 1988. — С.2.

7. Ханзафаров Н. Татарская комедия (Истоки и развитие): Автореферат дис… докт.филол.наук / Н.Ханзафаров. — Казань, 1996. — С.10.

Р.Әхмәтов фотосы

Лотфулла Фәттахов. «Сабантуй». 1957

УЛ ЗАМАНДА

ИРЕК САБИРОВ

Альбомнарда актарынган чакта,
Ирексездән саркый яшьләрем,
Күргән саен рәссам Фәттаховның
«Сабан туе» дигән әсәрен.

Күргән кебек булам сөлге җыю,
Вәсиләнең кара толымын;
Мәмдәл белән Юртыш арасында
Җәйрәп яткан Сыза болынын.

Шул болынга кереп китәр булып
Хәйран калып карап утырам:
Йә көрәшәм мышнап, йә чабышып,
Җитез аргамакта сыптырам.

...Ул заманда гармуннардан агып
Дәртләндерә иде саф моңнар;
Ул заманда ирләр аек иде,
Елмаючан иде хатыннар...

Г. Хафизов фотосы

ФӘРИТ УРАЗАЕВ,
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының бюро әгъзасы, тарих фәннәре кандидаты

ШУНЫСЫ ШАТЛАНДЫРА: СОҢГЫ ДИСТӘ ЕЛЛАРДА РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ, БДБ ҺӘМ ЕРАК ЧИТ ИЛЛӘРНЕҢ ТАТАР ХАЛКЫ ТУПЛАНЫП ЯШИ ТОРГАН БАРЛЫК ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ ДӘ БОРЫНГЫ БӘЙРӘМЕБЕЗ – САБАН ТУЕН ҮТКӘРҮ ЯҢАРЫШ ЧОРЫН КИЧЕРӘ.

ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ: ТӘҖРИБӘ ҺӘМ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАСЫ

Купләгән галимнәрнең әлеге мәдәни материалны, тикшеренеп, тирәнтен өйрәнү белән шөгыльләнүе, мәкаләләр язуы, китаплар, монографияләр бастырып чыгаруы да киләчәккә өмет белән карау мөмкинлеген бирә.

Республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребез әлеге бәйрәмне үзенчәлекле һәм сыйфатлы үткәрүдә ярдәм йөзеннән Татарстаннан килгән белгечләрне шатланып, зурлап каршы ала.

Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты, Мәдәният министрлыгы белән берлектә, төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен Сабан туен оештыручылар һәм режиссерларга Казанда инде сигез ел дәвамында методик семинарлар үткәрә, аудио- һәм видеокассеталарда методик ярдәмлекләр һәм музыкаль материаллар чыгара.

2004 елның апрелендә «Татарча көрәш» дигән Бөтенроссия Федерациясенең төзелүе дә горурлык тудыра. Милли көрәш татарларның борынгы бәйрәме — Сабантуйның төп символы һәм образы булып тора.

Боларның барысы да татар халкы аңында милли карашның гаять көчле яңарышы, кабат кайтуы турында сөйли.

Шулай да татарлар тарихында чорыбызның төп вакыйгасы — 2001 елда үткәрелгән беренче Федераль Сабантуй. Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарларның Федераль милли мәдәни автономиясе канаты астында күчмә символы «Тулпар Ат» булган гомумфедераль бәйрәмнең барлыкка килүе милләтне берләштерүгә яңа бер этәргеч бирде.

Сабантуй бәйрәме шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы үткәргән III Корылтайда (28-29 август, 2002 ел) кешелекнең сөйләм һәм матди булмаган мирасы җәүһәрләре буенча «ЮНЕСКО» исемлегенә кертү өчен номинация сыйфатында тәкъдим ителде.

Федераль Сабан туеның ролен һәм әһәмиятен билгеләгәнче, аның барлыкка килү тарихына кагылып үтәсем һәм татар халкының иң борынгы бәйрәме үсешенең үзгәреш юлын ачыклыйсым, ачасым килә.

САБАНТУЙ (ТАРИХИ ТАМЫРЛАРЫ) КАЙЧАН БАРЛЫККА КИЛГӘН?

Билгеле булганча, Сабантуй — асылда исламга кадәр чор бәйрәме. Димәк, нигезе белән ул — күчмә культура заманыннан килә торган мәдәни мирас.

Төрки халыкларның традицион рухи мәдәнияте формалашуына тәңречелек — борынгы төрки Тәңре культы, Күк һәм Кояш алласына инану һәм табыну гаять зур йогынты ясаган. Бу — Кояш культы, Кояш биоритмнары буенча яшәү. Табигый циклларның үзгәрешен, бер елдан икенчесенә күчүне билгеләүче йолалар болар. Борынгы төрки календарь бәйрәмнәрен игътибар белән өйрәнгәндә, тикшергәндә, аларның табигать ритмнары, кеше эшчәнлеге, кеше организмының биоритмнары белән өзлексез, тыгыз бәйләнештә булуын күрәбез. Нигездә, символларның бербөтен системасы булган әлеге бәйрәмнәр ел циклында чагылыш тапкан тагын да зуррак һәм киңрәк символик системаларга карый. Бу — язгы көн белән төн тигезлеге (Нәүрүз), җәйге кояш торгынлыгы

(Сабантуй (Җыен)), көзге көн белән төн тигезлеге (Сөмбелә), кышкы кояш торгынлыгы (Нардуган).

Төрки-татарларның беренче календарь бәйрәме Нәүрүз. Төрки күзаллаулар буенча яңа ел язгы көн белән төн тигезләшкән вакытта (март ае) башланган. Бу вакыт арасы ел энергиясенең беренче биш элементына: җир, су, металл, агач һәм утка табыну йолаларын башкарганнар. Бу йолалар татар халкының фольклор материалларында, калкулык-үрләрдә учаклар ягу, изге су белән коендыру һәм башкалар рәвешендә бүгенге көнгәчә сакланып калган. Төрки-

Тарихчы галим Д.Шәрәфетдинов архивыннан. 1999 ел.

сырты дип йөртелгән (Көнчыгыш календаре буенча «беренче ай»да).

Төрки-татарларның икенче календарь бәйрәме — Җыен төркиләрнең астрономик күзлектән дөньяга карашында җәйге кояш торгынлыгы датасына туры килгән һәм Кояшның еллык юлының яртысы турындагы күзаллаулар белән тыгыз бәйләнештә булган. Җыен бәйрәмен үткәрү алдыннан борынгы төркиләр 5 көн (атна) дәвамында, тауга күтәрелеп, күк алласы Тәңрегә (Кояшка) корбан китергәннәр һәм табигать татарлар күчмә тормыштан утрак яшәү рәвешенә күчкәннән соң, җир культы, башка йолалардан аермалы буларак, хәтердә корбан бирүнең төп элементы сыйфатында теркәлеп, ныгып калган. Бу инде аграр төс алган бәйрәмгә, ягъни табигатьне уяту һәм җир уңдырышлыгын күтәрүгә багышланган бәйрәм булып киткән, бигрәк тә ул ислам динен кабул иткәннән соң, татарлар аңында «Сабан бәйрәме» — Сабантуй буларак ныклап урын алган. Сабантуйның исламгача эчтәлеге бәрәкәт, байлык иңдерүне, мал-

туарның үрчемен арттыруны, мул иген уңышын сорап, ялварып, Кояшка, Күккә һәм элгәреләрнең рухларына күмәк корбан китерүгә кайтып калган.

Борын заманнарда бу ике «бәйрәм» бер-берсеннән нәрсә белән аерылган соң?

Сабантуй асылда Тәңре һәм үзенең әһәмияте белән Сабантуйдан соң икенче урында торып, асылда җәмгыятьнең социаль-икътисади мәсьәләләрен, беренче чиратта, яңа гаиләләр кору, җир биләмәләре бүлеп бирү, яңа йортлар салу, нәсел башлыгын сайлау һәм башка күп кенә мәсьәләләрне хәл иткән. Җыеннар җиде атна дәвамында үткәрелгән. Бу

М.Шакирҗанов фотосы

элгәреләребез рухлары хөрмәтенә җәйге кояш торгынлыгы алдыннан (иске стиль буенча май ахыры — июнь башы) бергәләп дога кылулар һәм корбан китерү йолалары белән рухны ныгыту вазифасын башкарган. Анда, нәсел дәвамчылары буларак, халыкның бары тик ир-ат өлеше генә катнашкан. Ә хатын-кызлар исә аларны нәсел тавы итәгендә көтеп торган. Гыйбадәттән соң ир-егетләр, тау итәгенә төшеп, җәядән ату, ат ярышлары, билбаулы көрәш һәм башка төр бәйгеләр оештырган.

Җыен, нәсел җыелышы буларак, бәйрәмдә халыкның балигъ булган ир-егетләр өлеше дә, хатын-кызлар өлеше дә катнашкан.

IV йөз ахырына караган Кытай «Вэйшу» елъязмасында күрсәтелгәнчә, борынгы ата-бабаларыбыз ел саен яз җитү белән (иске календарь буенча май ахыры — июнь башы) елга буенда «үз элгәреләренә, күккә, җиргә һәм рухларга корбан китергәннәр һәм, корбан китерүне сылтау итеп, ...барлык көчмә халыкны бергә җыйганнар, дәүләт эшләре турында фикер алышканнар һәм күңел ачу чаралары үткәргәннәр...»

Әлеге чаралар, печән өстенә кадәр үткәрелгән «яшьләрнең күңел ачу уеннары» кебек үк, XIX йөз халкы аңында ныклап берегеп калган.

Барлык бу чаралар Көнчыгыш календаре буенча «бишенче ай»да гамәлгә ашырылган.

Советларның «искелекне җимерү» заманында, җыеннар үткәрү тыелган бер вакытта, татар халкының милли бәйрәме Сабантуй халык традицияләренең барлык функциональ бурычларын һәм халык йолалары символларын үз эченә алган.

В.Туник фотосы

Төрки-татарларның өченче календарь бәйрәме Сөмбелә борынгы төрки астрономик дөньяга караште көзге көн белән төн тигезлегенә (сентябрь аена) туры килә. Халык хәтерендә ул Уңыш бәйрәме буларак сакланып калган. Көнчыгыш календаре буенча «җиденче ай»га карый.

Төрки-татарларның дүртенче календарь бәйрәме Нардуган борынгы төрки астрономик дөньяга караште кышкы кояш торгынлыгына туры килә (декабрь ае). Нардуган бәйрәмендә (иң кыска көн, ә Кояш-Тәңре, борынгы төркиләр күзаллавынча, бик еракка китеп барган вакытта) бөек Тәңренең тиз арада әйләнеп кайтуын сорап ялварганнар. Кояш нурларының кабат кайтуын Кояш кызы Умайның (Хомай) тууына тиңләгәннәр. Көнчыгыш календаре буенча бу «тугызынчы айга, У көненә» туры килгән.

Шулай итеп, борынгы төркиләрнең календарь бәйрәмнәре, эчтәлегенә яраштырып, беренче мәртәбә еллык календарьның нәкъ менә иң мөһим, кискен үзгәрешләр вакытында үткәрелгән. «Беренче ай»дан «тугызынчы ай»га кадәр вакыт арасы шулай ук бала яралу, ана карынында яралгының бала булып җитлегү һәм баланың туу циклын чагылдыра. Борынгы төркиләрдәге бу дөньяви караш

(нәсел тамырларының өзелмичә дәвам итүе), әлеге күренешнең барлыкка килүе илаһилыкка тиңләштерелә.

Ислам дине кабул ителгәннән соң, бу йолалар, гореф-гадәтләр, урта гасырның ярминкә сәүдәсенә бәйле бәйрәм культурасының бер өлешенә әйләнеп, сакраль әһәмиятен югалта. Исламга кадәр булган инанулар бары тик халыкның төрле хорафатлар һәм сынамышлар рәвешендә генә сакланып кала. Төрле календарь бәйрәмнәрне уздырганда, аның мөселманлаштырылуы (күмәк гыйбадәт кылу) белән беррәттән, бәрәкәт, байлык иңдерүне, малтуарның үрчемен арттыруны һәм, мул иген уңышын ялварып сорыйсорый, корбаннар китерүнең борынгы йолалары сакланган. Сүз дә юк, аларның барысы да ислам белән изгеләштерелгән, әмма дин япмасы астында аның архетиплары һәм символлары, халык мәдәниятенең тагын да тирәнрәк катламнары яшеренгән.

Әлеге бәйрәмнәрнең яңа тарихы узган гасырның 30 нчы елларында башланып китте. Ул чакларда Җыен җыю тыелган иде; Сабантуй шулай ук үзгәрешләр кичерде (трансформацияләнде), элеккечә бәйрәм итү юллары ябылды. Аерым бер компромисс, килешү нәтиҗәсендә генә совет хөкүмәте, йолалар, функциональ бурычлар һәм халык традицияләре символларының бер өлешен үзенә алып, Сабан туен бәйрәм итәргә рөхсәт бирергә мәҗбүр булды. Сабантуй бу сыйфатында бүгенге көндә милләт формалашкан чорның «фараз кылынган йоласы», ике бәйрәмнең үзенчәлекле синтезы һәм аларның символик йөкләнеш үрнәге булып тора.

Совет дәүләтенең, татарларның бәйрәм культурасын бөтен комплексында аерым бер идеологик күрсәтмәләргә буйсындыруга гына түгел, Сабантуйның асылын үзгәртүгә дә зур өлеш кертте. Бәйрәм чараларын оештыру, программаларын эшләү катгый регламентлана башлый. Аларны үткәрү партия һәм дәүләт хакимияте органнарының бурычына әйләнә. Сабантуйның асылын спорт һәм идеология-пропаганда чарасына әйләндерүгә омтылышлар булса да, ул татарларның иң борынгы бәйрәме, милләтне туплау һәм бердәмлеген чагылдыруның иң көчле этносоциаль факторларыннан берсе булып, халыкның кабатланмас рухын саклап калды.

XX йөзнең 90 нчы еллары башындагы демократик үзгәрешләр чорында, социаль төзелешнең алышынуы, илдәге иҗтимагый-сәяси хәлнең катлаулануы, милләтара мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе, әхлак нигезләренең кинәт үзгәрүе, какшавы һәм гореф-гадәтләрне яңача бәяләү елларында, традицион дуслык һәм иҗади төзелеш бәйрәме буларак Сабан туен үткәрү кешеләрне культура традицияләре тирәсенә берләштерде. 1990 еллар башында социаль-икътисади хәлнең тотрыксыз булуына да карамастан, җәмәгатьчелек, җирле үзидарә һәм дәүләт хакимияте органнары көче һәм тырышлыгы ярдәмендә Сабантуй, үзенең борынгы халык традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен саклап калып, ел саен үткәрелә торган бөтен халык тантанасы булып китте. Күргәнебезчә, XX йөзнең икенче яртысында Сабантуйның абруе үсте, ул җәелдерелде һәм татарларның милли хәрәкәте тарафыннан шактый югары баскычка күтәрелде. Вакыт узу белән, бәйрәмебез хакимият тарафыннан да актив кабул ителде һәм бүгенге көндә дәүләт һәм гомуммилләт статусы алды.

САБАНТУЙ – БҮГЕНГЕ ТАТАР МИЛЛӘТЕНЕҢ ЭТНОМӘДӘНИ ЙӨЗЕК КАШЫ

Татарларның этник бердәмлеген үзтәңгәлләштерүен өйрәнгәндә, шул ачыкланды: ул берничә дәрәҗәгә бүленгән символлар һәм мәгънәләрнең тулы комплексын тәшкил итә. Бу – халыкның җәмгыяви аңы тупланган биеклек, дәрәҗә. Хәтта җәмгыяви бәйләнешләр кими барган шәһәрләрдә дә билгеле бер якташлыкка карау, «кече Ватан» турында хатирәләр – һәр кешене үз халкы белән бәйләнештә тота торган ныклы җеп ул. Нәкъ менә шуның өчен дә җәмгыяви аңда тамырлары булган бәйрәмнәр җәмгыятьнең барлык әгъзаларын да берләштерү максатына гына хезмәт итеп калмый, хәтта бөтен җәмгыятьне бербөтен милләткә берләштерә. Татарларда халыкның Җыен һәм Сабантуй бәйрәмнәре – нәкъ менә шундыйлар. Алар хәзерге вакытта җәмгыятьнең башка бәйрәмнәренең күпләгән нигез элементларын да үз эченә ала, чын-чынлап бүгенге заман татар милләтенең позитив үзтәңгәлләшүенә уңай йогынты ясый.

Бүгенге көндә Сабантуй – милләтне тәңгәлләштерүдә төп механизмнарның берсе. Ул татар халкының үзаңын һәм мәдәни материалын формалаштыруда гаять зур роль уйный. Сабантуй, милли тәңгәлләштерүнең демонстратив-сайлаулы функциясен (үзтәкъдим) башкарып, татарларны башка милләтләрдән аерып торучы үзенчәлекле мәдәни чик булды.

Татарлар диаспора булып яши торган күп кенә төбәкләрдә нәкъ менә Сабан туен бәйрәм итү аларга татарларның милли мәдәниятенә кушылырга һәм үзенең татар милләтеннән булуын күрсәтергә, расларга мөмкинлек бирә.

Сабантуйны үткәрү республикадан читтәге төбәкләрдә (Россия Федерациясендә, БДБ илләрендә һәм ерак чит илләрдә) үткәрү 1992 елда Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтаен уздырган татарларның иҗтимагый оешмалары җилкәсенә төште. Мондый механизм халык дипломатиясе аша татарларның тупланып яши торган төбәкләренә иминлек һәм тынычлык процессын ныгыту мөмкинлеген бирә.

Бүген әлеге бәйрәм Россия Федерациясенең барлык татар җәмгыятьләре – Калининград шәһәреннән алып Сахалин утравына кадәр, Россиянең 25 ләп төбәгеннән татар милли мәдәни автономияләре, якын һәм ерак чит илләрдән Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Австралия, Болгария, Германия, Канада, Румыния, Финляндия, Швеция, Япония һ.б. илләрнең 80 иҗтимагый оешмасы тарафыннан киң күләмдә үткәрелә.

Бүген дә Сабантуй бәйрәменә нисбәтле заманча һәм тарихи яктан әһәмиятле күренешләр туып тора. Бер үк вакытта үзенең җәмгыяви, якташлык бәйрәме статусын югалтмыйча, ул гомуммилли форум, этниклык һәм тәңгәлләштерү репрезентациясенең аерым формасы статусын ала.

Сабантуй бәйрәмен кабат кайтару һәм трансформацияләүдә уникаль тәҗрибә, вакытлар үтү белән, илнең барлык халкы тарафыннан да бәйрәмчә йолаларның күркәм үрнәге булып кабул ителә башлады. «Гуманизм, мәрхәмәтлелек һәм миһербанлылык идеяләре иңдерелгән Сабантуй йолалары, уеннары һәм бәйгеләре татар халкының милли мирасын саклап калуда гына түгел, ә

бәлки кешеләрне глобаль масштабта толерантлык һәм тынычлык культурасы рухында тәрбияләүдә дә аның ролен көчәйтә».

Өйрәнелгән материаллар татар халкының үзаңын чагылдыра һәм бүгенге көндә Сабантуй милләтнең позитив үзтиңләшү индикаторларының берсе булып хезмәт итә, шуның белән ул этномәдәни системаны формалаштыруда ышанычлы чыганак булып тора. Бу очракта шулай ук Җыен кебек борынгы бәйрәмнәрнең спорт һәм культурология рәвешендәге төренә функциональ сыйфатларны теркәү генә түгел, ә бәлки яңа шартларда әлеге процессларның сәяси төсмерен дә исәпкә алу урынлы булыр.

Мәсәлән, Россия тарихында 1996 елда Россия Федерациясе Президенты Б.Н.Ельцин Татарстан Республикасының Арча шәһәрендә уздырылган Сабан туенда катнашты. Аны Президент М.Ш.Шәймиев озатып йөрде. 2001 елда шундый ук «батырлыкны» Россиянең икенче Президенты В.В.Путин да эшләде. Алар милли бәйрәмдә катнашып кына калмыйча, Сабантуй ярышларының аерым төрләрендә үзләрен сынап карадылар. Россия җитәкчеләренең милли бәйрәмебезгә шундый киң күңеле һәм якты мөнәсәбәте Россия киңлекләрендә әлеге борынгы бәйрәмнең тиңләштерү ролен тагын бер мәртәбә ачык күрсәтә.

Бу турыда Д.Шәрәфетдинов менә ничек язган иде: «Моңа ачык раслама — Татарстанда яшәүче барлык милләт кешеләре өчен чын мәгънәсендә бәйрәмгә әйләнгән Сабантуй. Бу фактны аеруча ассызыклап үтәсе килә, чөнки безнең Сабантуй татар белән русның, чуваш белән удмуртның һәм башка милләт кешеләренең бердәмлеген чагылдыра. Татар халкының иң яхшы традицияләрен саклап калып, ул бүгенге көндә Татарстан Республикасының башка халыкларына да хас булган үзенчәлекләрне үзенә алды. Бу мәгънәсендә ул төрле милләтләрнең чын-чынлап килешеп яшәү һәм дуслык бәйрәменә әйләнде. Күптәннән әйтелгән бит: «Сабантуй — дуслык бәйрәме».

ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ — БҮГЕНГЕ КӨН

Бүгенге көндә милли бәйрәмебез үсешенең иң биек баскычында. Ул — 2001 елдан Россия татарларының төбәк милли мәдәни автономияләре тарафыннан уздырыла торган «Гомумфедераль Сабантуй». Мондый Сабантуйларның беренчесе Татарларның федераль милли мәдәни автономияләре советы (1998 елда гамәлгә куела) карамагында Саратов өлкәсендә, Саратов шәһәренең үзәк паркында булды. Гомумфедераль Сабантуйда Ульян, Саратов, Оренбург, Волгоград, Иваново, Төмән, Түбән Новгород өлкәләрендә яшәүче татарларның милли-мәдәни мохтәрияте советы төркемнәре, Мордовия һәм Татарстан республикалары вакилләре катнашты. 2002 елда күчмә гомумфедераль Сабантуйны үткәрүне Самара өлкәсе үз өстенә алды.

Тольятти татарларының шәһәр милли-мәдәни мохтәрияте әлеге бәйрәмне олы теләк белән, югары дәрәҗәдә оештырды. Бу бәйрәмгә, Саратов шәһәрендәге кебек үк, шушы шәһәрдә яшәүче төрле милләт кешеләре кунак итеп чакырылды. Самара өлкәсендә Татарларның милли-мәдәни мохтәрияте төбәкләрдән катнашучылар санын икеләтә арттырды. «Сабантуй — 2002» батыры

ачыкланганнан соң, гомумфедераль Сабантуйның күчмә символ-туграсы «Тулпар Ат» беренче мәртәбә тантаналы шартларда Тольятти шәһәре татарларының милли-мәдәни мохтәрияте рәисе Д.Вәлиуллин һәм Ульян өлкәсе татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе А.Курчаков кулына тапшырылды.

Бронзадан эшләнгән (биеклеге — 50 см тирәсе) «Тулпар Ат» сыны бүгенге көндә Россия татарларының милли-мәдәни мохтәрияте оештыра торган гомумфедераль Сабантуйның күчмә символ-туграсы булды.

2003 елда гомумфедераль Сабантуй татарларның милли-мәдәни мохтәрияте вәкилләрен Ульян өлкәсенең Димитровград шәһәренә җыйды. 2004 елда исә ул Йошкар-Олада (Мари Эл Республикасы), 2005 елда — Түбән Новгородта, 2006 елда — Саранскида (Мордовия Республикасы), 2007 елда — Чиләбедә, 2008 елда — Әстерхан шәһәрендә, 2009 елда — Ульянда, 2010 елда — Ижау шәһәрендә (Удмуртия Республикасы), 2011 елда Екатеринбургта (Свердловск өлкәсе) үткәрелде. Быел исә федераль Сабантуй Ерак Көнчыгышның Владивосток шәһәрендә үтә.

Гомумфедераль Сабантуйны үткәрү өчен нигез булып ТР Министрлар Кабинеты белән Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты, Татар федераль милли-мәдәни мохтәрияте советы арасында 1999

елның 4 июнендә кул куелган мәдәни, икътисади һәм фәнни хезмәттәшлек турындагы килешү тора. Әлеге юридик документ нигезендә Татарстан Республикасын татар халкы тупланып яши торган төбәкләр белән бәйләнешә торган җепләр ныгытылды. Бу процесс, 2002 елда ТР Конституциясенең яңа басмасында «Татарстан Республикасының республикадан читтә яшәүче татарларга ярдәм итүе турында» дип аталган 14 нче маддәсе барлыкка килгәч, тагын да көчәйде.

Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм аларның органнары арасында ике якка да караган эш башкару предметларын чикләү һәм вәкаләтләрне үзара тапшырышу турында»гы Шартнамәсе законга кертелү бу процессны федераль дәрәҗәдә ныгытты.

Федераль Сабантуй кысаларында 2009 елда (Ульян шәһәрендә) беренче мәртәбә урта һәм кече эшмәкәрлек «Татарстан» сәүдә йортлары, Татарстан Республикасы һәм Ульян өлкәсе предприятиеләре вәкилләре катнашында «Татар базары» дигән күргәзмә-ярминкә оештырылды. Икътисади юнәлешнең барлыкка килүе Татарстан Республикасында җитештерелә торган продукциясе бөтен Россия Федерациясе буенча татарларның тупланып яши торган төбәкләренә кертү һәм сатуның яңа мөмкинлекләрен ача. «Татар базары» дигән күргәзмә-ярминкәләр моңа расламa.

Гомумфедераль Сабантуй бүгенге көндә татарларның халык бәйрәме булып санала һәм, югарыда әйтелгәнчә, ул Евразия киңлеген биләгән байтак халыклар менталитетын да берләштерә, мәдәни башлангыч булып тора. Моның белән бергә ул — татарның үзтәңгәлләшү символы, татар халкының борынгы йолаларын, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен һәм телен саклауда билгеләүче факторларның берсе, аның рухи бергәлеге булып торды һәм шулай кала бирә.

Бөтен тарихи үсеш чорында Сабантуй бәйрәме татарлар арасында күп гасырлар буе Исламның һәм мөселман кыйммәтләренең, ә совет чорында сыйнфый-атеистик идеологиянең өстенлекле булуына да карамастан, халыкның бәйрәм итү табигатен саклап кала алды.

Сабантуй — татарның традицион культурасының, шулай ук күпмилләтле Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясенең тулаем халкы культурасының аерылгысыз һәм табигый элементы ул. Сабантуй сүзенең мәгънәви семантикасы рус һәм Россиянең башка халыклары телләренә ныклап кереп урнашты, тәрҗемәне дә таләп итми.

Федераль Сабантуйның үзенчәлеге иң әүвәл татар халкының рухи һәм матди культурасын саклау, үстерү өчен җанлы культура традицияләрен гамәлгә ашыручы буларак башкарган вазифасында һәм әһәмиятендә чагыла. Бу — этник туплану һәм мәдәни тәңгәлләшүнең төп факторларыннан берсе булып сакланып калган халык бәйрәме.

Шулай итеп, Сабантуй нәселкабилә һәм җәмгыяви бәйрәмнән татар милләтен берләштергән, туплаган, дөньякүләм этномәдәни чикләрне билгеләгән гомуммилләт спорт-мәдәни форум дәрәҗәсенә кадәр әһәмиятле үсеш юлы үтте.

5 июнь, 2012 ел

Р.Әхмәтов фотосы

САБАН ТУЕНДА

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ

Сабан туе бүген. Авылыбызга
Йөзләп кунак кайткан бер көнгә.
Җырлый-җырлый бергә бөтенебез
Тауга күтәрелдек — иркенгә.

Дус-ишләрне күрү шатлыгыннан
Барлый алмаганбыз барсын да:
Батыр калган тимер тәнле егет
Батыр түгел икән асылда.

Егет батыр калгач, яшь-җилкенчәк
Күккә чөйгән иде батырны —
Агай әйтеп куйды: «Бу батырга
Алыштырмас идем атымны.

Ә ул алыштырды, ташлап китте
Иген үскән туган туфрагын.
Минем йөзне балам акламады...
Нәрсә диеп әйтим мин тагын!

Әй, иманың бер яңартыйм!» —
диеп, Алып батыр сыман кузгалды;
Кулга тотып чиккән сөлгене, ул
Мәйдан уртасына юл алды.

Көрәшне ул яңабаштан шулай
Башлады, йә, монда кем хаклы?
«Мә, таны, — дип, — җирне!» —
җиргә бәрде
Ул үз улын — тансык кунакны.

Р.Якупов фотосы

КАТЫКТАН АКЧА ЭЗЛӘҮ

ЗИННУР МАНСУРОВ

Хак түгелме: безнең куллар
эшли авыз өчен дә.
Авызга кул ярдәм итми
бары катык эчендә.

Кирәк чакта сандугачтай
сайрасын һәм кош тотсын, —
әйтү башка — эшләү башка —
авыз шуңа төшенсен.

...Тәлинкәсе бигрәк тирән,
ә катыгы ап-ачы...
Авызыңа керәм, диеп
тормый икән акчасы.

Ачы хаклык шикелле ул,
Өскә чыкмый тиз генә.
Ә катыкта акча тәмен
Авыз шундук сизенә.

Әйдә, авыз бер мәртәбә
Үзе эшләп ашасын...
Ни әйтәсең икән, халкым,
шушы уен аша син?..

ҖЫЕННАР

(БҮГЕНГЕ САБАН ТУЕНА МӨНӘСӘБӘТ ИЛӘ)

Закир. («Тормыш» газетасы, 29 май, 1916 ел).

Йөгерештә җиңүчеләр. Пермь губернасы Шадрин өязе Сабан туенда. XX гасыр башы. Татарлар. Рус этнография музее архивыннан.

ҺӘР МИЛЛӘТНЕҢ ҮЗЕНӘ МАХСУС ГАДӘТ-ҖОЛАЛАРЫ [ЙОЛА] ВӘ МИЛЛИ ГАНГАНӘЛӘРЕ [ТЕЛДӘН ТЕЛГӘ КҮЧЕП ЙӨРҮЧЕ СҮЗЛӘР] БАР. БОЛАР ШУЛ МИЛЛӘТЛӘРНЕҢ РУХАНИ ХИСЛӘРЕН, ДИНИ ВӘ ӘДӘБИ ТӘРБИЯЛӘРЕН КҮЗ АЛДЫНА КИТЕРЕП КУЯЛАР.

Милли йола, милли гадәт кебек, инсаннарның [кеше] рухани хәлләрен, мазыйларын [үткәннәр] күз алдында гәүдәләндерелгән икенче бер нәрсәне табып алуда бик мәшгуль булса кирәк. Милли җолалар гасырлар вә заманнар үтүе белән төрле үзгәрешләргә мәгъруз [күз алдына куелган] калсалар да, алар милләтнең бик озакта калган мазыйсын, аның рухани, хәтта иҗтимагый әхвален ачып бирү вазифасын үти.

Без — татар кавеме, дөньяның төрле ягына таралып, борынгы уртак булган гадәт вә җолаларымыздан байтагысын югалткан вә оныткан булсак та, гасырлар вә бик күп заманнар үтүенә карамастан, бәгъзе бер җолаларымыз һаман да сакланып киләләр. Шуларның берсе — бер дә шөбһәсез, эчке Русиядә яшәгән татар кавеме арасында «Җыен», Төркестан, Иран вә кечкенә Азиядәге төркиләр эчендә «Нәүрүз бәйрәме» вә «Хәмәл [зодиак тамгалары буенча 22 марттан 22 апрельгә кадәр була торган вакыт арасы] бәйрәме» кебек төрле исемнәр белән исемләнгән җыеннарымыздыр.

Бу җыеннарымыз гаять борынгы бер җоламыз булып, моның иске төрекләрнең диннәре вә рухани тәрбияләре белән дә мөнәсәбәте бик зурдыр.

Бу җыеннарның кышның зәмһәрир кебек салкыннары үтеп, бәһар [яз] — яз мөсәмма [исемләнгән, аталган] кебек табигатьнең нурлар чәчкән вакытына тугры килүе «Диннәр тарихы» һәм әсатыйр [мифик] мифология язучылар өчен бик киң бер зәмин [җирлек] хәзерләгән. Алар бу мөнәсәбәт белән бик киң дини тәхкыйкларга [хакыйкать эзләү] керешеп, бу җыеннарның кыш мөсәмма бетеп, кояш нуры бөтен йир йөзенә хәят биргән заманга тугры килүеннән, аларның алиһәләр хакындагы фикерләрен тәгаен итәргә телиләр.

Кыш, салкын һава, буран. Болар барысы да бәни бәшәргә [адәм балалары] начар тәэсир итәләр. Болардан зарланмаган, сызланмаган бер кеше дә юк. Кыш йир йөзендәге хәят иясе булган күп нәрсәләрне, шул җөмләдән үләннәрне, чәчкәләрне үлтерә, матур яланнарны, урманнарны кар-буран астында калдыра. Борынгы вә хәзерге күчмә халыклар кышның бу зарбәләреннән [зыян] утраклашкан халыкка караганда артыграк зарарланганнар вә зарарланалар. Алар менә шундый сәбәпләр өчен табигатьнең кыштагы начар тәҗәллиятенә [чагылыш] «Шәр [явызлык] алиһәсе — бозыклыкны яратучы тәңре»нең эше дип караганнар. Табигать матурланып, йир йөзендә хәят башлануга, алар «Җир алиһәсе — изгелек тәңре»сенең табигатьтәге тәҗәллияте булуына ышанганнар. Бу галимнәр борынгы төрекләрнең «Нәүрүз» вә «Хәмәл» бәйрәмнәрендә һәм безнең бик искедән килгән «Са-

Муллалар төркеме. Пермь губернасы Шадрин өязе Сабан туенда. XX гасыр башы. Татарлар. Рус этнография музее архивыннан.

бан туе» вә «Җыен» кебек җыелышларымызда да шуны күрергә телиләр. Борынгы төрекләрдә табигыятькә вә аның төрле мөсәммасындагы алмашынуларына гыйбадәт итү булганын исбат итмәкче булалар.

Милли җолалар гасырлар вә заманнар үтүе белән төрле үзгәрешләргә мәгъруз калсалар да, алар милләтнең бик озакта калган үткәнен, аның рухани, хәтта иҗтимагый әхвален ачып бирү вазифасын үти.

Ләкин хәзер — исламият арамыздан таралганнан соң, бу игътикад [ышану] бетеп, җыеннарымыз, «Нәүрүз» вә «Хәмәл» бәйрәмнәре милли бер җола булып калганнар. Шәрекътә табигатьнең сафлыгы, матурлыгы март 8-9 ыннан игътибарә башланганга, анда бу бәйрәмнәр безгә караганда иртәрәк булып үтәдер. Төркестан белән Бохараларда март 8 ендә, Иранда 9 ында башланып, берничә көн дәвам итә. Бездә матур яз соңрак килгәнгә, Сабан туе, җыеннар, урынына карап, апрель, май, хәтта июнь ахырларына кадәрле сузылалар.

Халык, гаммә [масса] авылларда яшәгәнгә, бу җыеннар безнең халкыбызның борыннан калган байтак җола вә гадәтләрен күз алдына китерәләр. Иҗтимагыятемезнең ни дәрәҗәдә булганын да бик ачык итеп күрсәтү хезмәтен үтиләр.

Бу җыеннарымыздагы динилек әсәре хәзер тәмам югалып, алар инде фәкать милли бер бәйрәм генә булып калганнар. Бу

җыеннарымыз халык өчен күрешү, белешү һәм танышуга сәбәп булу ягыннан гына түгел, күңел ачу, уйнау, көлү, җырлау, көч сынашу, атлар узыштыру ягыннан да бик мөһимдер.

Инсан бертөрле хәяттан туя, хәтта боега. Аның катнашасы, аралашасы килә. Көчен, куәтен башкаларга күрсәтергә тели. Күңелдәге аһ вә зарларыннан берничә сәгатькә генә булса да, бушануны арзу итә. Менә безнең Җыен вә сабантуйларымыз халкымыз өчен шул хезмәтне тәмамы белән үтиләр.

Җыеннарымыз халык өчен күрешү, белешү һәм танышуга сәбәп булу ягыннан гына түгел, күңел ачу, уйнау, көлү, җырлау, көч сынашу, атлар узыштыру ягыннан да бик мөһимдер.

Ләкин бу милли җыелышларымыз борынгы хәлгә караганда бик нык үзгәргәннәр. Мәшһүр акын (җырчылар вә шагыйрьләр) тарафыннан шигырь әйтешү вә җырлашулар хәзерге көндә беткән. Дөрес, башкортлар арасында аз-маз «акыннар» бар. Алар җыеннарда үзләре чыгарган шигырь вә җырларны укыйлар. Ләкин күбесе мәгънәсез, мөнәсәбәтсез була. Әүвәлдә безнең бу «Сабан туе» һәм «Җыен»нарымыз гарәпләрнең «Гыйказ», «Сәхәр»ләре кебек әдәбият мәҗлесләре хезмәтен дә үтәгән булсалар кирәк. Гарәп шагыйрь вә әдипләре шул базарларда үзләренең шигырьләрен халыкка укып, әдәбият мәйданында узышкан кебек, безнең «акын»нарымыз да үз һөнәрләрен күрсәткәннәрдер.

Хәзерге көндә цирклар, әдәбиятта узышырга газета-журналлар хезмәт итсәләр дә, борынгы заманнарда болар матур яланнарда, юнанлылар кебек мәдәнирәк булганнарында махсус ясалган биналарда иҗраэ [үтәү] ителгән юнаниларның «жимназиюм»нары, төрле тән көче сынашу өстенә, фәйләсүфләр вә хакимнәре өчен төрле мәүзугъларда [тема, сюжет] мөназара мәйданы булу вазифасын да үтәгән. Анда аларның галимнәре вә шәкертләре фикере куәтләрен дә сынашканнар. Безнең сабантуйларымызда да моннан берничә еллар элек хәзрәт вә төрле мәдрәсә шәкертләре юнанилардан алынган схоластикага гаид төрле мәүзугъларда мөзаккәрә итешәләр иде. Шул җәһәттән безнең җыеннар белән борынгы юнаниларның «жимназиюм»нары арасында бик зур мөнәсәбәт булган була.

Хәзер дә безнең бу җыеннарымыз мәдрәсәдә бергә укыган гасырдаш хәзрәт вә имамнар һәм шәкертләргә бер-берсе берлән күрешергә васитачылык [арадашчы] итә. Алар, җыеннар вә сабантуйлар мөнәсәбәте илә елында бер мәртәбә булса да

бергә җыелышып, аһ вә зарларын, кайгы вә хәсрәтләрен бүлешәләр. Төрле авыл халыклары да шул мөнәсәбәт белән дус вә кардәшләрен зиярәт итәләр. Яшь килен төшерүләр, кода-кодача сыйлашулар да шул вакытта тугры китеребрәк эшләнәдер. Җыен вә Сабан туе вакытларында авыл тантаналы бер милли бәйрәм төсенә керә һәм, башка дини бәйрәмнәргә караганда, милли Сабан туе вә җыеннар тантаналырак итеп үткәреләдер.

Уфа, Пермь, Оренбург губерналарының бер кыйсмендә [өлеш] мәшһүр Сабан туе вә җыеннар өстенә, кар эреп, йир йөзе ачылганда — «Тауга чыгу», тал яфрак яргандa — «Талга чыгу», ике сука арасында бер авылның тирә-күршеләре башка авылларны «Карга боткасы»на чакыруы кебек төрле исем белән исемләнгән җыелышлар да була. Боларның барысының да үзенә күрә азмы-күпме әһәмияте бар.

Уфа тирәсендәге җыеннар эчендә Кара Ягъкуб җыены аерым бер урын тота. Анда башкортларның борынгы җолаларыннан байтагысы күз алдына киләдер. Дим елгасының уң ягына салынган гүзәл манзаралы бу авыл җыенында байтак башкорт хатыннарын моннан берничә йөз ел элек кигән киемнәрендә күрергә мөмкин. Җыенга чыкканда, башкорт ханымнары башларына кашмау, аякларына көмешләгән биек үкчәле каталарын, өсләренә тәңкә тезгән бишмәтләрен кияләр вә үзләренең борынгы хәлләрен күз алдына китереп куялар. Боларны күрү күңелдә бик зур эз вә тәэсир калдырадыр.

Соңгы ун ел эчендә аз да булса мәдәниятемез вә милли тойгыларымыз үскәнгә, сабантуйларымыз да үсә вә тәрәкъкый итә башлады. Гадәттә сабантуйларымызда булмый торган төрле уеннар арттырылды. Милли вә дини ихтыярларымыз өчен дә сабантуйлары васитаителә башлады. Уфа, Оренбург, Чиләбе вә башка мөселман җәмгыяте хәйрияләре сабантуйларын, үз идарәләренә алып, тәртипле бер рәвешкә куйдылар вә бу саядә [күләгә, ышык] хәйрат юлына байтак кына микъдарда акча җыяр өчен яңа юл да ачылды. Милли бу җоламыз үстерелеп, аның хәйрат юлына васита булуына, әлбәттә, без бик шатланамыз.

Закир Кадыйри мәкаләсен басмага
Айгөл Латыйпова әзерләде.

КАЗАНДА ҮТӘ ТОРГАН САБАНТУЙ БӘЙРӘМЕ – XIX ГАСЫР
РУС ГАЗЕТАЛАРЫ БИТЛӘРЕНДӘ

ТАТАРЛАРНЫҢ «САБАН» БӘЙРӘМЕ ТУРЫНДА

[…] Килүчеләрнең, бигрәк тә Мәскәү кунакларының, игътибары татарларның Сабан бәйрәменә юнәлтелә. Татарча аны «Сабантуй», диләр (туй — бәйрәм). Аның хакында берничә сүз язсак, бәлки, кемнәргәдер кызык булыр.

Ул татар авылларында кар эреп беткәч, җирне сукалау алдыннан уза. Җир сөрә торган коралны татарлар сабан дип атыйлар, күрәсең, бәйрәм исеме шуннан килеп чыккан. Монда, Казанда, ул май башында була. Быел 7-сеннән 12 майга кадәр Казаннан өч яки дүрт чакрым ераклыкта, Татар бистәсе артында, болынлыкның куаклы өлешендә оештырдылар. Татарлар гаиләләре белән шунда кибиткаларда киләләр һәм үзләренчә кәеф-сафа коралар: аерым (ирләр һәм хатын-кызар өчен) ясалган түгәрәкләрдә көрәш, аннары юл буйлап йөгерү һәм ат чабышы күзәтелә, аларда җиңүчеләр, Олимпия уеннарындагы кебек, үз ишләреннән күз төшәрлек булмаган бүләкләр кабул итә. Монда Казан җәмәгатьчелеген тәшкил иткән халыкның күп булуын әйтергә кирәк. Күрәсең, алар бу тамашадан рәхәт таба: көненә килүче кареталарның саны гына да 200-гә җитә, диләр.

Ислам дине кануннарында мондый бәйрәм каралмаган һәм дингә аның бернинди кагылышы юк. Кайбер татар укымышлылары (муллалар), абызлар (поплар) һәм ахуннар (протопоплар яки архимандритлар) моны билгеләп үтү кирәк түгел, чөнки бу хакта Коръәндә берни язылмаган, диләр. Аннары, бәйрәм аларга мәҗүсилектән



КАЗАНСКІЯ ИЗВѢСТІЯ.

№ 19.

(Суббота, Маія 10 го дня, 1813 года.)

Санктпетербургъ, 3 Апрѣля.

Въ слѣдствіе сдѣланнаго извѣщенія по Киренскому уѣзду въ Иркутской Губерніи, о предположенномъ Киренскими гражданами заведеніи училища, нѣкоторыхъ селеній крестьянскія общества, желая обучать въ ономъ училищѣ дѣтей своихъ, добровольно взнесли на покупку для училища дома: Орленскіе 31 руб. 25 к. Витимскіе 92 руб. Нижнеилимскіе 337 руб. 95 к. Подкаменскіе 250 руб. 65 к. Макаровскіе 216 руб.; а всего 927 р. 85 к. Деньги сіи препровождены въ Киренскую Ратушу.

Радзивиловъ, 29 Марта.

Сюда прибыли сего дня два чиновника изъ Лемберга, отправленные тамошнимъ Губернаторомъ, по повелѣнію Его Величества, Австрійскаго Императора, для встрѣчи Государыни Великой Княгини Екатерины Павловны. Сіи чиновники Баронъ Дюке и Баронъ Эмбъ, по прибытіи сюда сказывали, что для принятія Ея Императорскаго Высочества готовятся въ Австрійскихъ владѣніяхъ всевозможныя почести, встрѣчи и все, что для спокойства и пріятности въ путешествіи нужно; а имъ обоимъ поручено узнать, какимъ образомъ и по скольку миль въ день изволитъ Ея Высочество путешествовать, намѣревается ли гдѣ останавливаться, и не угодно ли Ей будетъ осматривать достойные примѣчанія соляные заводы въ Бохнѣ и Величкѣ?—Оба чиновника сіи, перемѣнивъ здѣсь почтовыхъ лошадей, отправились немѣдленно отсюда по тракту чрезъ Дубно до Житомира на встрѣчу Ея Высочеству.

Отправленные Австрійскіе чиновники встрѣтили Ея Императорское Высочество Волынской Губерніи въ городѣ Острогѣ. 31 го Марта въ шестомъ часу изволила прибыть сюда въ вожделѣнномъ здравіи сія знаменитая путешественница въ сопровожденіи управляющаго означенною Губерніею Гна. Тайнаго Со-

калган кебек тә тоела. Моның белән килешергә дә буладыр. Татарлар күчмә халык булганнар, җир эшкәртмәгәннәр. Казан һәм башка губерналарда яшәүче халыкларның күбесендә моңа охшаш бәйрәмнәр бар... Мондый бәйрәмнәрдәге уеннар һәм башка кайбер үзенчәлекләр аларда христианлык, ислам һәм мәҗүсилек катнашканы турында сөйли.

Татарларга Сабан бәйрәменең каян үтеп кергәнлеген әйтү кыен. Бәлки, чыннан да, ул мәҗүсиләрдән киләдер, аларда бу йола бик күптәннән билгеле бит. Моның хакында башка урында сөйләшү дөресрәк булыр. Мондагы татарлар бәйрәм борынгы-



(4)

языкомъ 80, 70, 60 к. ноги съ губою 60, 50, 40 к. рубецъ 35, 25, 15 к. пара почекъ 25, 20, 15 к.; гусакъ съ печенью 80, 70, 60 к. баранины задн. мѣс. 15, 12, 10 к. фун. передн. 10, 9, 8 к. солонины задн. мѣста 10, 9, 8 коп. фунтъ, передн. 9, 8, 7 коп. гусакъ бараній съ грудиною и сальникомъ 80, 70, 60 к. свинины 15, 14, 13 к. фунтъ. *Рыбная*: Судаковъ и лещей ф. по 15, 14, 12 к. щукъ крупныхъ 13, 12, 11 к. мѣлкихъ 11, 10, 9 к. Судаковъ вялыхъ 9, 8, 7 к. ф. Сазанины 10, 8, 7 к. Икры паюсной ф. 70, 60 к. зернистой 60, 50 к. *Хлѣбная и другихъ припасовъ*: Четверть въ 8 четвериковъ овса 6 р. 40 к. и 6 р. гороху 22 р. и 21 р. крупъ полбеныхъ 23 р. и 22 р. просяныхъ 40 р. и 38 р. Пудъ пшеничной муки 2 р. 40 к. и 2 р. 30 к. ржаной 1 р. 20 и 1 р. 10 к. Хлѣба фунтъ изъ ржаной муки 2½ к. калачи и сайки 9 к. и 8 к. Масла коровьяго фунтъ 45 к. и 40 к. конопляннаго 26 к. льнянаго 25 к. пудъ липовца меду 28 р. штофъ молока 15 к. яицъ десятокъ 15 и 12 к. Уксусу пивнаго штофъ 15 к. мыла простаго пудъ 10 р. и 9 р. 50 к. свѣчь маканыхъ и литыхъ пудъ 12 р. и 11 р. 50 к. Ведро сѣрой капусты 25 к. Сажень дровъ однополенныхъ въ аршинъ березовыхъ 3 р. и 2 р. 50 к. осиновыхъ 2 р. 50 к. Сѣна 80 к. и 70 к.

Лаишевъ, отъ 9 го Маія.

Въ Камѣ съ 26 Апрѣля по 9 Маія прибыло воды на 1 аршинъ 10½ вершковъ.

Казань 12 Маія.

Здѣшній помѣщикъ и разныхъ ученыхъ обществъ членъ Д. Н. Зиновьевъ, извѣстный по многимъ своимъ полезнымъ занятіямъ по части Россійскаго сельскаго домоводства, желая распространить красильное растѣніе вайды (Isatis tinctoria), предлагаетъ нынѣ Казанской публикѣ для посѣва семена оной, кои всякой можетъ получить безденежно въ домѣ его, состоящемъ въ Армянской улицѣ, отъ садовника его Артемія Иванова. Описаніе Вайды, посѣва и разведенія оной находится въ 14 номерѣ Каз. Изв. 1811 года. Г. Зиновьевъ кромѣ того съ удовольствіемъ берется объяснить желающимъ, даже письменно, способъ извлекать изъ листовъ вайды синюю краску, подобную кубовой.

Казань, 16 Маія.

Разливъ воды нынѣ былъ не большой и увеселенія во время онаго противъ прежнихъ лѣтъ гораздо меньшія. Казань уподобляется приморскому городу, почти съ трехъ сторонъ окружается водою и лежитъ какъ бы на полуостровѣ. Остающіяся не занятыми возвышенія составляютъ островки, служащіе мѣстомъ для пріятнаго на нихъ иногда времяпрепровожденія; по вечерамъ, особенно въ праздничные дни, многіе обществами катаются по водѣ съ пѣснями, музыкою и ружейною или пушечною пальбою: нынѣ сіе не столь было примѣтно.

Большое вниманіе, преимущественно пріѣзжихъ изъ Москвы, обращено было на Татарской праздникъ *Сабанъ*, по Татарски называемый



(5)

Сабанъ Туи, (Туи — праздникъ). Можетъ быть для нѣкоторыхъ будетъ любопытно знать о немъ нѣчто и для того скажется о томъ здѣсь нѣсколько словъ. —— Оный бываетъ въ Татарскихъ деревняхъ вскорѣ по стаяніи снѣга предъ распахиваніемъ земли и поелику орудіе, коимъ Татара пашутъ, именуется Сабаномъ, то и праздникъ вѣроятно отъ того получилъ свое названіе. Здѣсь въ Казани онъ происходитъ въ началѣ Маія. Нынѣ продолжался съ 7 до 12 Маія въ трехъ или четырехъ верстахъ отъ Казани за Татарскою слободою на лугу къ кустарникамъ. Туда пріѣзжали Татара съ семействами въ кибиткахъ и особо пиршествовали всякъ по своему состоянію; въ составленномъ ими (мущинами, женщины были въ отдаленіи) кругу происходила борьба, также послѣ того по дорогѣ бѣганіе и конская скачка, побѣдители на сихъ нѣкоторыхъ подобіяхъ Олимпійскимъ играмъ получали неважныя награды отъ своихъ единовѣрцовъ. Съѣздъ сюда особъ, составляющихъ нынѣ Казанскую публику, былъ довольно большой и многіе имѣя для себя новымъ сіе зрѣлище, вѣроятно находили въ томъ удовольствіе; однѣхъ каретъ, говорятъ, пріѣзжало въ день до 200.

Праздника сего закономъ Магометанскимъ не положено и ничего касательно вѣры онъ не составляетъ. Нѣкоторые изъ Татарскихъ ученыхъ (муллъ), Абызовъ (поповъ) и Ахуновъ (протопоповъ или Архимандритовъ) думаютъ, что онаго отправлять не слѣдуетъ: ибо о немъ въ Алкоранѣ ничего не сказано, да и кромѣ того онъ кажется имъ языческимъ. Въ семъ вѣроятно и можно согласиться. Татары бывъ народомъ кочевымъ, не имѣли хлѣбопашества. Живущіе въ Казанской и другихъ Губерніяхъ народы имѣютъ многіе подобные сему праздники. У нѣкоторыхъ Черемисъ большой праздникъ *Анга-Соаренъ* бываетъ въ полѣ весною предъ распахиваніемъ земли; кромѣ того — *жатвенный праздникъ* (Уткинде-Байрамъ (Байрамъ по Тат. праздникъ). У Чувашъ — *Именъ Байрамъ* весною, *Кереметь Тасадосъ* (очищеніе Кереметя) — весноюже, когда начинаютъ пахать поле. У Мордвы весноюже бываетъ *Кереметный праздникъ*, на которомъ приносили звѣрей въ жертву; *полевый праздникъ* (У Ерзянъ — Валкъ Осксъ, а у Мокшанъ Велъ Осксъ) препровождаютъ оба пола въ полѣ. Вотяки имѣютъ Кереметный праздникъ — *Кереметь Нуналь* по окончаніи жатвы; праздникъ *Акетка* — въ лѣтней и для богомолья только назначенной избѣ (Будшикъ Коала), каковые находятся большею частію близь лѣсовъ, происходитъ на страстной недѣлѣ; вскорѣ послѣ того бываютъ у нихъ также праздники домашнія и одинъ изъ сихъ лѣтній большой. У Вогуличей — въ первый день пасхи — *Елбола* называется праздникомъ сошествія Божія (т. е. по ихъ смыслу весны); за тѣмъ чрезъ мѣсяцъ другой праздникъ *Анкобъ*. Обряды при сихъ празднествахъ и другія нѣкоторыя обстоятельства показываютъ, что праздники сіи имѣютъ въ себѣ смѣ-

дан килә дип саныйлар. Казан тарихы [1] буенча да шулай күренә. Әйтик, 1508 елны Казанда шушы вакытта Арча кырындагы зур болында бик күңелле бәйрәм уздырылуы (бәлки, ул шушы Сабан булгандыр, ләкин хәзер татарлар бәйрәмгә кагылышлы бу мәгълүматтан бихәбәр), Казанга килгән рус гаскәренең бәйрәм белән мәшгуль татарларны кыйнавы хакында теркәлеп калган. Күп кенә татарлар хәзер дә бәйрәм элек Арча кырында уздырылган, монда руслар үзләренең кәеф-сафа кору урынын тапкач, башка урынга күчкән, югыйсә һаман да шушында оештырылыр иде дип саныйлар.

«Казанские известия» газетасы,
10 май, 1813 ел

1. Сүз билгесез авторның XVI йөзнең икенче яртысында язылган публицистик, тарихи һәм әдәби эчтәлектәге «Казанская история. Новое сказание, вкратце повествующее о начале Казанского царства, и о войнах с Казанскими царями Великих Московских князей, и о победах их, и о взятии Казанского царства» исемле хезмәте турында бара.

***

Борынгы заманнарда татарлар Сабан бәйрәмен Арча кырында уздырганнар, чиста һавада ачык өстәл корып, бәйрәмгә килүчеләрнең барысын да сыйлаганнар. Шуңа бу Туй дип аталган. Ләкин русларның көче һәм йогынтысы арткан саен, бу йола югала барган.

«Казанские известия» газетасы, 6 июнь, 1814 ел

Мусульманскій міръ.

Вчера начался мусульманскій „сабанъ“ за заводомъ Крестовниковыхъ. Какъ и въ прежніе годы, на сабанѣ будутъ происходить состязанія въ бѣгѣ верховыхъ лошадей, бѣганье въ перегонку съ призами, борьба мѣстныхъ любителей—силачей и т. д. На громадной площади, занятой балаганами торговцевъ разной снѣдью и дешевыми сластями ежедневно на время этого гулянья перебываютъ десятки тысячъ мусульманскаго и русскаго населенія города и окрестныхъ деревень. Сабанъ продолжится до 23 мая. Старостой на сабанѣ состоитъ Х. Рахманкуловъ.

МӨСЕЛМАННАРНЫҢ «САБАН» БӘЙРӘМЕ

Кичә Крестовниковлар заводы [2] артында мөселман Сабан бәйрәме башланды. Башка еллардагы кебек үк, бәйрәмдә ат чабышлары, йөгерү, җирле һәвәскәрләр-пәһлеваннарның көрәшләре һ.б. булачак. Төрле вак-төяк һәм тәм-том сатучылар балаганнары урнашкан гаять зур мәйданга һәр көн тамаша кылырга шәһәрдән һәм тирә-як авыллардан дистәләрчә мең мөселман һәм рус халкы килә. «Сабан» бәйрәме 23 майга кадәр дәвам итәчәк. Бәйрәмнең старостасы булып Х.Рахманкулов сайланган.

«Казанский телеграф» газетасы, 17 май, 1903 ел

***

Быел «Сабан» бәйрәме, һава торышы яхшы тору сәбәпле, шактый күңелле үтте. «Атлетларның» гадәттә кырда була торган көрәшеннән тыш, кешеләргә йөгерү өчен ипподром эшләнгән иде. Ярышта катнашучылар призга түбәтәйләр, яулыклар, күлмәкләр һ.б. алдылар. Ат чабышы 12 чакрым ераклыкка (бер якка 6 чакрым) уздырылды. Узган җомга көнне, бәйрәмнең соңгы көнендә, ат чабышында 15-кә кадәр чабышкы катнашты. Беренче призны сәүдәгәр Сәйдәшевның [3] аты алды. Ат чабышында жокейлар булып фәкать 12-14 яшьлек татар малайлары утыра. Атна дәвамында «Сабан» бәйрәмен тамаша кылырга килгән кешеләрнең саны бер мең генә булмады. Һәм, әйтергә кирәк, бәйрәм вакытында Рус Швейцариясендә [4] Троицкий атнасында [5] без күрергә гадәтләнгән бернинди «скандаллар» булмады.

«Казанский телеграф» газетасы, 14 июнь, 1895 ел

2. Яңа татар бистәсендә урнашкан бертуган Крестовниковларның стеарин, стеарин шәмнәр һәм сабын җитештерүче химия заводы.

3. Сүз сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев турында бара.

4. Казанлыларның Арча кырында урнашкан ял итү урыны. Хәзер ул урында шәһәрнең М.Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы.

5. Изге Троицкий атнасында (неделя «по святой Троице») Арча кырында куелган балаганнар, атынчыклар, тәмтомнар тезелгән палаткалар, самоварлар янында Казан руслары күңел ача торган булган.

«САБАН»

Суббота, 17 мая 1903 г. № 3107. № 3107. Суббота, 17 мая 1903 г.

КАЗАНСКІЙ ТЕЛЕГРАФЪ.

ГАЗЕТА политическая, общественная, литературная и коммерческая.

Въ магазинѣ Торговаго Дома Н-ца Ширшовой и К°

Получены МОДЕЛИ дамскихъ шляпъ.

ЖЕЛѢЗО ЛИСТОВОЕ

ЖЕЛѢЗО СОРТОВОЕ И ЛИСТОВОЕ КРОВЕЛЬНОЕ

БР. ЛЮБИМОВЫХЪ

Въ магазинѣ ВАРАКСИНА

Громадный выборъ:

П. А. ЗУЕВЪ и К°

К. И. МАЛЬМБЕРГА

Бр. ВАШМАКОВЫХЪ

А. А. ДУБРОВИНА

Въ магазинѣ фабриканта М. Ф. СТЕПАНОВА

Получены въ большомъ выборѣ:

ЛѢТНІЯ НОВОСТИ

БУМАЖНЫЯ ТКАНИ.

ИЗВѢЩЕНІЕ.

ВОСКРЕСНЫЕ И ПРАЗДНИЧНЫЕ ДНИ ТОРГОВЛИ ПРОИЗВОДИТЬ НЕ БУДУТЪ ВЕСЬ ДЕНЬ:

СЪ 18 ЧИСЛА СЕГО МАЯ НА ЯРМАРКѢ — БУЛАКЪ у кондитера ЛОПАТИНА изъ Ярославля

ДЕШЕВАЯ РАСПРОДАЖА.

Новое полученіе товара

ЖАДИНА

Контора М. К. КАШИНОЙ

Магазинъ КОНСТАНТИНОВА большой выборъ ШЛЯПЪ ФУРАЖКИ

ПРЕДОСТЕРЕЖЕНІЕ.

Контора ассенизаціи В. Н. МАРКОВА

ВНОВЬ ОТКРЫТЪ колоніально-гастрономическ. магазинъ Н. Я. ЧЕСНОКОВА

Т. А. Гаврилова

Өченчекөн мөселманнарның сигез көнлек «Сабан» бәйрәме тәмамланды. Ат чабышында берничә чабышкы аерылып торды. Беренче призны — кыйммәтле «чапан» (җәйге ир-ат пальтосы, безнеңчә, халат сыман) — Мамадыш өязе Мамалтык авылыннан крестьян малае алды.

«Казанский телеграф»
газетасы, 1 июнь, 1897 ел

МӨСЕЛМАН ХАТЫН-КЫЗЫ ҺӘМ... ҖӘМӘГАТЬ УРЫНЫНДА КҮҢЕЛ АЧУ

Без узган ел мөселман бәйрәмнәре турында язганда, мөселманнарда «Сабан» һәм башка бәйрәмнәрдә гүзәл җенес вәкилләренең тоткан урыны турында хәбәр иткән идек. Мәгълүм булганча, аларга бөтенләй урын бирелми, андый җәмәгать чараларында мөселман хатын-кызының булуы артык дип санала. Әле менә яңа гына ачылган Сабанга җомга көнне, 29 майда, өч мөселман хатын-кызы килде, шуларның берсе ире белән һәм кечкенә улы белән килгән иде. Күңел ачу һәм ат чабышы барган урыннан еракта утыру мөселманнарның хатын-кызга карашларына каршы килми, мөселман хатын-кызлары ачылган тамаша-күренешне хозурланып карыйлар иде... Монда Сабан белән җитәкчелек итүче старшиналарның берсе нинди начарлык тапкандыр, аңлашылмый. Ләкин ул билгеле бер түләүгә яшьләрне мөселман хатын-кызларына балчык ыргытырга күндерде. Малайларның зур гына төркеме, вәгъдә ителгән тәм-томга кызыгып, һич бер гаепләре булмаган кунакларга — мөселман хатын-кызларына ташландылар. Аларга күпләп балчык кисәкләре аттылар. Эзәрлекләү, мөселман хатын-кызлары кача башлагач та туктамады. Ат-арбалар калдырылган җиргә җиткәч, алар, хушларын югалтып, җиргә егылдылар [...].

Болар турында протокол төзелде, ләкин эш анда түгел. Ә бит һәркем уйлаячак: безнең төзәлмәс, караңгы Казан «Азиясе» әле нинди кыргый!

Энъ Пэ.
«Казанский телеграф» газетасы,
2 июнь, 1898 ел

Басмага Илдус Заһидуллин әзерләде.

САБАН*

БУ — ҺӘР ЯЗДА БӨТЕН КЕШЕ КАТНАШЫНДА ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН БОРЫНГЫ ТАТАР ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ. БЫЕЛ УЛ БОЛЫНДА ҮТӘ. СУЛ ЯГЫННАН ӘРӘМӘЛЕ ҮРЛӘР КАЙМАЛАГАН БУ БОЛЫН ЯҢА ТАТАР БИСТӘСЕННӘН КӨНЬЯКТАРАК, ШӘҺӘРДӘН ӨЧ ЧАКРЫМНАР АРЫРАК ҖИРДӘ. САБАН СУКА-САБАННЫ АҢЛАТА, БӘЙРӘМНЕҢ МӘГЪНӘСЕ: ЯЗДА ТАБИГАТЬНЕҢ УЯНУЫН, КЫРЛАРНЫ СӨРӘЭШКӘРТӘ БАШЛАРГА ВАКЫТ ҖИТҮЕН ТАНТАНА ИТҮ. КАЙБЕР ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА БУ БӘЙРӘМНЕ КЫРЛАРДАН КАР КИТҮГӘ ҮТКӘРӘЛӘР.

КАРЛ ФУКС

Казанда исә Сабан соңрак була, чөнки бәйрәм үткәрәсе болын язын Идел сулары астында кала. Сабан бер җомгадан икенче җомгага чаклы атна буена бара [1]. Яше-карты төш алдыннан бәйрәм урынына җыелалар. Аркан тартып, түгәрәк мәйдан билгелиләр. Мәйдан уртасына яшь, таза татар егетләре көрәшкә чыга; билләренә бәйләнгән сөлгегә тотынып, әле бер, әле икенче якка әйләндереп, бер-берсен егарга тырышып көрмәкләшәләр. Егу кайчакта бик тиз була, кайчакта бик озакка сузыла.

Чирәмгә сырты белән төшерүгә, тамашачы шау итеп ала. Җиңүче егет тантаналы төстә мәйданнан чыга башлый, аңа бүләк яисә акча соналар (ун тиеннән алып егерме тиенгә чаклы). Бүләккә дигән акча татар сәүдәгәрләреннән җыелган була.

*1824 елгы язма (редакция). [Карл Фукс. Казан һәм Казан төбәге: Гыйльми хезмәтләр, документлар, истәлекләр, эзләнүләр. Төзүчеләр: М.Г.Госманов, А.В.Гарзавина, И.А.Новицкая. — Казан: Җыен, 2008. — Б.73-73].

Бәйрәмдә тәртип саклаучылар, озын таяк тотып, үзләренең кемлеген сиздереп йөриләр. Әгәр инде көрәштә җиңелгән яктан дәгъва-фәлән булса, әлеге бурмистрлар шунда ук ике якны җайлап тынычландыралар. Акчага кызыктырып, алар читтән көрәшчеләр дә табарга мөмкиннәр. Моны белсәләр, тавыш чыга, әмма бәхәс тирәнгә китми, тиз арада йомып та куялар.

[…] Көрәштән кала йөгерү ярышы, ат бәйгесе үткәрелә. Озын таякка эленгән, бүләккә дигән яулык беренче килүчене аргы башта көтеп тора.

Чабыш атлары күзгә бәрелеп тормый, тәбәнәк, ябык күренә. Әмма шәп чабалар, җайдак малайлар да тезгенне оста тотып баралар.

[…] Сабан бәйрәменең тагын бер истә кала торган уены мондыйрак тәртиптә бара: түгәрәк хасил итеп, бер-берсеннән ике адым ара калдырып, 12, 15 яисә 20 кеше утырышалар. Төрле кием-салымнарны төреп, олы бер туп кебек эшләнгән төен тотып, түгәрәкнең тышында берәү тора. Ул төенне түгәрәктә утыручыларның берәрсенә бирә дә үзе ике-өч адым читкәрәк китеп баса. Шул мәлдә төенне күршедән күршегә ыргытып, түгәрәк буенча, кулдан-кулга йөртә башлыйлар. Ә артта торган егет, төенне тотып алырга теләп, түгәрәк тышыннан йөгерә, эләктереп ала икән, төенне кулыннан ычкындырган уенчы урынына үзе кереп утыра; түгәрәк тышына чыгып, әлеге җиңелгән уенчы йөгерә башлый. Уен кагыйдәсендә ике шарт үтәлергә тиеш: берсе — түгәрәктә утыручылар өчен, төенне бер йә ике кеше аша түгел, фәкать күршеңә ыргытырга тиешсең. Ә инде түгәрәк тышындагы «аучы» ыргытырга җыенганда гына төенне эләктереп алырга тиеш; әгәр очып барганда яисә ялгыш җиргә төшкәндә төенне эләктерә икән — бусы саналмый; бу очракта ул яңадан түгәрәктән өч адым читкә «куыла», төеннең түгәрәк буйлап китүен көтә башлый. Гадәттә, бу кагыйдәләр бозыла, «аучы» елдам булса, төенне ике-өч кеше аша ыргытырга мөмкинлек бирә; әгәр аның хәлдән тайганын сизсәләр, жәлләп, төенне һавада ук тотарга яисә җиргә төшкәнне алырга да рөхсәт итәләр.

Бу уенда иң ныгы үзенең елгырлыгы белән мактанучы «аучыга» эләгә. Түгәрәктәгеләр бу мактанчыкны хәлдән тайдыру өчен берләшеп алалар: тезләнеп утырышалар да төенне шундый тиз ыргытыша башлыйлар, «аучы» өч-дүрт адым артка калып ыргыла, инде дә берәрсенең мыштырдап калуы аркасында «аучы» төенне куып җитә икән, шунда ук аны арткы якка җибәрәләр. «Аучы» кире борылып йөгерә башлый, әмма төеннән шактый артка кала. Бу мактанчыкны тәмам хәл итү

өчен, түгәрәктәгеләр, кагыйдәне бозып, төенне әле бер, әле ике кеше аша ыргытырга тотыналар, мескен «аучы» кайсы якка ташланырга белмичә чарасыз кала.

Бу — елгыр-җитезләр уены. Үшәнлек белән берни кыра алмыйсың монда.

Татар кызлары да катнаша бәйрәмдә, алар инде төп тамаша мәйданыннан читтәрәк, агач күләгәсенә туктатылган көймәле арбаларыннан бөркәнчек аша күзәтеп торалар. Бу очракка инде алар, әлбәттә, иң купшы күлмәкләрен кигәннәр, иннек-кершәнгә буянганнар, битенә юка кара челтәрдән миң кебек түгәрәкләр ябыштырганнар. Әгәр якын килсәң, алар озын җиңнәре белән битен каплап бетерә язалар, һаман китмичә карап торсаң инде, битен ачалар. Куак төпләрендә хатын-кызларның балалары белән чыр-чу килеп чәй табыны корып утыруларын күрергә була. Аз гына танышлыгы булганнарны да алар чәйгә кыстыйлар. Тик татар ирләренә генә табынга якын килергә ярамый.

Бәйрәмгә руслар хәмер алып киләләр, дип зарлана татарлар; күзәтү, тәртип саклау куелган булуга карамастан, кайбер татарлар, исергәнче эчеп, тәртип бозалар икән. Низаг килеп чыкмасын өчен, полиция һәрчак бәйрәмгә кайбер түрәләрен һәм казакларны җибәрә. Билгеле булганча, татарларга ислам кануны буенча шәраб эчү тыелган.

[…] Сабан бәйрәменә өлкәннәр дә килә. Әгәр алар күбәү икән, кояш баер алдыннан бергәләп кичке намазга басалар. Чирәмле кырда кыл кебек бер рәткә тезеләләр дә, сәҗдәгә китә-китә, тын гына, бөек бер олпатлык саклап гыйбадәт кылалар. Шау-гөр килеп бер якта халык күңел ачканда, шундый капма-каршылык сәер тойгылар уята.

Искәрмә
1. 1824 елда Сабан бәйрәме 25 майдан 1 июньгә кадәр барды. Ул елда озын таяк очына чуар яулык элеп, Казан урамнарын шау кузгатып йөргән сөрәнчеләр аша русларны да бәйрәмгә чакырдылар (К.Фукс искәрмәсе).

ӘХМӘТ РӘШИТ

***

Каенлыкта бүген Сабан туе,
Яше-карты алды аны күтеп,
Җыелыштык менә, калдырдык та
Кырны тургайларга сәхнә итеп.

Әйдә, алар анда бәйрәм итсен,
Безнең өчен мәйдан монда гөрли,
Белик әле, нинди үзгәрешләр
Булды икән үткән яздан бирле?

Былтыр кемнәр батыр булып калган,
Һәм кайсы ат килгән иң-иң алдан,
Хезмәттәге батырлыгы өчен
Кемнәр-кемнәр нинди бүләк алган?

Котлау ява уңган егетләргә,
Уңган киленнәргә котлау ява,
Күңелләр көр — бүген Сабан туе,
Тылсымлы моң — чыңлап тора һава.

Ерак заманнардан күчкән бәйрәм —
Кыза, кыза милли Олимпия,
Олимп тавы исә күңелләрдә —
Ул үзенә каһарманнар җыя.

Тантаналар, әнә, бар тарафта:
Калаларда бәйрәм, салаларда;
Бабайларның асыл йолалары
Мирас булып күчә балаларга.

Татар иле генә бәйрәм итми —
Кан кардәшләр, шөкер, һәммә җирдә;
Җир шарында ничә кыйтга булса,
Барча милләттәшләр бергә-бергә.

Без күптәннән — кадим заманнардан
Гүзәл сыйфатларны саклый-саклый,
Шәҗәрәне дәвам иттерәбез
Инде менә шушы көнгә чаклы.

Гадел бәһа бирер өчен тарих
Күзебезгә текәп кат-кат карар;
Йөзебез ак булгач, без үлемсез,
Без — мәңгелек халык,
Без — татарлар.

ФАТИХ ӘМИРХАН

САБАН ТУЕНДА*

Без кечерәк вакытта әле Казанның Сабан туе шәһәрдән өч-дүрт чакрым ераклыктагы бер куаклыкта ясала иде.

Аны кемнәр ясагандыр, кемнәр аны идарә иткәндер, кемнәр, башлап йөреп, аны кайгыртканнардыр — мин аларын белмим, минем хатирәдә фәкать ике исем оешып багланып калганнар:

— Күмерче Ибраһим һәм Сабантуй Гәрәй.

Сабан туе була икән дигән хәбәр чыккач та, без шушы ике исемне ишетә торган идек. Боларның әүвәлгесен мин белмим, әмма икенчесенең кыяфәте минем зиһенемә бик шәп урнашып калган.

Бу — каудар гына, мәңге каядыр ашыгып тора торган, кирәк вә кирәк түгел урыннарның һәммәсендә дә кычкырына вә җикеренә торган әтәч сымак бер кеше иде.

Көрәш мәйданының уртасында бу кеше, мәңге ашыгып-ашыгып, каударланып, әллә кемнәргә ачуланып, күкрәгенә әллә нинди бер калай тагып йөри, безне, балаларны, мәйданның эченә кертми, Казанның могътәбәррәк байлары килсә, аларны каршы алып, аларга башкаларны торгыза-торгыза урыннар хәзерләп йөри. Һәм көрәшүчеләр бер-берсен ексалар, ул шушы фаҗига вә галәбә [җиңү] шатлыгының бергә җыелган урынына йөгереп, каушап барып җитә дә аякларын тыбырчындырып тора иде. Сабан туеның бу каһарманы, бер яктан, без балалар өчен куркыныч бер адәм булса, олугълар өчен көлке бер «Сабантуй Гәрәй» иде. Сабан туе көн бу кеше өчен бер бәйрәм генә түгел, бәлки нәрсәдер бәйрәмнән өстен бер нәрсә иде; шушы көнне генә аңар кеше:

— Гәрәй абзый! — дип хитаб итә, шушы көнне генә ул үзен бер «ләвазим» иясе [хезмәт урыны булган, дәрәҗәле], вазифалы бер мәэмүр сымак [чиновник сыман] итеп хис итә, шушы көнне генә ул үзен бер каһарман, хәят өчен кирәкле бер зат итеп күрә ала иде. Шуңа күрә дә ул, елның бер генә атнасын шөгыльләндерә торган сабан туе исеме белән, ел буена халыктан үзенә сәдака алып йөри иде.

Ул Гәрәй абзыйны минем күптән инде күргәнем юк. Ул, бәлки, исәндер, алай булса, Ходай бу иске заманның җанлы хатирәсенә озын гомер бирсен! Бәлки, ул инде вафат иткәндер, алай булса, Ходай аңа рәхмәт итсен!

Бу заманда Сабан туена хатын-кыз кертелми иде. Кертелми дип, кертелми дә түгел, бәлки хатын-кыз үзе анда бармый иде: шәригать кушмый иде.

**Ф.Әмирханның 1989 елда басылып чыккан «Сайланма әсәрләр» (Казан: Тат.кит.нәшр.) җыентыгының III томыннан алынды. Томны төзүче, текст һәм аңлатмаларны хәзерләүче Зөфәр Рәмиев. (Әсәр «Кояш»ның 1914 елгы 11 май (410 нчы) санында «фельетон» булып «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылган. «Сайланма әсәрләр»дә бар (2 нче том, 1958). Текст газетадан алынды. — Зөфәр Рәмиев искәрмәсе).*

Хатын-кыз ул заманда хәзерге яңа зиярәт буена җыелып, сөйләшеп, прәннек, конфет, чикләвек ашап утыралар иде. Ирләр Сабан туе белән хатын-кыз җыела торган җир арасында ике чакрым кадәр мәсафә [ара] булганлыктан, болар кемнәрнең батыр чыгуы, нинди атларның узганлыгы хакындагы мәгълүматны да ирләр Сабан туеннан хатын-кыз лагерена килгән малайлар аркылы гына хасил итәләр иде. Мондагы күңел ачу булса, яшь кызларның җыелышып, «так каравыл» уйнауларыннан гыйбарәт була иде.

Ирләр Сабан туеның да күңел ача торган програмы киң булмый торган иде: музыка, шәригатькә сыеп бетми торган нәрсә булганга күрәдер инде, рәсман [рәсми рәвештә] булмый, фәкать куаклык арасына яшеренеп утырып чәй эчә торган кешеләр генә үзләренә хосусый гармунчы яхуд скрипкачы алып, шуннан «әйттереп» утыралар, болар арасында чәй мәҗлесендә аракы эчеп кәеф кора торганнары да шактый була иде, ләкин бу эшләр гайре рәсми, могътәбәран [хөрмәтле кешеләр] күзеннән яшеренеп эшләнә торган эшләр иде. Рәсми програм көрәш, җәяүлеләр йөгереше, ат узыштырулардан гына гыйбарәт булып, көрәш әүвәл малайлардан башлана, аннан зурларга күчә торган иде. Бу вакытларда Сабан туенда руслар булмыйлар, русларның күбесе татарның шундый бәйрәме була икәнен дә белмиләр иде.

Инде ул заманнар үтеп киттеләр. Татардагы фикри вә мәдәни инкыйлаб [культура үзгәрүе] Сабан туена да тәэсирсез калмады.

Казанның Сабан туен хәзер инде җәмгыяте хәйрия үз кулына алды. Анда инде музыка шаулап тора башлады. Андагы узышка атка караганда «мәдәнирәк» [культуралырак] велосипедларда мөшарәкәт [катнаша] итә башладылар, уеннар да төрләләнде, мәйданга керү, анда урын әшгаль итү [алу] дә билетлы булганлыктан, Сабантуй Гәрәй абзый ихтыярыннан бигрәк, керүче кешенең, җәмгыяте хәйрия файдасына түли торган акчасыннан килә торган булды. Сабан туеның бу «мәдәниләшүе» аңа рус халкын да җәлеп итә башлады. Соңгы елларда инде Сабан туе карарга әллә никадәр руслар киләләр. Бу — Казанның үз Сабан туе [1], җәмгыяте хәйриясе тарафыннан ясала торган Сабан туе.

«Мәдәниләшү», бер җәһәттән, күбрәк кәеф-сафа бирсә, икенче җәһәттән, моның башка яклары да булачагы табигый бит: менә бервакыт Пороховой слобода [2] үзенә автономия дәгъва итәргә калкытты:

— Имеш тә, ул гадәме мәркәзият (децентрализация) тарафында, имеш тә, Ирландиягә кирәк булган автономия Пороховойга да кирәк!

Безнең Казан Сабан туе идарәсе Асквиттан [3] да уң түгел, ул шуңар күрә Пороховойда автономияле Сабан туе булуга каршы баш калкытмады: Пороховой үзенә Сабан туе ясый башлады [4].

Бу ел андагы Сабан туе үзләренең добровольный пожарный командалары файдасына ясала, шуңар күрә дә Сабан туен идарә итү дә, аңар кирәкле акча табу да — һәммәсе добровольный пожарный командада эшли торган егетләр кулында. Сабан туеның тәртипле барышы аларның бу эш артыннан тырышып йөргәнлекләрен күрсәтеп тора.

Мин анда Сабан туеның ахырына табарак кына барып җиттем. Анда килгәндә, минем күземә иң әүвәл чагылган нәрсә хатын-кызларымызның Сабан туена күп килүләре вә үзләрен шактый сәрбәст [иркен] тотучылыклары булды.

Автономия алган урыннар мәркәзгә караганда консерватизмнан ераграк булучылыгы тәҗрибә ителмәгән эш түгел. Монда да шулай икән. Пороховой Сабан туе безнекенә караганда мәдәнирәк икән! — дигән фикер ихтырсыз башка килә.

Хатын-кызлар монда төркем-төркем булып торсалар да, бу төркемнәр ирләр төркеме белән капма-каршуклар; менә берәр ел үтәр, ул төркем-төркемлек тә бетәр дә Сабан туйларында хатын-кызларымыз үзләрен бөтенләй сәрбәст тота башларлар дип ышанасың ки, бу эш Сабан туе — бу милли бәйрәмемезнең — дәвам вә рәважы [алга китүе] өчен бик мөһим бер матдәдер.

Мин үз тарафымнан Казан хатын-кызларына да бу елгы җәмгыяте хәйрия Сабан туена сәрбәст мөшарәкәт итүне гарыз [тәкъдим] итәр идем; барсыннар, керсеннәр, клубларда, театрларда утырган шикелле сәрбәст утырсыннар вә сәрбәст йөрсеннәр. Алар милли бәйрәмнең үги балалары түгел; ирләрнең Сабан туена катышырга никадәр хаклары булса, хатын-кызларымызның да шулкадәр үк хаклары бар. Аларны бу эштән һичбер кеше мәңгы итә [тыя] алмый, алар милли бәйрәмнең озак көтелгән кадерле кунаклары булырлар!

Җәмгыяте хәйрия идарәсе дә җил тегермәне белән сугышкан Дон-Кихот шикелле хәрәкәттә булмас, җәмгыять файдасына иганә итәсе һәм милли бәйрәмгә катышасы килгән ханым вә туташларны тиешле ихтирам белән каршы алыр.

Пороховой Сабан туенда күзгә бик бәрелгән нәрсәләрнең икенчесе анда русларның бик күп булуы булды. Карарга җыелган халыкның яртысы руслардан гыйбарәт иде. Алар нәкъ татарлар шикелле бер үк ихлас белән безнең бу бәйрәмгә катышканнар, нәкъ татарлар кадәр үк кәефләнә беләләр. Рус халкы, гомумән, бәйрәмнәрне сөяләр, аның өстенә, Сабан туе, бу чын Шәрекъ бәйрәме, русларда мәкабиле [охшашы] булмаган бәйрәмнәрдән берсе бит!

Ике милләткә гомуми булып киткән бу бәйрәмдә ике якның да гавамы тарафыннан кертелгән бер күңелсез хәлне дә монда зикер итми [телгә алмый] китеп булмый. Рус белән татар көрәшкәндә, рус гавамы руска вә татар гавамы татарга тарафдарлык итеп, моназарәгә [бәхәсләшү] керешеп китәләр икән. Менә бу эш бөтенләй тиешсез вә кирәксез бер эш, хәтта зарарлы бер эш, татарлар үз тарафларыннан бу тугъРыда бик сак булырга, рус ватандашларымызны кәефсезләндермәскә тиешләрдер.

Рус екса да, татар екса да барыбер түгелмени? Көрәш мәйданында ега алуның гына шәрәфе бик зур түгел иде.

Теләсә нинди зур рус галимен, зур мөхәррирен теләсә нинди татар ломовой ямщигы көрәшеп ега ала бит һәм, билгакес [киресенчә], татарның теләсә нинди Гаспринскиен, теләсә нинди Гаяз Исхаковын теләсә нинди бер йөк ташучы рус көрәшеп ега ала, ләкин, әмма моның белән мактанган татар ломовой ямщик яхуд йөк ташучы рус көлке генә булып калыр иде.

Рус ега икән, бик яхшы: шул рус шул татардан көчле булган була. Татар ега икән, ул да бик яхшы: шул татар шул рустан көчле булган була. Ләкин моның белән милләтләр үлчәшмиләр.

Мин татар гавамына бу мәсьәләгә һичбер әһәмият бирмәскә вә бу тугъРыда рус гавамы белән һичбер төрле моназарәгә керешмәскә киңәш бирәм. Бу тугъРыда моназарә ахмаклык вә аңсызлыктан башка нәрсә түгел. Татар гавамы әүвәл башлап мондый моназарәне ташласа, рус гавамы да аны, табигый уларак, ташлаячактыр.

Пороховой Сабан туеның програмы шактый киң булганлыкны сөйләделәр, анда берникадәр яңа спортлар кертелгән икән. Фәкать мин боларына барып өлгермәдем.

Мин барганда инде халык, көрәш мәйданыннан чыгып, узышка җибәрелгән атларны көтәләр, добровольный пожарный команданың үз музыкантлары му-

зыка уйныйлар, чабышка киткән атлар өчен хәзерләнгән призлар озын бер жердага эленеп, һәркемгә күренеп торырлык бер җиргә бастырылганнар иде. Мәйдан тирәсендә, һаваның бозык булучылыгына карамыйча, мең ярым кадәр халык тәхмин итәргә [(барлыгын) чамаларга] мөмкин иде.

Сабан туе идарә итүче егетләрнең берсенең тырышуы белән, халыктан истисна [аерым] уларак, минем атыма чабышучылар килә торган җирдә урын бирделәр дә мин дә халык белән бергә атларны көтәргә тотындым. Атлар сигез чакрымнан киләчәк булганга күрә, аларны озак вакыт көтеп алырга тугъры килде. Көтүче халык киләчәк атлар хакында үзләренең фикерләрен сөйләп торалар. Озынчарак башлы бер абзый:

— Шәле аты беренче килер! — дип бик катгый әйтеп тора. Иптәшенең бу эштә шик тотуына аның исе китә. — Беләм инде мин Шәле атының беренче киләсен, син ат таный торган кешеме соң! — дип җибәрә.

Менә бервакыт ерактан атлар күренә башлыйлар. Музыка яңгырый, ниндидер бер күк ат, иптәшләрен егерме биш-утыз сажин кадәр җир калдырып, беренче килә, аның артыннан икенче, өченче, дүртенче атлар килә. Атларның берсе өстендәге малаен ташлап калдырган, ләкин үзе һаман чабуында дәвам итә, хәтта үз алдындагы бер атны узып китәргә дә соң дәрәҗә тырыша.

— Юләр ат, өстемдә малаем булмагач, җиңелгәрәк килер дип уйлагандыр инде.

Халык аны шушы юләрлеге өчен көлеп каршы ала, ләкин ул, аңар бер дә исе китмәгән кыяфәт белән генә, сызыкны үткәч тә чабуында дәвам итә.

Иң ахырдан бер ат килә, ул да, бичаракай, үзенең күңелсез хәлен аңламаган сымак, бөтен гайрәтен сарыф итүдә косур [кимчелек] күрсәтми. Ходай аңа чапкыр аяклар бирмәгәнгә, ул үзе гаеплемени? Ул инде үз көченнән килгәнне эшләп карый.

Чабыш туктагач, беренче килгән атның Шәфиев аты, икенче килүче ат Шәле авылының бер кеше аты икәнлеген сорашып белдем.

Теге озынча башлы кеше иптәшенә үзенең бу хатасын ничек бәян иткәндер, белә алмый калдым.

— Шәле атына күз тиде! — дияргә аңар юл бар.

Чабышкан атларга призларны өләштеләр. Икенче килгән атны бер сала агае өстерәп халык арасыннан уздырды, кай кешеләр аннан: «Кайсы авылныкы?» — дип сорашалар, ул илтифатсыз гына, ләкин кычкырып кына:

— Шәле! Шәле!— дип куя.

Ничек тә аты икенче килгән кеше шул!

Искәрмәләр

1. Бу – Казанның үз сабан туе... – Казанда ул елны сабан туе 23 һәм 25 майда (җомга һәм якшәмбедә) җәйге ипподромда уздырыла. Алдан хәбәр ителгән программа нигезендә анда балалар һәм зурларның татарча көрәше, французча көрәш, баганага менү, велосипедта узыш, балалар һәм зурлар йөгереше, ат чабышы була, милли музыка уйный. Күп ярышларда руслар да катнаша. Газеталарда басылган хәбәрләрдә сабан туеның тәртипле узуы, исерекләрнең күренмәве әйтелә. Тамашага килүчеләр билетлар белән кертелгән, җомга көнне өч меңләп, якшәмбедә ике меңләп кеше булган.

2. Пороховой слобода – Казандагы бер бистә, хәзер шәһәрнең Киров районы территориясендә.

3. Асквит (1852-1928) – инглиз дәүләт эшлеклесе, либераль партия лидеры, 1908-1916 елларда премьер-министр; аның житәкчелегендәге хөкүмәт ирландиялеләрнең милли азатлык хәрәкәтенә каршы килгән, 1916 елгы кузгалышларын да рәхимсез бастырган.

4. Пороховой үзенә Сабан туе ясый башлады. - 1914 елда ул 9, 10, 11 майларда уздырылган.

АЛЫП БАТЫР УЛЛАРЫ

ГАЗИНУР МОРАТ

Мәйдан уртасында — ирләр —
Алып батыр уллары.
Көрәшче халыкныкы ул
Язгы Сабан туйлары.
Бабайлардан калган йола
Бүген безне җилкетә...
Әнә, мәйдан, тын да алмый,
Көрәш батырын көтә.
Йә, кем ул батыр көрәшче?
Ил йөзен акларлыкмы?
Туган җирен төрле залим
Затлардан сакларлыкмы?
Рухы ныкмы, түзәрлекме,
Әзерме зур алышка?
Ныклы дәвам булырмы ул
Халкым улы Алыпка?
Бу көрәштә беркемгә дә
Юк бернинди ташлама.
Татарның Сабан туе да
Алыплардан башлана...

Р.Әхмәтов фотосы

РАБИТ БАТУЛЛА

ЯРЫШ*

Киң болын көчле агышлы елгага барып тоташа иде. Икенче якта кыя-лар. Басу капкасыннан халык болынга агыла. Дугаларына шөлдерләр, кыңгыраулар таккан, эшлияләры бизәкле атлар җигелгән арбаларга кешеләр утырган. Һәр арбаның кучеры янында гармунчы утыра. Бия җигелгән арба артыннан колын уйнаклап бара. Берничә җайдак егет ат уйната.

Трантаска утырган ике милиционер бара.

Боларның барысы да Рудикның күзе аша уза. Алар Айрат белән көнбагыш чиртә.

Фронттан кайтканнар бара, алар погонсыз гимнастерка кигән. Һәрберсенең күкрәге тулы орден, медальләр.

Ике-өч сәпит узып китте.

Жуков «ГАЗ»игы бара. Балалар машина артыннан йөгерә.

Полуторка узып китте, күрәсең, ул район мәркәзеннән килгән күчмә кибет.

Кешеләрнең күбесе җәяү бара. Яшь хатыннар бала арбасы тарткан.

Мәйданга килеп җиттеләр. Кешеләр түгәрәк хасил итеп утыра. Күбесе нидер ашый, көнбагыш, чикләвек ваталар, сагыз чәйниләр.

Мәйдан уртасында биек багана. Багана очындагы читлектә әтәч.

Читтәрәк авыш бүрәнә. Бүрәнәдән ерак түгел, ике потлы гергә тәкә бәйләнгән. Ул тартыла, ычкына алмый.

Мәйданның тышкы ягында олы яштәге хатыннар көнбагыш чикләвек, ко-рот сата.

Полуторканың арткы тартмасы ачык, сатучы өстә торып сату итә, аның товары: конфет, морс, мичкәдә тозланган балык.

Бер кырда яшьләр әйлән-бәйлән уены оештырган. Бер түгәрәктә җырлыйлар, икенчесендә бииләр. Шау-шу, көлеш.

Кеше күзеннән еракта, агач күләгәсенә бер гаилә урнашкан. Яшь ана, күкрәген яулыгы белән каплап, баласын имезә. Ата кеше өч яшәр малаена «әтәч» конфет алып килгән. Малай шатлыгыннан нишләргә белми сикерә. Ана да бәхетле елмая.

Арырак бер кызчык анасының итәгенә ябышкан да җылый:

*Өзек мәшһүр балет артисты Рудольф Нуриевкә багышланган «Бию җене кагылган егет» кыйссасыннан алынды.

— Әни-и, әтәч камфит кирәк. Алыгыз миңа да әтәч камфит.

Болын түрендә хәтәр егетләр атларының тоякларын кыздыра, алар арасында Тулпарга атланган Мортаза да бар.

Кызыл комач белән капланган комиссия өстәле янында Сабан туен әзерләүчеләр кайнаша. Колхоз рәисе Аксирак, авыл советы рәисе Мардун, тагын кырыс чырайлы ике кеше. Алар китель, хром күнитекләр кигән, гәләфи чалбарлардан. Берсе Ворошиловныкы кебек, икенчесе Сталинныкы сыман мыек үстергәннәр.

Шунда ук оешкан төстә пионерлар йөри. Вожатая бик җитди кыяфәттә әмерләр бирә, балаларны оештыра.

Вожатая ирләрчә кырыс тавыш белән:

— Становись! — дип кычкыра. — Балалар этешә-төртешә тезелә. — Смирно!.. Первый, второй рассчитайсь!

Балалар сафка басып, артык җитди, артык тантаналы кыяфәттә саный башладылар:

— Первый… второй… первый… второй…

— Фахразиев! — дип кычкырды вожатая.

— Мин Фахразиев! — диде бер малай.

— Ике адым алга!

Малай алга чыкты.

— Фахразиев, син пионермы?

— Пионер, Зания апа!

— Отставить, Фахразиев!

— Гафу итегез, мин — пионер, Зания Гафуровна.

— Пионер икәнсең, Фахразиев, синең кызыл галстугың кайда?.. Ник дәшмисең? Фахразиев! — Аның тавышы шомлы иде. — Мин синнән сорыйм, Фахразиев! Кайда синең галстугың?

Малай җылый ук башлады:

— Апа минем гластуктан ими капчыгы тегеп кигән.

— Авылга марш! Син кансиртта катнашмаячаксың!

Малай үкереп җылап, читкә китте.

Халык арасыннан малайның апасы атылып чыкты да Фахразиев дигән малайны җитәкләп, вожатая янына алып килде.

— Кем сине кыерсытты, энем? — диде апа кеше янаулы тавыш белән. — Ни өчен син җылыйсың?

— Ул сборга галстуксыз килгән! — диде вожатая.

Галстуксыз малайның апасы Мәдинә шактый тәвәккәл кыз булып чыкты. Ул янаулы кыяфәт белән вожатая каршысына йөзгә-йөз килеп терәлде дә ысылдап:

— Сиңа ни җитми, Зания? — диде. Тегесе каушап калды. — Ни өчен син гел минем энемне кыерсытасың? Чөнки без фәкыйрь, шуңа күрәме? 1917 елда иптәш Ленин байларны бетерде. Ә син фәкыйрьләрне кимсетәсең, байларны яклыйсың. Мин райкомга чаклы барып җитәрмен, син буржуйлар яклы!

Кычкырышучылар янына халык җыела башлады. Вожатая мондый кыюлыкны көтмәгән иде. Гауга башланасы урынга Аксирак килеп җитте, теге ике кырыс чырай да аңа иярсгән иде.

— Ни булды? Кем буржуй? — диде Аксирак сорау алучы сыман дәһшәтле тавыш белән.

Фахразиевның апасы усал йөзен Аксиракка таба борды.

— Энемне Сабан туенда катнаштырмый менә бу җубалгыгыз! — дип кычкырды Мәдинә.

Вожатая Аксирак килгәч кыюланды кебек.

— Ул галстуксыз килгән! — дип аклана башлады.

Тәвәккәл кыз кискен хәрәкәтләр белән күлмәк изүеннән кызыл комач тартып чыгарды да Заниянең борынына төртте, аннан энесенең муенына бәйләп тә куйды:

— Минем күкрәкләрем капчык кигезмичә дә ишелеп төшмәс, әнә, синекен капчык та тотып тора алмас. Бар, стройга бас! — дип боерды ярсу кыз энесенә. Фахразиев үз урынына барып басты. — Бәйләнеп кенә карасын пырлитарга!

Изүеннән комачны чыгарганда, аның тыгыз күкрәкләре ачылып киткән иде, ике кырыс чырайның һәм Аксиракның игътибарыннан ул читтә калмады.

Районнан килгән әлеге кырысның берсе, анысы нәчәлник бугай, Аксиракны читкәрәк чакырып алды да, пышылдап:

— Тавышны йом! Бу хәтәр кызыкай тәртәгә тибәр. Аларга материальный ярдәм итәргә кирәк.

— Понял! — диде Аксирак. Ул тәвәккәл кыз янына килеп әйтте:

— Шаулама, Мәдинә, әйбәт булыр, шаулама. Сиңа материаль ярдәм дә булыр...

Мәдинә кызган иде:

— Нигә ул кешеләрне классларга аера? — диде.

Аксирак ыкы-мыкы итте:

— Ну, сөйләшә белми ул, адлим словом, грамот чамалы... Ә син, Зания, балаларың белән әнә тегендә эшлә.

Ике фронтовик, халыкны аралап, бәхәсчеләр янына ыргылды.

Берсе, шактый кызмачасы:

— Ни бар монда? — дип кычкырды. — Кайсыгызны урынына утыртырга кирәк?

— Тарал! Берни дә булмады! Тарал! — диде Аксирак.

Нәчәлник Аксиракның җиңеннән тартып, ризасыз гына:

— Башла, башла инде! Нигә сузасың? — диде.

Тегесе оештыручыга каты итеп төртте:

— Тиз бул, башла! — дип әмер бирде.

Оештыручы Саттар ике учын рупор итеп:

— Хөрмәтле калхузчылар! — дип оран салды. — Урыннарыгызга утырыгыз! Көрәшкә, ат чабышларына, капчык белән сугышка, су ташуга, аркан тартышка кызыл өстәл янында языла башлагыз. Бүләкләр, бирнәләр күз алдыгызда. Беренче килгән атка матур палас Гөлчәһрә киленнән. Башбатырга тәкә белән чигешле сөлге Фирүзә киленнән. Шулай итеп, Сабан туе бәйрәмен башлап җибәрәбез. Котлау сүзен председателебез, Бөек Ватан сугышы батыры, ике орденлы Аксирак Сабировка бирәбез.

Аксирак бил каешын рәтләп сүз башлады:

— Иптәш калхузчылар, тәскәйт, фронтовиклар! Без җиңдек, адним словом, вероломный фашизмны. Иптәш Сталинның акыллы җитәкчелеге аркасында, тәскәйт... Яшәсен безнең бөек атабыз Иосиф Виссарионович Сталин!

Ыргы уйный, барабан кагалар. Түгәрәккә марш атлап пионерлар керде.

Р.Әхмәтов фотосы

Без яңа тормыш алып киләбез,
Агайлар, безгә юл бирегез!
Барабаннар сугып үтәбез без,
Ал байраклар белән, күрегез.

Пионер, алга!
Зур көрәш алда,
Камсамулларга
Сәлүт бирәбез,
Алмашка киләбез!

Рудик йотлыгып күзәтә. Бер карсак буйлы ир ике потлы гер күтәрә. Гер күтәрү буенча комиссия кешесе аның ничә тапкыр күтәргәнен санап бара:

— Утыз, утыз биш...

Ике үсмер, аркылы бүрәнәгә атланып, капчык белән сугыша.

Рудик аларны урта гасырлардагы гөрзи белән орышучылар итеп күрә.

Текә баганага менәргә теләүчеләр чираты. Берсе багана башына якынлашып килә.

Рудик аны урта гасырларда шәһәр диварына сөяп куелган багана буйлап менеп баручы сугышчы итеп күрә.

Авыш бүрәнә буйлап бер малай бара.

Рудик аны ургып ага торган елга өстенә салынган бүрәнә өстеннән баручы сугышчы итеп күрә.

Мәйдан уртасында аркан тартыш.

Рудик аларны абордажга алынган корабны тартып китерүче сугышчылар итеп күрә.

Мәйданда көянтә-чиләк белән су ташу ярышы, егылалар, көлешәләр.

Оештыручы янә кычкырды:

— Ат чабышлары башлана, аралык — өч чакырым, Талтирәккә чаклы — чакырым ярым, кирегә — чакырым ярым.

Уратада көрәшчеләр.

Урта гасыр сугышчылары бер-берсен иярдән тартып алырга тырыша кебек. Бер батыр икенчесен умырып алып һавага чөя.

Башбатыр көндәшен аркасына салды. Җиңүчене халык алкышлый.

Мәйдан өстендә янә оештыручы тавышы яңгырады:

— Камиссия үз карарын чыгарды: Сараш Байморатов башбатыр кала! Аңа тәкә белән Казан сөлгесе!

Ду килде халык, кемдер кул чаба, кемдер сызгыра.

Сараш батыр сөлгесен баш очында болгап:

— Ризамы, картлар? — дип кычкырды.

Картлар:

— Риза! Риза! Риза! — дип өч тапкыр кычкырды.

Башбатырның муенына Казан сөлгесе урыйлар, аның сыртына тәкәне менгезәләр, башбатыр, тәкәне күтәреп, шәрәф түгәрәге буйлый йөреп китте. Мәйдан, аягүрә басып, башбатырны алкышлый.

Шулчак кемдер яшелле-күкле тавыш белән акыра башлады:

— Атлар килә-ә! Җайдаклар килә-ә!

Халык атлар килгән якка ыргылды.

Болын түреннән атлар килә, матур киләләр.

— Кем беренче? — дип сорый бер карт.

— Таштарак! Персидәтел аты килә-ә! — диде егет.

— Икенче Тулпар чаба!

— Тулпар алга чыга.

— Юк, Тулпар артта калды… Ул, чыгымчылап, кырыйга кереп китте.

Атлар килә. Рудик урта гасырлардагы яуга чаба торган сугыш атларын күрә. Ат өстендә Рудик үзе дә бар.

Тамашачылар җаната. Кычкыралар, сызгыралар.

Узыштан кайткан атларны малайлар йөртергә алып китте.

Оештыручы тамагын ерта язып акырды:

— Тасманы беренче булып Таштарак узды!

Аксирак белән ике кырыс кеше, ике милиционер канәгать, алар Аксиракны котлый.

Халык риза түгел иде. Ыгы-зыгы купты. Алкышлаучылар арасында ризасызлар авазы катырак ишетелә башлады. Ачуы чыккан Мортаза тамагын киереп акырды:

— Таргай Тулпарның сәламәт күзенә камчы орды-ы! Камчы орды-ы!

Таргай да тамагын киерә:

— Юк-ук, мин ормадым… Ул үзе миңа камчы белән сукты-ы!

Халык шаулый. Мортаза буза куптара. Ике милиционер аның ике кулыннан тотты.

Мортазаны ике милиционер гына тотып тора алмый, ул тартыла, ыргыла, алар кулыннан ычкынды:

— Аксирак! Синең эш бу! Син котырттың Таргайны Тулпарның күзенә сугарга! Юкса, Тулпар аны узып китә иде.

Сорхан атлы олы яшьтәге абзый кычкыра:

— Ярыш дөрес түгел, иптәшләр. Малай атның күзенә сукты!

Таргай күзен дә йоммый:

— Сукмадым! — дип аклана. — Мортаза абый үзе миңа камчы белән орды.

Мортаза, Аксирактан аерылып, Таргай янына килде:

— Ах, син, бабасыр! — диде Мортаза. — Кем сиңа сукты, маңка малай?! Күрсәт, күрсәт аркаңны халыкка! — Ул көч белән Таргайның күлмәген күтәреп, аркасын ачты. — Кайда монда камчы эзе, кайда? Тулпар бөтенләй сукрайсынмы? Кабәхәтләр сез! Айрат, атны алып кил. — Айрат атны алып килде. — Күрегез! Узышка чаклы Тулпарның уң күзе сәламәт иде, карагыз, аның уң күзендә камчы эзе.

Халык диңгез кебек дулкынлана. Эш җитди төс ала бара иде. Фронтовиклар Мортаза яклы.

— Ярыш дөрес түгел! — дип кычкырды култык таякларына таянган фронтовик Кодраш.

— Тулпар белән Таштаракны яңадан узыштырырга кирәк! — диде Сорхан абзый.

— Юлның ян-якларына күзәтчеләр куйсыннар! — диде Кодраш.

Милиционерлар халыкны тыеп тора алмый иде инде.

Районнан килгән кырыс нәчәлник Аксиракка теш арасыннан гына боерды:

— Эш зурга киткәнче җайла! Синең дә, минем дә баштан сыйпамаслар!

— Яхшы, яхшы... — диде Аксирак. — Җәмәгать! Тынычланыгыз! Тулпар белән Таштаракны ике чакырым арага җибәрәбез. Тынычла-ан!

— Ян-якларга күзәтчеләр куегыз! — дип кычкырды Сорхан.

— Булыр! — диде Аксирак.

Халык тынычлана төште.

— Мөхтәрәм җәмәгать! — диде Мортаза. — Минем шартым бар. Таргай урынына башка җайдак куегыз яки аның камчысын алыгыз. Яки икебез дә камчысыз барабыз!

Икесен дә камчысыз җибәрергә, дигән карар кылынды.

Оештыручы игълан итте:

— Булды-ы! Моннан кушкаенга чаклы, аннан киренгә чабасыз! Ара ике чакырым... Басыгыз!.. Китте-ек!

Ике җайдак алга томырылды. Кушкаенга чаклы алар тигез барды. Менә алар кушкаенны әйләнеп узды. Кире чабалар. Халык үкерә, сызгыра. Беренче булып Таштарак килә. Мортаза атын тыебрак бара. Таргай атын тибенә-тибенә куалый. Мортаза тезгенен бушата төште, Тулпар Таштаракны куып җитә, хәзер алар икесе тигез килә.

— Тулпа-ар! — дип кычкырды да Мортаза тезгенен бөтенләй бушатты.

Тулпар алга очты. Тасмага килеп җитәр алдыннан гына Тулпар Таштаракны артта калдырды. Сызгырыш, үкереш башланды. Гаделлек торгызылды. Җайдаклар җәяүләнде. Башка малайлар атларны, тезгеннәреннән тотып, йөртергә алып киттеләр. Тамашачылар мәйданга кайтты. Аксиракның чырае җимерек иде. Ул оештыручыга нидер әйтте.

Тегесе калку урынга басып игълан кычкырды:

— Ярышта Тулпар белән Мортаза җиңүче дип табылды!

Алкышлар, котлаулар Мортазаны күмеп китте. Малайлар атларны йөртеп, мәйданга алып керде. Беренче булып Айрат җитәкләгән Тулпар, икенче булып Таштарак шәрәф түгәрәге буйлап йөреп китте.

Калку урында тагын оештыручы күренде:

— Җиңүче җайдак Мортаза Фазлыев матур палас белән бүләкләнә, паласны сугучы киленебез — Гөлчәһрә!

Паласны атның аркасына салдылар.

— Ризамы, аксакаллар? — дип сорады Мортаза.

Аксакаллар ягыннан:

— Риза-а, Мортаза, риза-а! — дигән җавап килде.

— Рәхмәт, аксакаллар! — диде җиңүче.

— Икенче урынны Таштарак белән Таргай яулады. Аңа тирлек бүләк ителә.

Оештыручының ярдәмчеләре Таргайга ияр астына җәя торган паласчык тапшырдылар.

— Ризамы, картлар? — диде Таргай.

Халык ризалык кычкырды.

— Өченче урын Йолдызкашка белән Байтарга...

Иң арттан килгән атны мәйданга алып керделәр. Фатыйма карчык капшана-капшана ат янына китте, аны Рудик култыклаган. Фатыйма ат муенына кәшимир яулыгын бәйләргә тырыша.

— Нигә алай итәсең, әби? Ул иң арттан килде бит. — диде Рудик.

— Сиңа ул кызганыч түгелмени? — диде әби.

— Бик кызганыч! — диде Рудик.

— Мә, яхшылап бәйлә. Иң нык тырышканы ул булды бит, балам. Ләкин бу эш атына присидәтелнең симергән айгырын узу кайда? Кара, ат җылыйдыр, мөгаен.

Рудик атның яңагын сыпырганда күрде: чыннан да ат җылый иде.

— Менә шушы бүләкне муенына бәйләгәч, туктар, улым. Бу гадәтне борынгы бабаларыбыз уйлап чыгарган, олан. Җиңелүчене дә бүләкләргә кирәк.

Башка хатыннар да арттан килгән алашаның муенына яулык бәйли.

— Халык үзе хәл итсен, кемне хурларга, кемне хупларга!

Рудик алашага озак кына карап торды, аның яшен сөртте. Яулыкларны бәйләште. Иң күп бүләкне арттан килгән алаша җыйды.

Халык тарала башлады. Батырлар билгеләнде, ат ярышлары тәмамланды. Моннан соң мәйдан янында уенчылар, гармунчылар, яшьләр генә калды.

Аксирак җитәкчелегендәге комиссия өстәл янында утыра бирә. Аксирак кушуы буенча оештыручы Саттар Мортазаны эзләп табып, өстәл янына алып килде.

Кырыс нәчәлник иң беренче булып Мортазага кулын сузды:

— Ну-с, котлыйм сине, Фазлыев! — диде.

Икенчесе сүзләренә шомлы мәгънә салып әйтте:

— Ләкин, Фазлыев, синең белән күптәннән утырып сөйләшкән юк бит инде, — диде.

Кырыс нәчәлник әйтте:

— Берсекөнгә... иртәнге сәгать сигезгә киләсең...

Сүзгә Аксирак катнашты:

— Син районда тиешле урыннарда сөйләшкән вакыттта, Тулпарың ит комбинатында булыр! — диде, Мортаза аның чыраенда мыскыл очкыннары күрде.

Мортаза куырылып килде, ул ярсуын көчкә тыеп тора иде:

— С-син, бетле күз! Ни сөйләгәнеңне колагың ишетәме? — диде ул.

Аксирак иренен чалшайтып:

— Син үз тавышыңны ишетмисең! Синең өстән бер капчык җалоба бар! Син башкалар алдында нимес техникасын мактыйсың, тәскәйт. Пленный мурда!

— Кыскасы, мин Тулпарны бирмим! — дип кисте Мортаза.

— Синнән сорап торганнар, ди, тәскәйт...

— Мин синең үзеңне ит камбинатына аткарам!

— Ишеттегезме, ул миңа яный! — дип кычкырды Аксирак.

Мортаза сабырлыктан кычкыруга күчте:

— Калхуз милке белән шаярырга сиңа кем кушкан? РККАны, фронтовикны иткә тапшыру — җинаять!

Аксирак та аннан катырак кычкырырга тырыша иде:

— Бер Тулпарны гына түгел, бөтен атларны да иткә тапшырачакбыз. Бу минем каприз түгел, тәскәйт, райком указы, әгәр бик телисең икән, хәтта иптәш Сталинның указы! Ликвидировайт все конские заводы, понял! Иртәгә бөтенесе дә иткә китәчәк! Понял! Үтерү белән миңа янаганың һәм совет диствителнесен хурлаганың, һәм дошман техникасын мактаганың өчен, син башың белән җавап тотарсың, кулак калдыгы, плинний Фазлыев!

Мортаза, нәфрәтен тыя алмыйча, Аксиракның якасыннан алды:

— Ну, кабәхәт тә инде син, Буксирак Сабиров!

Хәмит килеп чыгып, Моразаны тотып алды.

— Ярамый, Мортаза! — диде ул.

Нәчәләник сүз алды:

— Кул белән уйнаганың өчен, беләсеңме, ни була, Фазлыев?

Хәмит вакытында өлгерде, ул сабыр гына нәчәлниккә әйтте:

— Кичерегез аны, кайнар кеше, кызып киткәндер, кичерегез!

— Кайнар булса, без аны тиз суытырбыз! — диде кырыс нәчәлник.

Милиционерлар Мортазаның кулларын каерып тотты.

— Туганнар, кичерегез аны. Бәйрәм көн бит! — диде Хәмит.

— Ялынма аларга, абый! — диде Мортаза.

Кырыс нәчәлник милиционерларга ым какты, тегеләре Мортазаны ычкындырды. Нәчәлник әйтте:

— Бәйрәмен бозмагыз... Кайтсын өенә, беренче урынны яулаган батыр бит, бүләкләрен юсын, — диде.

Мортаза, Тулпарның тезгенен алып, авыл тарафына китте. Аның белән рәттән Хәмит, Айрат, Сорхан, Рудик йөри. Пальма яннан теркелди, ара-тирә юл кырыена чыгып, чыпчык, тычкан халкын куыштыргалап ала.

Җиңүче Мортазаның кәефе бик тә хөрти иде. Бу җиңү җиңелүдән битәр олы кайгы чыганагы буласын да Мортаза бик яхшы аңлый. Аксирак та, районнан килгән шомлы нәчәлникләр дә аны болай гына калдырмаячак. Бу куркыныч-шомлы уенны азагынача уйнап бетерергә кирәк.

— Сорхан абый, — диде Мортаза. — Атларны иткә тапшыру дөресме?

— Шулай диләр. Атларны бетерәләр, имеш. Кымыз заводларын да туктаталар икән.

— Ат дворлары урынында ни кала?

— Дуңгыз фермалары!

— Дуңгыз фермалары?

Мортаза тынды, башкалар да сүз әйтмәде.

САБАНТУЙ БУЛЫП УЗГАН МӘЙДАНДА

ХАРРАС ӘЮП

Кичә монда Сабантуй гөрләде,
Җыйды, көрештерде бу мәйдан,
Бабайларның кайнарлыгы кайтты,
Кунакчыллык көчте еллардан.
Атлар чапты...
Колга башларына
Менеп җитте кичә Кыюлык;
Хаклык батыр калды.
Мактанчыклык
Капчык тигәч төште егылып.
Эчкерсезлек кайткан кунак булып,
Тапкырлыгы шунда, җорлыгы,
Һәр кешенең җанын сыйпап йөрде
Гасырлардан килгән җыр-моңы...
Халыктагы матур гадәтләрне
Берәм-берәм җыеп еллардан,
Бер күрсеннәр әле диеп, ахры,
Дәшеп алган безне бу мәйдан.
Бүген менә тагын таралыштык.
Ераклардан килгән җылылык
Мәйдандагы ак багана сыман
Күңелләрдә калды сузылып...

Р.Әхмәтов фотосы

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Һәммә җисем сайланышта, үзгәрештә.
Тик бер нәрсә кала мәңге бер рәвештә,
Ул – хакыйкать! Бүгенгеме, кичәгеме –
Аерма юк!

Лена Шагыйрьҗан

СҮЗ УЛ – ГӘҮҺӘР*

ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИН,
әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы

Һәр халыкның тормыш, белем һәм акыл тәҗрибәсе хикмәтле сүзләр рәвешендә гасырлар дәвамында тупланып, буыннан-буынга күчеп, сакланып килгән. Аларның күбесе мәкаль-әйтемнәр булып халык авыз иҗаты җыентыкларында урын алган. Язма әдәбият барлыкка килгәннән соң, хикмәтле сүз әйткән акыл ияләренең исемнәре дә теркәлеп бара. Борынгы төрки язма истәлекләрдә, М.Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә һәм Й.Баласагунлының «Котадгу белек» поэмасында афористик гыйбарәләрне күп очратырга мөмкин. Урта гасырлардан алып хәзерге чоргача иҗат иткән язучы-шагыйрьләрнең иҗатында, аерым алганда Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, К.Насыйри, Р.Фәхретдин, Г.Тукай, Дәрдемәнд, Һ.Такташ, М.Җәлил, Г.Кутуй, Х.Туфан һ.б. әсәрләрендә, халкыбызның тормыш һәм яшәү рәвешен, зирәклеген, дөньяга карашын чагылдырган хикмәтле сүзләр урын алалар, әдипләрнең әйтергә теләгән фикерләрен укучыга җиткерүгә буйсыналар.

Классик дәвердә һәм хәзерге татар әдәбиятында күренекле язучы һәм шагыйрьләребез Ә.Еники, Г.Афзал, Ш.Галиев, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, М.Мәһдиев, Ә.Баян, М.Юныс, Т.Миңнуллин, Т.Галиуллин, Ф.Яруллин, Р.Фәйзуллин, Х.Әюп, Р.Сибат, Р.Вәлиев, К.Кәримов, Н.Гыйматдинова, Г.Гыйльманов, Г.Морат һ.б. әсәрләрендә тирән мәгънәле, фәлсәфи эчтәлекле гыйбарәләр, әһәмиятле урын алып, туган телебезнең мөмкинлекләре чикләнмәгән булуга ишарә ясап торалар. Инде килеп, Р.Харис, Р.Батулла, М.Галиев, М.Мирза, З.Хәким кебек киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм язучы һәм шагыйрьләребезнең тапкыр-зирәк сүзләрне, акыллы гыйбарәләрне максатчан иҗат итүләре һәм теркәпберкетеп барулары билгеле.

*Сәхифә «Дөньяда сүзем калыр» (Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел) китабы нигезендә даими алып барылачак.

Иҗатчылары мәгълүм хикмәтле гыйбарәләрне канатлы сүзләр, тәгъбирләр, юмор һәм ирония белән әйтелгән «төрткеләр» дип йөртсәләр дә, соңгы вакытта фәндә аларны афоризмнар дип атау әйләнешкә кереп бара. Бүгенге көндә татар әдипләре каләменнән төшкән әсәрләрдәге зирәк, тапкыр, хикмәтле сүзләрне, ягъни афоризмнарны җыю, теркәү, җыентыклар төзү өстендә эш алып барыла. Шул уңайдан ике хезмәтне — «Мәгариф» нәшриятында басылган «Татар акылы» (төз.: А.Г.Яхин, Л.Ә.Гыйззәтуллина, Л.Г.Шәрифуллина. — Казан, 2002) һәм «Мин әйттем: татар язучыларының афоризмнары, хикмәтле сүзләре, фәлсәфи уйланулары» дип аталган (төз. Г.Ә.Нәбиуллина һәм Л.Г.Гыйләҗева. — Казан, 2008) җыентыкларны билгеләп узарга кирәк. Борынгы гомумтөрки һәм урта гасырлардан алып хәзерге чорга кадәр яшәп иҗат иткән язучы-шагыйрьләрнең әсәрләреннән бөртекләп җыелган күпсанлы афоризмнарны туплаган әлеге әдәби хәзинәләр, тиз арада таралып, үз укучысын тапты.

Күпсанлы укучыларыбызның сорау-үтенечләрен истә тотып төзелгән «Дөньяда сүзем калыр» җыентыгы югарыда телгә алган мәҗмугаларның тулыландырылган, яңартылган басмасы буларак тәкъдим ителә.

Җыентыкта урын алган афоризмнарның эчтәлегеннән һәм безнең тикшеренүләребездән күренгән афоризмнар иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр, яшәеш кыйммәтләре, әхлакый төшенчәләргә бәйле проблемаларны яктырта. Тормыш-яшәешнең төрле ягына караган мәүзугларны иңләп үтә торган мәсьәлә ул — милләт язмышы. Күрәсең, фаҗигале язмышка дучар булган татарның һәр әдибе милләтенең бүгенгесен, киләчәген читләтеп уза



алмый. Шуңа да безнең сүз сәнгатен, халык, милләт, сәясәт, тел, моң, хәтер кебек темалар, афористик гыйбарәләр күләме ягыннан да, үткенлеге һәм кискенлеге, җан авазы булып яңгырашы белән дә аерылып торалар. Г.Тукай һәм Г.Исхакыйлардан алып бүгенге әдипләребез иҗатында чагылыш тапкан әлеге сорауга Т.Миңнуллин кыска гына болай дип җавап бирә: «Әгәр милләтеңне көчле итеп, бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан».

Ә Р.Зәйдулланың «Коллар без — үзара хан булып кыланабыз, үзебез ятлардан телебезне теләнәбез»; Г.Моратның «Ирек яуларга да хокук кирәк, Сорап алып булмый ирекне» дигән фикерләрен сызланмыйча укып булмый.

М.Галиевнең «Тел ул — халыкның рухи дәвасы», М.Әгъләмовның «Хәтер — синең киләчәгең дә», Ф.Яруллинның «Язмыш — арба, гел шуны

тартып йөрисең, кая гына барма», Х.Әюпнең «Безнең өчен иман шулдыр: бу дөньяның карасына манамана, җаның агарт», М.Мирзаның «Ерак үткәннәргә хәтердә булса да кайтып була, Ерак киләчәккә барыр өчен, хыял гына җитми» кебек уйлануларында тормыш-яшәеш үзенең бөтен каршылыгында, катлаулылыгында күз алдына килеп баса.

Татар әдипләренең игътибар үзәгендә кеше тора, ул язылган һәм язылмаган кануннар хакында фикер йөртә. «Кеше күңеле — дәрья» (Г.Ахунов), «Күңел сере бар чагында гына, яшәү рәхәт» (А.Гыйләҗев) кебек гыйбарәләр кеше язмышы турында уйланырга мәҗбүр итәләр. Бу яктан үзенең үткенлеге һәм таләпчәнлеге белән сискәндереп җибәргән А.Гыйләҗевнең «Кеше гаепсез булса, узган гомере турында уйлап та карамас иде», Т.Галиуллинның «һәр кешедә әллә ничә мин утыра» яисә Ш.Галиевнең «Үзеңне җиңү — иң зур җиңү, монда җиңелүче юк», Р.Вәлиевнең «Бөекләр күп сөйләшми», З.Хәкимнең «Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ясалмалылыгы гына ясалма түгел» кебек фикерләренә беркем дә битараф кала алмастыр. Югарыда китерелгән образлы гыйбарәләрнең һәркайсында халыкның гасырлар дәвамында туплый килгән тормыш тәҗрибәсе, фәлсәфәсе, дөньяны образ-символлар аша күзаллавы чагыла.

Афористик гыйбарәләр арасында аеруча зур урын биләгән тагын бер тема — әхлакый кыйммәтләр. Татар халкы — горурлык, сабырлык, ярдәмчеллек, чисталык ярату, гыйлемгә омтылу һ.б. сыйфатлары белән хөрмәт казанган милләт. Шул ук вакытта мин-минлек, икейөзлелек, ваемсызлык кебек сыйфатлар аны тарката, көчсезләндерә. Болар барысы да афоризмнарда ярылып яталар. Мисал итеп, М.Галиевнең «Горурлык — күңелең ауганда да аумый торган текә манара йөртү», М.Мирзаның «Гадилек — һәркем күтәрелә ала, әмма һәркем шунда кала алмый торган биеклек», Р.Батулланың «Әрсез, әрләгән саен, әрләндәй сикерә» фикерләрен китерү урынлы булыр.

Төрле буын һәм зәвык тарафдарларын кеше холкы, яшәү рәвеше, үзгәреп торган әхлак кагыйдәләре турында гомумирәк, мәгәр һәр очракта кулланырга мөмкин булган тәгъбирләр якынлаштыра. Р.Фәйзуллин: «Җиңел килгән рәхәттән саклан», — дип кисәтсә, М.Галиев, аның белән бәхәсләшкәндәй: «Тормышның һәр мизгеленнән рәхәт ала белсәң генә, рух күтәренке була», — ди, элегрәк яшәп иҗат иткән С.Сөләйманованың бәхеткә үз бәясе бар икән: «Бәхет күп сорый, аз биреп».

Гаиләдә бала тәрбияләү, аңа әхлак кагыйдәләрен яшьтән сеңдереп үстерү турында күп язылу табигый. «Өендә ялкаулык күрмәсә, бала ялкау булмый» (М.Мирза) җөмләсен анализлап, педагоглар бик күп мәгънәви юнәлешләр табарлар иде.

Язучыларның уйларында нәкъ менә безнең көннәр яшәешен ачып биргән гыйбарәләр дә аз түгел. «Кара төннең күзе юк, Намуссызның йөзе юк» (Р.Фәйзуллин), «Иң авыр эш эшсез утыру икән» (К.Кәримов) яисә М.Галиевнең «Ахмаклык кылу өчен, акыл кирәкми» дигән фикерләре безнең чор өчен ят дип әйтеп кара.

Җыентыкка тупланган афоризмнар, хикмәтле, образлы гыйбарәләр — бәяләп бетергесез байлыгыбыз, рухи хәзинәбез, Тукай халык җырлары турында әйткәнчә, «тутыкмас» мирасыбыз. Аларда яшәешнең, кеше

тормышының нинди генә гамәли вә нисби кыйблалары, рухани дөньяның, әдәп-әхлак мәсьәләләренең кайсы яклары гына чагылыш тапмый. Халкыбызның сынамышлары гасырлар дәвамында чарлана килгән. Аларның көнитеш тәҗрибәләре йогынтысында туганнарын (әйтик, табигать яшәешен ачуга багышланган «Карга, каркылдап, яз ясый алмаган кебек, бүре улаганга гына, кыш та килми» (Ф. Яруллин)) сүз осталарыбызның үз күзәтүләре, шәхси сиземләүләре нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәре тулыландыра.

Татар афоризмнарында, гомуми иҗтимагый мәсьәләләр белән бергә, гаилә, хатын-кыз, ир-ат, мәхәббәт һәм нәфрәт, бәхет, акыл һәм гыйлем, гаделлек һәм ялган кебек мәңгелек фәлсәфи төшенчәләр дә зур урын били.

Мисал рәвешендә китапта ике мәүзугның яктыртылышына игътибар итик: батырлык һәм мәхәббәт.

Күптән түгел арабыздан киткән, үзенең тормышы, иҗаты белән чын баһадирлык үрнәге күрсәтеп калдырган Ф.Яруллин батырлык һәм аның нигезләре турында күп яза: «Батырлык! Нәрсә ул батырлык? Газинурлар, Матросовлар шикелле, күкрәгең белән дошман амбразурасын каплаумы, әллә үзең ач чакта соңгы сынык икмәгең белән бүлешүме? Кешеләр төрле-төрле булган кебек, батырлык та күптөрле шул».

Алдарак язучы бу фикеренә ачыклык кертә: «Акны ак дип әйтергә дә батырлык кирәк кайчак». Батырлыкның нигезләре, төрле чагылышлары турында уйланмаган язучы сирәктер. К.Тинчурин: «Үкенмәү зур батырлык сорый», — дип язып калдырган булса, З.Зәйнуллин: «Кан кою өчен, акыл кирәкми», — дигән пацифистик фикерен калкытып куя.

Мәңгелек һәм олы, бөек бер хис булган мәхәббәт турында язмаган сүз остасы юктыр. Мәхәббәт сагышы, сөю-сөелү хисе кебек һәр инсан башыннан уза торган кичереш хакында бераүләр, бигрәк тә прозаиклар белән драматурглар, тәфсилле итеп язарга яратса, икенчеләре, бигрәк тә шагыйрьләр, аны кыска, әмма тирән мәгънәле афористик юлларга сыйдыралар. Уртак мәхәббәтен таба алмый интеккән затларны драматург Т.Миңнуллин акыллы киңәше белән «юата». «Яраттырасың килсә, үзең дә ярат. Ярата алмасаң — хөрмәт ит. Шулчакта сине дә яратырлар». Бу олы тойгы турында сафсата сатарга ятакканнарны З.Хәким болай «фаш итә»: «Мәхәббәте аз булган кеше мәхәббәт турында күп сөйли. Яратырга сәләтле кеше сөйләми. Ул ярата». Күренекле Ә.Еники дә кыска җөмләсенә фәлсәфи мәгънә сала: «Мәхәббәт — яраткан кешеңне бәхетле итү ул». Шул ук мәүзугны язучылар көтелмәгән чагылышларында ачып куялар: «Өмер белән үлеп була, әмер белән яратып булмый» (Т.Галиуллин) яисә «Газап татымаган кеше ләззәт тәмен белми» (М.Юныс).

Мәхәббәт диңгез уртасындагы ялгыз утрау түгел. Гашыйк булу, яратышу — ике кешенең уртак бәхете, яшәешләренә нур бөркеп торучы чыганак. Р.Фәйзуллинның «Кешенең иң зур иреге — сөюе, сөелүе» дигән афоризмы мәхәббәткә мәдхия булып яңгыраса, Г.Афзалның «Ничек итеп алга барырга дип, бичара ирләр ут йота, Дөньяны хатыннар белән сыерлар тота» сүзләреннән хатын-кыз һәм ир-атның тормыштагы урыннарын чамаларга мөмкин.

Ир-егет язучылар, хатын-кызны олылап, аның гүзәллеге ал-

дында сәҗдә кылсалар (шул ук Р.Фәйзуллин: «Ир-ат, егет — бөтенебез хатын-кыз ятиме без», — дип яза), дөнья бизәкләре-каләм ияләре, ирләрнең тормыштагы урыннарына хакыйкый бәя бирү белән беррәттән, «кара яндырып» чеметеп алырга да күп сорамыйлар.

Бу төр мисаллар җыентыкта Н.Гыйматдинова иҗатыннан күп китерелгән: «Ирсез гомер – нурсыз гомер», «Хатын-кыз төлкедән хәйләкәр, еландай зәһәр».

Мәхәббәт турындагы гыйбарәләргә матурлык, үз-үзеңне тота белү турындагы уйланулар якын тора. «Кешеләр алдында матур булу — үзең алдында матур булу ул», – ди Ф.Яруллин.

Төзүчеләр сүз сәнгатебезнең афористик байлыгын мөмкин чаклы тулырак иңләргә тырышсалар да, меңәр еллык тарихлы татар әдәбиятының ачыклыкка, матурлыкка, яктылыкка омтылышын бөтен тулылыгы белән иңләү мөмкин түгел. Р.Зәйдулла, Г.Морат, Ф.Тарханова, Р.Аймәт кебек яшьрәк буын иҗаты күпмедер күләмдә исәпкә алынса да, Л.Шәех, Р.Сәлах, Э.Һадиева, Р.Мөхәммәтшин, Й.Миңнуллина, Р.Галиуллин һ.б. кебек бөтенләй яңа буын, әдәбиятка килеп, мәҗмугада тәкъдим ителгән өлкәдә дә үз сүзен әйтергә өлгерде инде. Димәк, инде яңа «китап» ишек шакый. Анысын төзү инде дистә елны тәшкил итәргә мөмкин.

Ниһаять, татар халкының зиһен, акыл, хис байлыгын эченә алган бу өлкә әдәбият, тел, фәлсәфә, тарих галимнәре тарафыннан фәнни-гамәли өйрәнү эшенең дә көн тәртибенә куелуын сорый. Җыентыкка кергән, төрле чорда, төрле юнәлеш, өслүб вәкилләренең иҗат җимешләре буенча халкыбызның холкын, хыялөметләрен, күңел нурын гына түгел, ул үткән тарихи юлны, фикерләү дәрәҗәсе үсүне дә күзаллый алабыз.

Чынлыкта, йомры, хикмәтле, мәгънәле гыйбарәләрнең үз иҗатларында җәйрәп ятуын язучы үзе белмәскә дә мөмкин. Әйтик, «Адәм баласы» — М.Мирза үз шигъриятендә шулчаклы афоризмнар булуын күз алдына китерә алмагандыр. Мин дә үз иҗатымда шактый мәгънәле афоризмнар табылыр дип уйламаган да идем. Шул яктан бәяләгәндә, бу җыентык язучыларыбызның эзләнүләрен, сурәтле фикерләү үзенчәлекләрен, осталык лабораториясен аңларга да ярдәм итә. «Тарихта каласың килсә, уеңны уйлап, өздереп әйт, буш сафсата сатма» дигән киңәшен дә бирә каләм тибрәтүчеләргә бу җыентык.

Күренгәнчә, сурәтле фикерләүнең иң борынгы формаларыннан берсе булган афоризмнар билгеле бер чорның проблемаларын, халык тормышының фәлсәфәсен күзалларга ярдәм итәләр. Формасы белән җыйнак, эчтәлеге белән тирән мәгънәгә ия бу гыйбарәләр вакыт агышын тоярга, халыкның гасырлар дәвамында формалашкан иҗтимагыйфәлсәфи фикер тарихын, әхлакыйэтик кануннарын, дөньяга карашын, яшәеш кыйммәтләренә мөнәсәбәтен үсештә-үзгәрештә күзалларга да мөмкинлек тудыралар.

Афористик яңгырашлы гыйбарәләрне табу, тану, сайлап алу — ком катламыннан алтын бөртекләрен аерып алу шикелле үк, катлаулы, четерекле һәм әдәби зәвыкны, сиземләүне таләп итә торган шөгыль. Бу эшне яратып, иренмичә эшләгәндә генә уңышка ирешеп була. Шул яссылыктан бәяләгәндә, төзүчеләр башкарган игелекле хезмәт икеләтә хөрмәткә лаек.

ИЛЕ ИРКЕННЕҢ КӨНЕ ИРКЕН

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА
филология фәннәре кандидатлары

Кем ки туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаса, аның күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр.

Габдулла Тукай

Туган илем…
Якынлыгың синең белмәдем мин,
Ерак китми торып,
Ничек яшьлек тәмен без белмибез,
Картлык килми торып!

Абдулла Алиш

Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

Фатих Кәрим

Чит җирләрдә күп йөрсәң, үз балаларың үзеңә ят булып бетә.

Габдрахман Әпсәләмов

Чит илләргә чыксаң, озак торма,
Гыйбрәт алыр өчен чык икән.

Илдар Юзеев

Туган якта һәр тал җырлый.

Сибгат Хәким

Иленнән аерылган — җиреннән аерылган, җиреннән аерылган — җименнән аерылган.

Сәет Шәкүров

Безнең тамырлар — туган-үскән җирдә. Башта тамыр өзелгәнен сизмисең әле. Аның булуын, кирәклеген дә белмисең, белем алып, һөнәр үзләштереп йөргәндә, өлкәнәя башлагач кына, тамырсызлык сизелә. Гореф-гадәт безне ата-баба шәфкатенә, аларның яшәү ысулына. Тормыш тәҗрибәсенә тоташтырып торган икән. Алар, безгә кадәр йөз, биш йөз, мең ел элек яшәсәләр дә, бөтенләй үк үлмәгәннәр. Өзелгән тамырларны авылда калдырып, шәһәр туклыгына ирешкәч кенә, авылда чакта җанга ашлама булып борынгыларның васыятьләре кереп торганлыгын тоя башлыйбыз. Шулардан колак каккач, безгә акыл кирә. Тормыш җиле тәгәрәтеп йөртә башлагач, син нәрсәгә генә тотынып карамыйсың. Җилгә каршы торырга тамыр юк. Шул шәфкатьсез җил сине аракыга, ялкаулыкка, әхлаксызлыкка китереп аудара. Тамырсыз агач корый. Тамырсыз үлән чери. Адәм баласы бит агачтан да, үләннән дә сизгеррәк. Дөнья иминлеге — тамырда.

Миргазиян Юныс

Кеше, кайда гына төпләнмәсен, нинди генә югарылыкларга ирешмәсен, туган туфрагыннан, туган җиреннән олы була алмый. Кечкенәме-зурмы, баймыярлымы, кендек каны тамган җир — бердәнбер изге җир. Ә иҗатчы өчен туган җир йөз мәртәбә газизрәк, чөнки иҗатның чишмә башы — туган җир.

Марат Әмирханов

Туган җирдә исемсезләр дә югалмый.

* * *

Үзең читтә чакта да, күңел туган якта яши.

* * *

Чит җирнең бердәнбер яхшылыгы — туган җир кадерен ныграк сиздерә.

* * *

Күңелдәге сагыну бөресе туган җирдән киткәч ачыла.

* * *

Чыпчыкка да бер Ватан, Лачынга да бер Ватан.

Шәүкәт Галиев

Туган илме, торган җирме яхшы?
Берсен алып, берсен ташлама.
Олы юлга чыгар сукмакларың
авыл кырларыннан башлана.

* * *

Тәпи баскан җирем, эчкән суым
кара, акмы, ачы, татлымы —
бөтен гомерем белән түли алмам
шушы җирдә яшәү хакымны.

Саҗидә Сөләйманова

Шәһәрнең тарихтан килгән, ата-баба биргән исемен алмаштыру — кеше рухын бу җиргә бәйләп торткан киндекне өзү белән бер инде ул.

* * *

Туган илен үз теләге белән ташлап, читтә яшәгән кешенең безнең кебек гадәти кеше белән чагыштырганда нинди аермасы бар? Җавап минем өчен инде ачык: теге кешенең күңелендә туган җиргә бәйләп торучы җыр юк. Җыр бәйләргә тиеш!

Мөхәммәт Мәһдиев

Ил кадерен белим дисәң,
Чит илләрдә йөр икән.

* * *

Намус эше — ил эше,
Үлем юктыр илчегә.

Резеда Вәлиева

Табигать-анабыз һәр адәм баласына мөмкинлекләрне, талант һәм сәләтләрне дә бик җитәрлек итеп, үзенә тиешлесен бирә икән. Өстәмә мөмкинлекләр, тылсым, сихер кебек нәрсәләрнең бер дә, бер дә кирәге юк икән.

Радик Фәизов

Авылда яшәүнең үз законнары бар.

* * *

«Ватан» төшенчәсе абстракт була алмый. Шуңа күрә, ул сүзне язганда, конкрет бер җирлекне, конкрет бер төбәкне күз алдына китерергә тиешсең.

Туфан Миңнуллин

Ташландык нигездән дә шыксыз, котсыз күренеш бар микән бу дөньяда? Әйтерсең лә кешеләр бөтен ямьне, бар матурлыкны үзләре белән алып китәләр, кайчандыр көн иткән төшләрендә кайгы-хәсрәт эзләрен генә калдыралар.

Мәдинә Маликова

Адәмне гомер-гомергә үзен дөнья кочагына үстереп тапшырган туган туфрагы, нигез-оясы озата бара. Җәннәт бакчаларына тиң табигать-мохит куенында да шул туфрак җылысын тоеп, үзеңнең нигәдер, кемгәдер кирәклегеңне сизеп яшисең. Кайдадыр сине көтәләр, синең кемгәдер хаҗәтең зур! Бу тойгы һәрчак алгысытып, ашкындырып тота, өметне яшәтә!

Роберт Әхмәтҗанов

Туган ягына һәркемнең җиңүче булып кайтасы килә. Авыл — бөркетләр оясы. Ул үз балаларын еракка, биеккә очыра да читтән генә күзәтә: я, синең хәлләрең ничек? Оча аласыңмы? Тормыш давыллары канатларыңны сындырмадымы? Безнең йөзгә кызыллык китермисеңме?

* * *

Авылның йөз күзе бар. Аннан берни яшерә алмыйсың.

* * *

Кеше күңеле өчен туган як кирәк. Еракка китсә — сагыныр өчен, картайса — балалыгына кайтыр өчен, дошман керсә — яклар өчен. Ерак җирләрдә йөргәндә, кеше читтәге матурлыкны әнә шул үзенең туган ягы белән чагыштыра. Туган ягы аңарга биеклеккә сикерү ноктасы, гүзәллек үрнәге булып хезмәт итә.

* * *

Туган туфрак беркемне дә кире какмый ул. Туган якның туфрагы да җиңел дип, картайгач үләр өчен, тикмәгә генә кешеләр туган-үскән җирләренә кайтмыйлар. Кеше, гадәттә, я бәхете ташып торганда, я күтәрә алмаслык кайгы килгәндә, я юлын югалтканда, туган якларына кайта. Бәхетле кешенең үз бәхете белән бераз мактанасы, кайгылының кайгысын таратасы, юлын җуйганнарның юл табасы килә.

Фәнис Яруллин

Бала туфракта аунап, шуны ашап үссен ул. Туфракта нидер бар. Үзебез дә шуннан лабаса.

* * *

Адәм баласының кендеге, әнисе карынынннан өзелү белән, җиргә тоташырга тиеш.

* * *

Нәселнең, нигезнең, кабилә тамырының дәвамы булачагына инанып китәргә кирәк.

Фоат Садриев

Тәпи басарга һәм күмелергә
тәгаенләнгән җирлегең булсын!

* * *

Безне бергә кайчак кайгы гына
Җыя хәзер Туган нигезгә...
Ни әйтәсең башкага! —
Җирдә нигез-тамыр кирәк
Хәтта җансыз ташка да...

* * *

Туган җирең чүл булса да,
Күңелдә ул гөл генә!
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!

Равил Фәйзуллин

Шәһәрнең үз законнары, авылның — үзенеке.

Җәүдәт Дәрзаман

Җир — илнең йөзек кашы.

* * *

Авыл ярык тагарак кебек ул. Анда су да, сүз дә тормый.

* * *

Кешеләр генәме, сулар да бит туган ягына кире кайта.

Марсель Галиев

Илдә бүре булсаң да ярый,
Тик ил өчен кирәк уларга!

Зөлфәт

Сандугач, көз җилләре исә башлауга, җылы якка китә. Җәй җиткәч, тагын бу якка кайта. Шулай җылыдан җылыга очып, кышны күрмичә гомер кичерә ул. Шуңа күрә матур сайрый, дөньяның гүзәллегенә соклана. Ә мескен чыпчыклар, песнәкләр, тукраннар туган җир, туган ил дип ябышып ята. Сандугачка караганда, туган якның чыпчыгы кадерлерәк миңа.

* * *

Туган илеңне, туган телеңне, туган җиреңне тартып алудан да зуррак җәза юктыр инде ул?!

* * *

Читтә тапкан бәхет — бер атналык тәхет кенә ул: бүген бар, иртәгә юк. Туган җирдә тамыр җибәрергә тиеш кеше.

Авылда һәр малайның үзенә генә аерым, үзенә генә хас бала чагы булмый. Авылда — бөтен малайларга, кызларга уртак бер балачак. Бер инеш, бер урман, бер күк, бер җир…

Разил Вәлиев

Бәхет — туган җирдә. Ак кыялар илендә генә.

Ринат Мөхәммәдиев

Авылыннан китсә дә кеше,
Кавеменнән китмәсен.
Кавеменнән киткән кеше
Бәхет өмет итмәсен!

Нәҗибә Сафина

Үз авылыңның матурлыгын күрмичә яшисең икән ул.

Туган авылыңнан бер китсәң, торган авыллар күбәя икән…

Камил Кәримов

Илсез һичбер кеше, һичбер халык ирекле була алмый. Илен җуйган — ирегең җуйган.

* * *

Туган йорт — туганлыкның тирән тамыры.

* * *

Туган йортын сагынудан туктаган — туганлыктан бизгән. Үткәненнән ваз кичкән.

* * *

Туган йортларын бүлгән (сатып акчасын бүлгән) туганнарның кайтыр юлы киселгән.

* * *

Туган йорттан туганын читләштергән — туганлык чылбырын өзүче.

* * *

Туган йортны төзек тоту — шунда торган туганның һәм барлык бертуганнарның бурычы.

* * *

Туган йортта барлык бертуганнарның да өлеше бар. Әмма Туган йорт — төпчекнеке. Туганнар арасында гарип булса, туган йортта аның сыеныр җире түрдән булырга тиеш.

* * *

Туган рәнҗеше туганга төшә… Туганын кичерә алган — саваплы.

* * *

Җиде бабаңнан калмаса, бу җирнең синеке булуы икеле.

Мөхәммәт Мирза

Ил-нигезеңне төзекләндерергә омтылмасаң, үз йорт-нигезеңне торгызып кына, нәселеңне саклап калып булмый ул.

* * *

Авыл таркалды, диләр аннан күченеп китүчеләр.

Нурулла Гариф

Туган як — әдипнең таяну ноктасы да, төп юнәлешен билгеләүче кыйбласы да.

* * *

Авыл татар кешесе өчен аеруча кадерле. Ул — әхлак һәм гадәткагыйдәләребезне, эстетик культуратрадицияләребезне саклаучы күңел сандыгы.

* * *

Җир йөзенең кабатланмас ямен — табигатьтәге төсләр, исләр, авазлар хәзинәсен — үзең дә «яшел яфрак чагыңда» күреп, тоеп-ишетеп калырга кирәк икән шул! Соңыннан иң аталы концерт залларында да балачак урманының аһәңен ишетермен димә...

* * *

Иң матур исем — кешенең үз исеме, диләр. Иң хикмәтле исем, — күрәсең, кешенең туган иле, дөньяга күзе ачылган төбәк исемедер: андагы басу-урман, җир-су атамалары...

Мөдәррис Вәлиев

Туган җирен яраткан кеше генә бөтен дөньяны ярата ала.

* * *

Иң ярлы кеше — туган җирсез кеше.

* * *

Туган җирне онытып булмый, аны сагынып кына була!

* * *

Туган туфрагыннан башка үлән дә үсә алмый.

* * *

Туган җир читкә киткән саен матурая, кеше, киресенчә, якынрак килгән саен матурая, шуңа күрә туган җирнең гүзәллеген читкәрәк китеп кара, кешенең гүзәллеген якынрак килеп кара.

* * *

Кайсыдыр изге китапта әйтелгән бит: «Алла безгә биргән рухны нык сагына», — дигән. Әйбәт, изге җанлы, күркәм рухлы кешеләрнең Аллаһы Тәгалә катына бик иртә китеп баруы шуның белән аңлатыла булса кирәк. Яман ниятле явыз бәндәләрдә рух бик тиз тузып-таушалып бетә икән — ни гаҗәп! Андыйлар гайрәтне чигерерлек дәрәҗәдә озак яшиләр. Туган җир белән дә шулай. Изге җанлы, саф рухлы балаларын туган җир һәрвакыт сагынып яши, үзенә чакырып, ымсындырып тора.

Галимҗан Гыйльманов

Яшең кипмәс, үз җиреңдә
Мөһаҗир булып тусаң.

Газинур Морат

Туган якның төннәре дә якты!

Ркаил Зәйдулла

Туган җирдә кеше сукбай була алмый, җирдән, туган нигездән аерылу сукбайга әйләндерә кешене.

Фирдәвес Зариф

Туган якның һәр авазы —
Үзе үлмәс бер мөнәҗәт.

Зөлфәт Хәким

(Дәвамы алдагы саннарда).

Р.Әхмәтов фотосы

ЯШӘ, САБАН ТУЕ!

ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАН

Саумы, олуг бәйрәм,
Саумы, Сабан туе!
Көтеп алдык сине,
Сагынып ел буе.

Котлый сине кояш,
Тәбрик итә җәең, —
Мәйданыңа куйган
Яшел келәм җәеп.

Котлый сине сөеп
Һәрбер чәчәк, үлән
Борынгыдан килгән
Милли даның белән.

Бәйрәм төсе кергән
Болын, тугайларга.
Сине котлап сайрый
Былбыл, тургайлар да.

Бәйрәм бүген, диеп,
Җилләр пышылдаша;
Сәламлиләр сине
Чиккән сөлге аша.

Тәбрик итә сине
Кырда буразналар, —
Безнең кебек зарыгып
Көткән бу язны алар.

Ашкынадыр йөрәк,
Күңел әллә нишли.
Сине котлап, әнә,
Чаптар атлар кешни.

Тәмле таба исе
Чыккан һәрбер өйдә.
Җырлый самавырлар
Син яраткан көйгә.

Синең хакка пешә
Бәлеш, коймаклары.
Сиңа башын ия
Хуҗа, кунаклары.

Мондый зур бәйрәмне
Онытмый бер күргән —
Гыйбрәт алып китсен,
Урын бирик түрдән.

Бер-беребез өчен
Чып-чын бәйрәм ясыйк.
Чишмә суы белән
Сусауларны басыйк.

Яше-карты килгән,
Сабан туен зурлап.
Берсе котлый биеп,
Берсе — җыру җырлап.

Яңрап-чыңлап тора
Гармун тавышлары,
Күрешү шатлыклары,
Сагыну сагышлары.

Көрәш мәйданына
Чыга батыр ирләр.
Сабан туен хаклап
Тама хәләл тирләр.

Кыза Сабан туе,
Сүнмә, кояш, балкы!
Бәйрәм кадерен белә
Тыныч хезмәт халкы.

Күңелләргә рәхәт
Бирдең, Сабан туе!
Рәхмәт, сиңа, рәхмәт,
Гүзәл Сабан туе!

Бергә-бергә яшәү
Язсын гомер буе.
Яшә, Туган илем!
Яшә, Сабан туе!

Бәйрәм итә туйлап
Татарстан иле.
Исә дөнья буйлап
Сабан туе җиле...

ХУШЛАШУ

Мин яшәдем җирдә сорау биреп,
Җавапларын таба алмадым.
Минме юкса салкын чишмәләргә
Кайнар хисләр булып таммадым?

Минме юкса язгы җилләр белән
Узышмадым язмыш кырында?
Минме иске җырны яңартмадым
Мәхәббәт һәм сагыш турында?

Лена Шагыйрьҗан



Л.Кузнецова фотосы

ШӘҮКӘТ ХӘСӘН УЛЫ БИКТИМЕРОВ

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге зур югалту кичерә. 28 майда каты авырудан соң 84 нче яшендә атаклы татар актеры, СССРның халык артисты, РСФСР һәм ТАССРның халык артисты, Россия Федерациясенең К.С.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров вафат булды.

Ш.Х.Биктимеров 1928 елның 28 октябрендә туа, Татарстанның Саба районы Миңгәр авылында үсә. 1949 елда Казан театр техникумын тәмамлаганнан соң, Г.Камал исемендәге Татар академия театры труппасына кабул ителә һәм гомер буе бу театрда эшли.

Ш.Х.Биктимеров күпкырлы иҗади шәхес, атаклы сәхнә остасы иде. Ул татар актерлар мәктәбенең сәхнәдә ышандырырлык, дөрес итеп уйнау, персонаж характерының психологик асылына тирән үтеп керү кебек иң яхшы традицияләрен үзенә тупла-

ды. Якты таланты, эшләү, фикерләү сәләте һәм сәнгать культурасы югары дәрәҗәдә булу Ш.Х.Биктимеровка күп еллар дәвамында данлыклы театрның әйдәп баручы артисты булып калырга ярдәм итте.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 60 елдан артык эшләү дәверендә Ш.Х. Биктимеров классик һәм хәзерге заман репертуарына караган 130 дан артык образ иҗат итте. Нургали (Т.Гыйззәт «Ташкыннар»), Кнуров (А.Островский «Бирнәсез кыз»), Галин (Ш.Камал «Габбас Галин»), Ленин (Н.Погодин «Баһадирлар»), Тәлгать (Х.Вахит «Беренче мәхәббәт»), Сәитгәрәй (Н.Исәнбәт «Гөлҗамал»), Ислам (Ш.Хөсәенов «Әни килде»), Туктамыш хан (Ю.Сафиуллин «Идегәй»), Канкаев (Т. Миңнуллин «Канкай углы Бәхтияр»), Ишан (К.Тинчурин «Зәңгәр шәл»), Хан (Ф.Борнаш «Таһир — Зөһрә»), Тархан (Н.Исәнбәт «Хуҗа Насретдин»), Дорозуар (Э.Лабиш «Тол ханымда тукталыш») кебек рольләре һәм башкалар татар актерлык сәнгате хәзинәсенә керде. Ш.Х. Биктимеровның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Т.Г.Миңнуллин әсәрләре буенча куелган спектакльләрдәге Хәсән Акчурин («Без китәбез, сез каласыз»), Сибгат («Ат карагы»), Нурхәмәт («Илгизәр+Вера»), Нурислам («Дуслар җыелган җирдә»), Палач («Моңлы бер җыр»), Зариф («Монда тудык, монда үстек»), Шаһит («Хушыгыз!») рольләре чын мәгънәсендә иҗади уңыш дип танылды.

1967 елда Ш.Х.Биктимеров Ч.Айтматов повесте буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә Байтимер ролен башкарган өчен Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек булды.

Т.Г.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклендәге Әлмәндәр карт образы Ш.Х. Биктимеровның гаять зур казанышына әйләнде. Бу рольне башкарган өчен ул РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Спектакль 35 елдан артык сәхнәдән төшмәде, бу әсәр берничә буын тамашачылар һәм актерлар тәрбияләде, Ш.Х.Биктимеров башкаруында Әлмәндәр образы милли сәхнә вакыйгасына әйләнде, ул милләтнең әхлакый кыйбласын чагылдырды.

Ш.Х.Биктимеровның иҗади тормышы зур иҗтимагый эш белән бәйләнеп барды, ул Казан шәһәр Советы, ТАССР Югары Советы, СССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Татар халкының иң популяр һәм иң яраткан артистларының берсе, XX гасыр театр сәхнәсенең атаклы остасы Шәүкәт Хәсән улы Биктимеровның иҗат һәм тормыш юлы театр сәнгатенә тугры һәм фидакарьләрчә хезмәт итү үрнәге булып тора.

Татар театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән, Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Ш.Х.Биктимеров «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде.

СССРның халык артисты Шәүкәт Хәсән улы Биктимеровның күпкырлы иҗаты халык йөрәгенә мәңгелеккә үтеп керде, ул халкыбызның казанышына әйләнде. Аның якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

Р.Н.МИҢНЕХАНОВ,
М.Ш.ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х.МӨХӘММӘТШИН,
И.Ш.ХАЛИКОВ,
Ю.З.КАМАЛТЫНОВ,
И.Р.МЕТШИН,
А.М.СИБАГАТУЛЛИН,
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ,
Ф.Р.БИКЧӘНТӘЕВ,
А.Я.СЛАВУТСКИЙ,
Р.М.ЗАҺИДУЛЛИН.

В.Зотов фотосы



Быел әллә нинди моңсу ел булды. Кайгы, чыннан да, ялгызы гына йөрми икән. Татар театры бер-бер артлы авыр югалтулар кичерә. Арабыздан бер-бер артлы затлы, асыл шәхесләребез китеп бара. Шамил Закиров, Туфан Миңнуллин, инде менә Шәүкәт Биктимеров. Татар артисты. Тумышы белән, бөтен булмышы белән Актер. Талант. Сирәк очрый торган табигый Талант. Шәхес. Шәхеснең дә иң затлысы, иң зыялысы, иң кешелеклесе. Камал театрының йөзек кашы, татар театрының йөз аклыгы, татар театрының намусы, татар театрының тарихы, легендасы. Без бүген татарларыбыз арасыннан СССР ның иң соңгы халык артистын соңгы юлга озатабыз. Ул Совет чорында ук илебезнең Михаил Ульянов, Кирилл Лавров кебек иң күренекле артистлары дәрәҗәсенә менгән, татар театрының, республикабызның, халкыбызның данын күкләргә күтәргән, дәүләтебезнең иң югары бүләкләрен алган шәхесебез иде. ТАССР ның Югары Советы депутаты булса да, СССР Югары Советы депутаты булып

сайланса да, зур-зур җәмәгать эшләре алып барса да, бик еш кына төрле президиумнарда утырса да, ул иң элек Кеше һәм Актер булып калды.

Шәүкәт абый — йөзләгән кабатланмас рольләр уйнаган, үлемсез образлар тудырган артист. Без аны Ишан буларак та, Туктамыш хан буларак та беләбез, безнең өчен ул Бәхтияр Канкаев та, Шәкүр карак та, ул пролетариат юлбашчысы Ульянов-Ленин да, үлемсез Әлмәндәр дә. Ул татар кешесенең, татар картының, татар аксакалының нинди булырга тиеш икәнен татарның үзенә дә, бөтен дөньяга да күрсәтеп китте.

Бөекләребез китә тора. Бөекләрне, әлбәттә, беркем дә алыштыра алмый. Шуңа да бөекләр алар. Әмма аларның изге урыннары буш та торырга тиеш түгел. Яңа Әлмәндәрләрне сәхнәдә күрсәтерлек талантлы, яшь Марсель Сәлимҗановларыбыз калкып чыгарга тиеш, әдәбиятка яңа «Әлдермештән Әлмәндәр»ләрне язарлык талантлы, яшь Туфан Миңнуллиннарыбыз килергә тиеш. Татар сәхнәсендә яңа Әлмәндәрләрне уйнарлык талантлы, яшь Шәүкәт Биктимеровларыбыз булырга тиеш. Бөекләр киткән саен без дә — алар урынына калганнар да — үзгәрергә, җитдиләнергә, милләт алдындагы, әдәбият-сәнгать алдындагы бөек җаваплылыкны үз өстебезгә алырга бурычлыбыз…

Шәүкәт абыйны барыбыз да ярата идек. Җитмешенче елларда без аның белән бер йортта яшәдек. Мин шул чакта аның нинди әйбәт күрше икәнен, нинди ихлас, матур күңелле кеше икәнен якыннан белдем. Сиксәненче елларда Татарстан телевидениесендә режиссёр Әхтәм Зарипов «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле берничә серияле телевизион спектакль куйды. Мин аның редакторы идем. Шул чакта Хаҗи әфәндене уйнаган Шәүкәт Биктимеровның нинди искиткеч талантлы актер икәнен миңа якыннан күрергә туры килде.

Ул әдипләр белән дә, композитор-музыкантлар белән дә, рәссамнар белән дә һәрчак дус булып яшәде. Аны бигрәк тә рәссамнар яратты, аларның һәрберсе Шәүкәт абыйның портретын ясарга тырыша иде. Һәм кем генә ясаса да — аның портреты уңышлы чыга иде. Чөнки аннан Ходай талантны да, төс-кыяфәтне дә җәлләмәгән иде. Кыскасы, ул чын татар иде. Сәхнәдә дә, тормышта да үзенең татарлыгын онытмады… Ул безнең күңелләрдә нәкъ менә чын татар булып, чын татар карты Әлмәндәр булып сакланачак та.

Рәхмәт сиңа, Шәүкәт абый
Рәхмәт сиңа, Әлмәндәр бабай!
Хуш!
Урының җәннәттә булсын!

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты,
Халык шагыйре

Р.Әхмәтов фотосы

САБАНТУЙ

МӨХӘММӘТ МИРЗА

...Татар көпшәк халык түгел,
йолкырга, тарткаларга...
М. Шәймиев

I
Сабантуй – туган халкымның
Тиңдәшсез тантанасы!
Кешелеккә яшьтәш бәйрәм,
Әйтегез, кайда бар соң!

Ядкәре бөек Болгарның,
Хаҗитархан, Урданың.
Сарматларда, Каганатта
Сабантуйлар булган ул!

Сабан туе орыш түгел,
Ярыш, алыш – сынатма.
Мәйданнарга сөлге тотып
Чыгып баскан ир-атка

Төбәлгән ил-йорт карашы,
Алымы ни, ысулы.
Аксакаллар хөкем итәр,
Хаклык булмас кысулы...

Җитезләрнең җитезе кем,
Матурлардан кем матур?
Тапкырларның тапкыры кем,
Батырлардан кем батыр?

Барлау кирәк,санлау кирәк,
Данлау кирәк аларны.
Батырлары булса гына
Халык гомере дәвамлы.

II
Билләргә ята ак сөлге.
Имәндәй нык егетләр,
Иңнәрендә ил-йорт йөге,
Алып батыр кебекләр.

Кызлар бии, калфаклары
Ука белән чиккәнме,
Әллә инде кызыл туйлар
Итәр чаклар җиткәнме?

Кызлар бии, биесеннәр,
Биеп туймас чаклары.
Сабантуйда бии хәтта
Ярсу чабыш атлары...

Аргамаклар ак күбектә
Очып үтә араны.
Тояклары чыңлавында
Моңы Кыпчак-даланың...

Чәчән суза, саз сызыла,
Курай, торба, думбыра...
Уралыннан, Сарытаудан
Урап килгән моң гына.

Моң – гасырлар аръягыннан,
Шанлы еллар багыннан...
Шөкер, милләтем бердәнбер
Иманына табынган...

Кыйбласы бер, иманы бер,
Теле бөтен, бер генә.
Шул милләтне бүлгәләргә
Җөрьәт итәр кем генә.

III
Сабантуйлы халык бер ул,
Белсәң дә, белмәсәң дә!
Меңьеллардан килгән берлек
Тармаңгай кемсәләргә

Тынгы бирмидер халыкның
Гайрәте, олпатлыгы...
Мәйданга чык — исбатла соң
Ниятеңнең хаклыгын...

Аерып кара халыкны
Кәсебе, һөнәреннән...
Бозлык чорыннан бер булып
Яшәгән көннәреннән.

Аерып кара җырыннан,
Чулпылары чыңыннан...
Риваяте, дастаннары,
Бүгенгесе – чынынннан.

Аерып кара Җаекны,
Агыйделне Уралдан...
Чулман, Идел, Иртыш, Нократ
Бердәм халык, туганнар

Көн иткән кыры, ярында...
Урманы, даласында...
Аерып кара халыкны...
Мең яшьлек каласыннан?..

Кемгә ни җитми, байлыкмы,
Туганынмы тарсына?..
Чикләнмәгән форсат бирә,
Сабан туе барсына.

Кирәк ыру, кавем булсын,
Кирәксә иңсен күктән...
Чык мәйданга — дан алырсың,
Буләккә — сөлге көтә!

Бердәнбер хаклык урыны,
Хак бизмәне шул чиктә.
Кавемеңне бөек итеп,
Көрәсең килсә бик тә,

Сан белән түгел, сын белән
Яула мәйданга чыгып.
Сабан туе сынауларның
Иң гаделе, иң чыны!

Узышта ал, алышта бил
Бирмәгән халык кына.

Сабантуйлы — мәйданлы ил,
Мәйдансыз — сарык кына.

Мәйдансыз бүленеп калса,
Бер бүре чыгар буып,
Ыру кавемгә таркалса,
Куян таркатыр куып...

Юк, көпшәк халык түгел без,
Йолкырга, тарткаларга.
Юл куймабыз, белеп торсын
Дус, ятлар, башкалар да.

Таш атканга да аш куйган,
Кичерә белгән халык.
«Юаш», — диеп, ялгыш уйда
Булса кемдер, — беркатлы...

Кичерү мөмкин ялгышны
Кардәш, дуслык хакына.
Ялган, яла, хыянәтне
Кылса кемдер халкыма,

Көтмәсен һичбер ярлыкау
Бүген һәм килерендә...
Гомер иткән һәр көн сынау,
И алып, билең бирмә!

Гомер иткән һәр көн сынау
Галәм, дөнья каршында...
Аргамаклар ак күбектә
Ал бирмичә ярсыган...

Гомер иткән һәр көн сынау
Үр менгәндә, милләтем,
Бердәмлегең, бөтенлегең
Кыйммәтләрдән кыйммәтле!!!

Гомер иткән һәр көн сынау
Җитлегү, олпатлыкка.
Сабан туе мәйданында
Милләтем сынау тота!

Аксакаллар хөкем итә,
Күз уңында һәр алым.
Ак сөлгеңдәй ак юл сиңа,
Алыплы, моңлы халкым!

ЯҢА КИТАПЛАР



ХРИСТИАНСКОЕ ПРОСВЕЩЕНИЕ И РЕЛИГИОЗНЫЕ ДВИЖЕНИЯ (РЕИСЛАМИЗАЦИЯ) КРЕЩЕНЫХ ТАТАР В XIX – НАЧАЛЕ XX ВВ.

Сборник материалов и документов / Сост., автор вступительной ст., примечаний, научно-справочного аппарата Р.Р.Исхаков. – Казань: Изд-во «Ихлас», Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2012. – 412 с. Тираж – 100 экз.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Радик Исхаков төзегән документлар һәм материаллар җыентыгы татар халкы тарихының моңарчы аз өйрәнелгән сәхифәләрен актырта.

Китапта Россия дәүләт тарих архивы (Санкт-Петербург), Татарстан Республикасы милли архивы (Казан), Россия милли китапханәсенең кулъязмалар бүлеге (Санкт-Петербург), Россия дәүләт китапханәсенең кулъязмалар бүлеге (Мәскәү) документлары, вакытлы матбугат һәм миссионер оешмаларның моңарчы дөнья күргән кайбер еллык хисапларыннан өзекләр урын алган. Аларның авторлары булып төбәкләрдәге рухани җитәкчеләр, миссионерлар, шул исәптән Н.И.Ильминский, Я.Коблов, В.Т.Тимофеев һ.б., Казан рухани академиясе студентлары, үзәк һәм губерна хакимияте вәкилләре, шулай ук керәшен татарлары (гаризалар) тора. Китапта урнаштырылган 69 документның төп өлеше беренче тапкыр быстырыла.

Чыганакларда Казан, Түбән Новгород, Сембер, Пермь, Вятка, Уфа губерналарында, Алтайда, Енисейск шәһәрендә булган вакыйгалар бәян ителә.

Темага «керү» өчен, Р.Р.Исхаковның «XIX – XX гасыр башында православие миссионерлары һәм керәшен татарлары арасында этноконфессиональ барыш» исемле кереш мәкаләсе белән танышу файдалы.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган тари-

хи чыганаклар өч катлаулы фәнни проблеманы ачып бирүгә юнәлтелгән: самодержавие һәм Рус православие чиркәвенең татарларны христианлаштыру сәясәте һәм керәшен татарларының мөселманлыкка кайту хәрәкәтенә каршы көрәше; православие миссионерлары тырышлыгы белән керәшен татарларының бер өлешендә христиан ориентациясе көчәю — нәтиҗә буларак православие динендәге төркем оешу процессы; керәшен татарларының икенче бер төркеменең, киресенчә, бабалары диненә кире кайтулары һәм «яңа» мөселманнарга әверелүләре.

Бу катлаулы фәнни мәсьәләләр күп еллар дәвамында кискен бәхәсләргә сәбәп булды һәм капма-каршы фикерләр формалашуга китерде. Чыннан да, галим кеше чит дин һәм мәдәният таратуны, бу өлкәдә аерым шәхесләрнең кылган гамәлләрен тирәнтен өйрәнеп кенә төпле җавап бирергә тиеш. Документлар җыентыгы галимгә дә, укытучыга да, студентка да, тарихи чыганакларның текстлары белән танышырга һәм аларда яктыртылган вакыйгалар турында үз фикерен булдырырга ярдәм итә.

Җыентык азагында бирелгән «Территориаль-географик» һәм исемнәр күрсәткечләре кызыксындырган шәхесләрне һәм вакыйга барган урыннарны ачыкларга ярдәм итә.

Китап «Россия империясендә ислам институтлары» сериясендә нәшер ителгән.

ИСХАКОВ Р.Р.
МИССИОНЕРСТВО И МУСУЛЬМАНЕ ВОЛГО-КАМЬЯ
(последняя треть XVIII — начало XX в.). — Казань: Татар.кн.изд-во, 2011. — 222 с. Тираж — 1000 экз.

Диннәрнең җәмгыятьтә тоткан урыны көннән-көн көячәя барган заманда, этник һәм динара мөнәсәбәтләргә, шул исәптән хакимиятнең бу катлаулы һәм четерекле өлкәдәге сәясәтенә галимнәрнең игътибары бермә-бер артты. Әлеге тема белән даими һәм тирәнтен кызыксыну бигрәк тә Урта Идел төбәгендә яшәүче халыкларның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү өлкәсендә күзәтелә. Бу аңлашыла да. Идел-Чулман буйларында яшәүче

халыклар, катлаулы тарих сынаулары узып, үзара тату көн итәләр. Үткән замандагы тормыш-вакыйгаларны өйрәнеп, ул чорларда уңай күренешләрне бүгенге тормышта исәпкә алырга, ә ялгышларны кабатламаска кирәклеген җәмгыятькә җиткерү тарихчыларның гражданлык бурычы булып тора. Яшь тарихчы Радик Исхаковның XVIII гасыр ахыры — XX йөз башында Идел-Чулман төбәгендә Рус православие чиркәвенең мөселманнар белән мөнәсәбәтләренә багышланган китабы шушы хакта искәртә.

Китап дүрт бүлектән тора. Беренче бүлектә Рус православие чиркәвенең Россия империясе дәүләт оешмалары системасында тоткан урыны яктыртыла, самодержавиенең мөселманнарга карата алып барган дәүләт сәясәте концепциясе бәян ителә.

Икенче бүлектә автор төп игътибарны XVIII гасыр ахырында — XIX йөзнең беренче яртысында рухани хакимиятнең керәшеннәр арасында мөселманлыкка кайту хәрәкәтенә каршы көрәшенә һәм кулланылган яңа миссионерлык алымнарына юнәлтә, аларның түбән нәтиҗә бирү сәбәпләрен атый.

Монографиянең иң зур өлеше 1860-1890 еллар аралыгында булган вакыйгаларга багышланган. Биредә сүз, беренче чиратта, Н.И.Ильминский тарафыннан яңа, төбәк халыкларының туган телләрендә уку-укытуга, дини белем бирүгә корылган миссионерлык системасының концепциясе эшләнү һәм аны томышка ашыру, яңа миссионерлык институтларының эшчәнлеге турында бара. Изге Гурий җәмгыяте, җирле халыклар телендә китаплар тәрҗемә итү һәм бастыру, укытучы һәм рухани кадрлар хәзерләү турында сюжетлар яңа фактларга бай. Шулай ук хөкүмәтнең дин өлкәсендә мөселманнарга карата сәясәте, аерым шәхесләрнең карашлары авторның күз уңыннан читтә калмаган.

Соңгы, дүртенче, бүлек Н.И.Ильминскийның вафатыннан соңгы чорда, XX гасыр башында, илдә барган сәяси һәм иҗтимагый үзгәрешләр йогынтысында чиркәү сәясәтендәге кризисның сәбәпләрен ачыклый, аның динара мөнәсәбәтләргә йогынтысын билгели.

Китапның яңалыгы тикшерелә торган фәнни проблемага яңа караш булуда гына түгел. Укучы игътибарына тәкъдим ителгән, төрле китаплардан һәм архивлардан бөртекләп җыелган фотолар ул чор атмосферасын тоярга ярдәм итә, динара мөнәсәтләргә яңалык керткән, бу катлаулы өлкәдә мәйдан тоткан галимнәр, күренекле шәхесләрнең сурәтләре белән танышырга мөмкинлек бирә.

Китап укытучыларга, студентларга, гомумән, тарих белән кызыксынучыларга атап язылган.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ – ТӨРКИЯ РЕСПУБЛИКАСЫНДА

30-31 май көннәрендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация Төркиядә ике көнлек рәсми сәфәрдә булып кайтты.

30 майда Татарстан Илбашы Анкарада Төркия Президенты Абдулла Гөл, тышкы эшләр министры Әхмәт Давутоглу белән очрашты, Ататөрек төрбәсенә чәчәк салды.

31 май көнне исә Рөстәм Миңнеханов Истанбулда күренекле татар мөһаҗирләре Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Садри Максуди каберләрен зиярәт кылды. Алар рухына багышланган догалардан соң, мәшһүр татар җәмәгать эшлеклеләре һәм галимнәре каберләренә «Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановтан» дип язылган тасмалы зур чәчәк бәйләме куелды.

Шул ук көнне Президент Европа, Якын Көнчыгыш, Көньяк Африка һәм Урта Азия буенча Дөнья икътисади форумында катнашты. Форумның «Үзгәрүчән Россия: яңа идарәнең формалашуы» дип аталган секциясендә чыгыш ясады.

Форумнан соң Р.Миңнеханов Топбаш Төрки халыклар паркындагы Татар өендә яңа экспозиция ачылышында булды, Төркиядә яшәүче татарларның җәмгыять җитәкчеләре белән күреште, аларга татар мәдәниятен саклау өлкәсендәге хезмәтләре өчен Рәхмәт хатлары тапшырды.

Татарстан делегациясе шулай ук Төркия башкаласының Габдулла Тукай исемендәге паркында бөек татар шагыйренә һәйкәл ачылуда катнашты. Һәйкәлне Казан сынчысы Асия Миңнуллина ясаган.

Айя Суфия музее янында узган Сабантуйда Татарстаннан килгән сәнгать әһелләре ясаган чыгышлар ямь өстәде. Бәйрәмнән соң Рөстәм Миңнеханов Төркия премьер-министры Рәҗәп Тайип Эрдоган белән очрашты.

Татарстан һәм Төркия арасындагы икътисади һәм мәдәни багланышларны үстерүдә мондый рәсми очрашуларның әһәмияте бик зур.

БОЛГАР ҖЫЕНЫ – ХӘТЕР ЯҢАРТУ

10 июнь көнне Болгарда Урта Идел Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам дине кабул ителүне искә алуга багышланган Җыен үтте. Биредә Татарстан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән мөселманнар, шул исәптән

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты тарафыннан уздырылган «Милли тормыш һәм дин» дип аталган III Бөтенроссия татар имамнарының форумына җыелган дин әһелләре дә катнашты.

Махсус ясалган сәхнәдә мәртәбәле кунакларның чыгышлары концерт номерлары белән аралашып барды. Җыенның кульминациясе тарихи мәчет калдыклары урынында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт киңәшчесе, Татарстанда Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау республика фонды җитәкчесе Минтимер Шәймиев, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы генераль сәркатибе Экмаледдин Ихсаноглуның мөфтиләр, күпсанлы дәрәҗәле кунаклар һәм мөселманнар белән бергә өйлә намазын уку вакыйгасы булды.

Җыен барышында Рөстәм Миңнеханов белән килгән кунаклар күптән түгел генә ачылган һәм дөньядагы иң зур Коръән урнаштырылган бинаны карадылар, ике манаралы мәчет комплексын рәсми ачу тантанасында катнаштылар. Еraклардан күренеп, балкып торган бу мәчет манараларының биеклеге — 46,5 метр, мәчет гөмбәзенең диаметры 17 метрга кадәр җитә.

Ак мәчет янында эшли башлаган, шулай ук күптән түгел генә ачылган «Иген музее» комплексы да килгән кунакларның күңеленә хуш килде.

«ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕНДӘ ИСЛАМ МӘДӘНИЯТЕ»

«Идел-Урал төбәгендә ислам мәдәнияте» дип аталган V халыкара симпозиум Татарстан Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү үзәге, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Россия ислам университеты һәм IRCICA (Ислам тарихын, сәнгатен һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге) тарафыннан оештырылды. Әлеге чара 11-12 июнь көннәрендә Татарстан Фәннәр академиясе бинасының Кече залында узды.

Симпозиумның беренче икесе — Казанда, өченче һәм дүртенчесе Уфа шәһәрендә булган иде.

Биредә котлау сүзләре белән Төркиядән, Литвадан, Һиндстаннан, АКШтан, Нидерландтан, Россия төбәкләреннән килгән галимнәргә Татарстан Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров, IRCICA ның генераль директоры Халит Эрен, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе Разил Вәлиев, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаил Хәкимов мөрәҗәгать итте.

Симпозиумда катнашучылар күптөрле фәнни мәсьәләләр (ислам дине, архитектура, тел һәм әдәбият, ислам яңарышы, икътисад һәм хокук, мәгариф һ.б.) буенча фикер алыштылар, докладлар сөйләделәр.

Идел-Урал төбәгендәге ислам мәдәниятен Төркия һәм Россия галимнәренең бергәләп өйрәнүе татар һәм башкорт мәдәниятен гомумтөрки мәдәният киңлегендә бәяләргә мөмкинлек ачты.

Индекс 54132